КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

Җ.С. Миңнуллин, Э.К. Сәлахова

# ИСКЕ ТАТАР ЯЗУЫ

## Уку-укыту кулланмасы

Казан
«Яз» нәшрияты
2014

УДК 809.432.1(07)
ББК 81.632.3.я 7
М57

Рецензентлар:
Сафиуллина-Аль Анси Р.Р., филология фәннәре кандидаты;
Хәйретдинов А.Г., фәлсәфә фәннәре кандидаты

М57 Миңнуллин Җ.С., Сәлахова Э.К. Иске татар язуы : Уку-укыту кулланмасы / Җ.С. Миңнуллин, Э.К. Сәлахова. – Казан : Яз, 2014. – 216 б.

ISBN 978-5-904449-86-5

«Иске татар язуы» курсы гарәп әлифбасына нигезләнгән татар язуы тарихы, этаплары белән таныштыру, укырга-язарга өйрәтү, иске татар теленең фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләрен аңлатуны максат итеп куя. Иске татар теленең төрле чор язма истәлекләре белән таныштыруны күз алдында тота. Кулланмада лекция һәм гамәли дәресләрнең эчтәлеге, белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр тәкъдим ителә. Материалны үзләштергәндә ярдәм итәрлек төп һәм өстәмә әдәбият исемлеге китерелә. Кушымта рәвешендә белемне тикшерү өчен тест, гарәп хәрефләре белән күчереп язу өчен текстлар, уку өчен басма һәм кулъязма текст үрнәкләре дә урнаштырыла.

Китап югары уку йортларында «Педагогик белем», «Теология», «Лингвистика», «Тарих», «Филология» юнәлеше буенча белем алучы студентларга һәм, гомумән, иске татар язуы белән кызыксынучылар өчен тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-904449-86-5

© Казан федераль университеты, 2014

«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ)

ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

З.С. Миннуллин, Э.К. Салахова

# СТАРОТАТАРСКАЯ ПИСЬМЕННОСТЬ

## Учебное пособие

Казань
Издательство «Яз»
2014

УДК 809.432.1(07)
ББК 81.632.3.я 7
М57

Рецензенты:
Сафиуллина-Аль Анси Р.Р., кандидат филологических наук;
Хайретдинов А.Г., кандидат философских наук

М57 Миннуллин З.С. Салахова Э.К Старотатарская письменность: Учебное пособие / З.С. Миннуллин, Э.К.Салахова. – Казань: Яз, 2014. – 216 с.

ISBN 978-5-904449-86-5

Курс «Старотатарская письменность» ставит задачу ознакомления и обучения студентов старотатарскому письменному языку, умению работать с рукописьными текстами разных стилей и почерков арабского письма. Данное пособие содержит материалы лекционных и практических занятий, контрольные вопросы, практические задания. Предлогается список основной и дополнительной литературы по данной проблематике. В приложении представлены тест, тексты для работы по закреплению пройденного материала, фрагменты рукописей и тексты старотатарской письменности. Содержательная и методическая интерпретация материала осуществляется в соответствии с образовательным стандартом.

Пособие предназначено для студентов высших учебных заведений, обучающихся по направлениям «Педагогическое образование», «Теология», «Лингвистика» «История» и «Филология», а также широкому кругу читателей, всем тем, кто желает владеть старотатарским языком на арабской графике.

ISBN 978-5-904449-86-5

© Казанский федеральный университет, 2014

## Эчтәлек

Гарәп хәрефләре нигезендә татар язуы дәресләре. *Кереш* ................ 7
1 нче дәрес. «Әлиф», «би», «ти», «си», «пи» ................................... 11
2 нче дәрес. «Җим», «хи», «хы», «чи» ............................................ 14
3 нче дәрес. «Дәл», «зәл», «ра», «зи» ............................................. 15
4 нче дәрес. «Син», «шин», «съад», «зъад», «тый», «зый» .............. 16
5 нче дәрес. «Гәйн», «гъайн», «фи», «каф» ...................................... 18
6 нче дәрес. «Кәф», «гәф», «ләм», «мим» .......................................... 20
7 нче дәрес. «Нүн», «һи» .................................................................... 22
8 нче дәрес. «Уау» ............................................................................... 24
9 нчы дәрес. «Йай» .............................................................................. 26
10 нчы дәрес. «ңэ», «жэ» ..................................................................... 28
11 нче дәрес. Хәрәкәләр ........................................................................ 29
12 нче дәрес. Саннар ............................................................................ 31
13 нче дәрес. Иске татар язуының үзенчәлекләре ............................ 34
14 нче дәрес. Иске татар язуының кайбер үзенчәлекләре ............... 37
15 нче дәрес. Иске татар язуында кеше исемнәренең
бирелеше ............................................................................................ 40
16 нчы дәрес. Яңа имля ........................................................................ 43
17 нче дәрес. Кулъязмаларны укуның кайбер гомуми
кагыйдәләре һәм үзенчәлекләре .................................................. 45
Мөстәкыйль үзләштерү өчен материаллар ...................................... 47
Борынгы төркиләрдә һәм татарларда язмачылык тарихы ............... 47
Татарлар тарафыннан кулланылган гарәп язуы төрләре ................. 51
Кятибләр, хаттатлар .............................................................................. 57
Язу материаллары ................................................................................... 60
Кулъязма китапның состав өлешләре ................................................ 69
Китап бизәү сәнгате ............................................................................... 72
Китап төпләү ........................................................................................... 74
Татарларда гарәп язуында тудырылган сәнгать әсәрләре
һәм рухи һәйкәлләр ......................................................................... 77
Тугра һәм шәмаилләр ............................................................................ 77
Кабер таш язмалары .............................................................................. 82
Хөсне хат – матур язу ............................................................................ 87
Текст белән эшләү кагыйдәләре .......................................................... 94
Әдәбият чыганаклары һәм текстология ............................................. 96

Тыныш билгеләре ........................................................................ 102
Транскрипция ............................................................................... 105
XX йөз башы гарәби язулы татарча текстларны кириллица
нигезендә транскрипцияләүнең кайбер кагыйдәләре .............. 107
Төшенчәләр сүзлеге ...................................................................... 115
Әдәбият исемлеге ......................................................................... 119
Кушымта № 1. Тест ...................................................................... 125
Кушымта № 2. Гарәп хәрефләре белән күчереп
язу өчен текстлар ...................................................................... 129
Кушымта № 3. Язу үрнәкләре һәм уку өчен
басма текстлар ......................................................................... 140
Кушымта № 4. Уку өчен кульязма текстлар ................................. 192

# Гарәп хәрефләре нигезендә татар язуы дәресләре

## Кереш

Гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар язуы мең елдан артык тарихка ия. Татар мәдәниятенең күп гасырлык тарихы белән азмыкүпме таныш булганнарга мәгълүмдер, болгар бабаларыбыз дәвереннән алып, XX йөзнең егерменче еллары азагына кадәр татарларда гарәп хәрефләре кулланылышта була. Әнә шул хәрефләр белән болгар заманнарында ук фәннең төрле тармакларына караган гыйльми трактатлар, әдәби әсәрләр, шул җөмләдән, мәшһүр Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» дастаны иҗат ителгән. Бөек гуманист Мөхәммәдьяр, атаклы галим Шиһабетдин Мәрҗани, сөекле шагыйребез Габдулла Тукай әсәрләре шул хәрефләр ярдәмендә безнең көннәргә кадәр килеп җиттеләр. Гарәп хәрефләре кабер ташларына да уелган, шәмаилләр булып йорт диварларына да эленгән. Язу булгач, аның осталары да булган. Гасырлар үтү белән, язуны изге эшләрнең берсе дип санаган татар халкы арасыннан хаттатлар-каллиграфлар да үсеп чыккан. Алар арасыннан мәшһүр Гали Мәхмүдов һәм Хөсәен Фәезханов кебекләр сәнгать дәрәҗәсенә ирешкән гарәптөрки каллиграфиясеннән Казан һәм Санкт-Петербург университетларында студентларга дәрес биргән. Татар хаттатларының каурый каләме белән күчерелгән меңнәрчә кульязма китапларга татар халкының аһ-зарлары, өмет-хыяллары иңгән.

Мәгълүм ки, гарәп хәрефләренә нигезләнгән һәм хәзерге вакытта фәндә иске татар язуы, дип йөртелә торган язу системасы Идел-Урал җирлегендә катлаулы һәм гыйбрәтле юл үтте. X гасыр башларында ул болгар бабаларыбызда кулланылышта булган борынгы төрки руник язуны алыштыра. Идел буенда киң таралган гарәп язуы XIII гасырда монгол яулары белән килгән уйгыр язуына да, Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылгач, XVIII–XIX гасырларда көчләп тагылган рус алфавитына да бирешми.

1905–1907 еллар революциясеннән соң вакытлы татар матбугаты бик тиз аякка баса һәм гаҗәеп киң колач җәя – Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Уфа, Әстерхан һ.б. шәһәрләрдә дистәләрчә исемдә газета-журналлар чыга башлый, алар халык арасында киң кулланыш алалар.

1917 елдан соң татарча китап басу эше, вакытлы матбугат үсеше элек бер дә күрелмәгән яңа казанышларга ирешә. Шул ук вакытта гарәп язуын татар теленә тулаем яраклаштыру максатыннан чыгып, мөһим реформалар кабул ителә.

1929–1930 елларда Россиядә күп халыклар масштабында барган социаль-иҗтимагый, мәдәни үзгәрүләр дәвамында иске татар язуы латин хәрефләре белән алыштырыла, ә 1939 елда латин хәрефләре урынына рус алфавиты нигезендә эшләнгән, хәзер дә дәвам итә торган яңа татар язуы кертелә.

Гарәп хәрефләре нигезендә татарча укырга-язарга өйрәтү дәресләре киң катлау укучыларга адреслана, ягъни бары тик гыйльми максатларны гына күз алдында тотмый. Классик гарәп әлифбасы 28 хәрефтән торган. Гасырлар үтү белән аңа фарсы-төрки телләр җирлегендә 8 яңа хәреф өстәлгән.

Хезмәттә гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар телендә укырга-язарга өйрәтү, бу язуның үзенчәлекләре белән таныштыру максат ителә. Моңа ирешү өчен түбәндәге бурычлар куела:

1) гарәп алфавитындагы хәрефләрнең язылышын өйрәнү;

2) гарәп хәрефләре белән иске татар телендәге текстларны уку һәм шул хәрефләр белән дөрес итеп язарга өйрәнү;

3) төрле чорда язылган кульязма текстларны дөрес укый алу дәрәҗәсенә ирешү.

Түбәндә тәкъдим ителгән материал гарәп хәрефләрен язу тәртибен, аларның язуда кулланылу үзенчәлеген, гарәп язуы нигезендә язылган татарча текстларны уку тәртибен өйрәтүне күз алдында тота. Шулай ук кушымтада төрле чорның кульязма үрнәкләре бирелә, бу, үз чиратында, төрле чорда гарәп язуының үзенчәлеген, почеркларның төрлелеген тоярга мөмкинлек бирә.

Хезмәттә студентларның, гарәп язуын өйрәнүче башка укучыларның гарәп язуын үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү өчен мөстәкыйль эш төрләре тәкъдим ителә, алар – кириллица белән бирелгән татар телендәге текстны гарәп хәрефләре белән күчереп язу өчен үрнәкләр һәм шулай ук белемне тикшерү өчен тест рәвешендәге биремнәр. Студентлар өчен якынча зачет-имтихан сораулары да урнаштырыла.

# Гарәп алфавиты

| Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|
| ـا | ـا | ا | ا | әлиф |
| ـب | ـبـ | بـ | ب | бә |
| ـت | ـتـ | تـ | ت | тә |
| ـث | ـثـ | ثـ | ث | с̱ә |
| ـج | ـجـ | جـ | ج | җим |
| ـح | ـحـ | حـ | ح | х̣ә |
| ـخ | ـخـ | خـ | خ | х̱а |
| ـد | ـد | د | د | дәл |
| ـذ | ـذ | ذ | ذ | з̱әл |
| ـر | ـر | ر | ر | ра |
| ـز | ـز | ز | ز | зәйн |
| ـس | ـسـ | سـ | س | син |
| ـش | ـشـ | شـ | ش | шин |
| ـص | ـصـ | صـ | ص | с̣ад |
| ـض | ـضـ | ضـ | ض | д̣ад |
| ـط | ـطـ | طـ | ط | т̣а |
| ـظ | ـظـ | ظـ | ظ | з̣а |
| ـع | ـعـ | عـ | ع | ‘әйн |
| ـغ | ـغـ | غـ | غ | г̣айн |
| ـف | ـفـ | فـ | ف | фи |
| ـق | ـقـ | قـ | ق | к̣аф |
| ـك | ـكـ | كـ | ك | кәф |
| ـل | ـلـ | لـ | ل | ләм |
| ـم | ـمـ | مـ | م | мим |
| ـن | ـنـ | نـ | ن | нүн |
| ـه | ـهـ | هـ | ه | һа |
| ـو | ـو | و | و | уау |
| ـى | ـيـ | يـ | ى | йа |

# Иске имля әлифбасы

| Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Укылышы |
|---|---|---|---|---|
| ـا | ـا | ا | ا | а, ә (әлиф) |
| ـب | ـبـ | بـ | ب | би (би) |
| ـپ | ـپـ | پـ | پ | п (пи) |
| ـت | ـتـ | تـ | ت | т (ти) |
| ـث | ـثـ | ثـ | ث | с (си) |
| ـج | ـجـ | جـ | ج | җ (җим) |
| ـچ | ـچـ | چـ | چ | ч (чи) |
| ـح | ـحـ | حـ | ح | х (хи) йомшак |
| ـخ | ـخـ | خـ | خ | х (хы) каты |
| ـد | ـد | د | د | д (дәл) |
| ـذ | ـذ | ذ | ذ | з (зәл) |
| ـر | ـر | ر | ر | р (ра) |
| ـز | ـز | ز | ز | з (зә) |
| ـژ | ـژ | ژ | ژ | ж (жэ) |
| ـس | ـسـ | سـ | س | с (син) |
| ـش | ـشـ | شـ | ش | ш (шин) |
| ـص | ـصـ | صـ | ص | с (съад) |
| ـض | ـضـ | ضـ | ض | з (зъад) |
| ـط | ـطـ | طـ | ط | т (тый) |
| ـظ | ـظـ | ظـ | ظ | з (зый) |
| ـع | ـعـ | عـ | ع | г (гәйн) |
| ـغ | ـغـ | غـ | غ | г (гъайн) |
| ـف | ـفـ | فـ | ف | ф (фи) |
| ـق | ـقـ | قـ | ق | к (къаф) |
| ـك | ـکـ | کـ | ك | к (кәф) |
| ـگ | ـگـ | گـ | گ | г (гәф) |
| ـل | ـلـ | لـ | ل | л (ләм) |
| ـم | ـمـ | مـ | م | м (мим) |
| ـن | ـنـ | نـ | ن | н (нүн) |
| ـه | ـهـ | هـ | ه | h (hи) |
| ـو | ـو | و | و | уау |
| ـۋ | ـۋ | ۋ | ۋ | в (вау) |
| ـی | ـیـ | یـ | ی | й (йай) |

## 1 нче дәрес

Гарәп алфавитында 28 хәреф бар, һәр хәрефнең дүрт төрле язылышы бар, аларны «шәкел» дип атыйлар. Гарәп әлифбасына нигезләнгән татар язуы уңнан сулга таба языла һәм шул тәртиптә укыла да. Китап һәм журналлар да хәзерге уку-язу системасына күнеккән кеше күзлегеннән караганда «кире яктан» укыла башлый. Баш хәрефләрнең юклыгы – гарәп графикасының тагын бер үзенчәлеге ул.

Татарларда кулланылган гарәп хәрефләренең исемнәре гарәп теле алфавитындагы әйтелешләреннән аерыла.

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| а, ә | ﺎ | ﺎ | آ | آ | әлиф |

Бу хәреф гарәп алфавитында «алифун» дип әйтелә.

«Әлиф» хәрефе туры сызыкка яисә таякка охшаган, шуңа да укый-яза белмәгән надан кешеләргә карата татар халкында «әлифне таяк дип белми» дигән гыйбарә бар. «Әлиф» хәрефе юлның өске ягында гына языла. Бу хәреф дүрт шәкелдә ике төрле формада бирелә, чөнки бу хәреф гарәп язуындагы «өзек хәрефләр»нең берсе. «Өзек хәрефләр» дип үзеннән соң хәреф кушмый торган хәрефләрне атыйлар. «Өзек хәрефләр»дән соң килә торган хәрефләр сүз башында куела торган рәвештә язылалар.

«Әлиф» хәрефе сүз башында آ «матдә» билгесе белән язылса, «а» хәрефен белдерә, сүз уртасында язылганда андый билге куелмый.

Алга таба, үзләштерүне җиңеләйтү максатыннан, бертөрле нигезле хәрефләрне төркемләп караячакбыз, бу очракта гарәп алфавиты тәртибеннән кайбер тайпылышлар да булуы мөмкин.

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| б | ﺐ | ﺒ | ﺑ | ب | би |
| т | ﺖ | ﺘ | ﺗ | ت | ти |
| <u>с</u> (сакау) | ﺚ | ﺜ | ﺛ | ث | си |
| п | ﭗ | ﭙ | ﭘ | پ | пи |

ب – «би» хәрефе ике шакмак киңлегендә, ярты шакмак биеклегендә языла. Бу хәреф, нигездә, яңгырау «б» авазын белдерә, шулай да борынгы кулъязмаларда аның саңгырау «п» авазы урынына да кулланылганлыгы мәгълүм. (Гарәп алфавитында – «бā’ун».)

ت – «ти» хәрефенең нигезе «би», «си», «пи» хәрефләренеке белән охшаш, алар бер-берсеннән бары тик нокталар саны һәм аларның урнашуы белән генә аерылалар. «Ти» хәрефе нечкә әйтелешле «т» авазын белдерә, татар сүзләрен язганда, нигездә, әлеге вариант кулланылган. Шунысын да искәртергә кирәк, гарәп теленнән кергән сүзләрдә, шулай ук кайбер татар сүзләрендә дә «т»ның башка формалары да языла, бу хакта дәреслекнең алдагы сәхифәләрендә сүз булачак. (Гарәп алфавитында – «тā’ун».)

ث – «си» – гарәп әлифбасының сакау әйтелешле хәрефе. Татар телендә мондый аваз юк. Ул гарәп теленнән кергән сүзләрне язганда гына файдаланылган, әмма кайбер татар кулъязмаларында сирәк кенә булса да татар теленең үз сүзләре составында да күрергә мөмкин. (Гарәп алфавитында – «с̱ā’ун».)

پ – «пи» хәрефе югарыдагы хәрефләрдән бары тик нокталар саны һәм аларның урыны белән генә аерыла.

«Би», «ти», «си», «пи» – өзек хәрефләр түгел, шунлыктан алар сүз уртасында, сүз ахырында үзеннән алда һәм соңыннан килгән хәрефләр белән тоташа ала.

Хәрефләрнең бер-берсе белән кушылу үзенчәлеген түбәндәге мисалларда күрергә мөмкин.

با با – баба

با ب – баб

آتا – ата

تابا – таба

باتا – бата

بات – бат

Гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар язуы (куфи һәм тәгълик дип аталган язу төрләреннән башкалары) сулга авыштырыбрак языла. Моны аеруча «әлиф» һәм «ләм» хәрефләрен язганда истә тотарга кирәк.

Язылыш тәртибенең төп кагыйдәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Башта хәрефнең нигез шәкеле языла, аннан соң гына тиешле нокталар куела. Хәрефләрне кушып язганда да, шундый ук эзлеклелекне сакларга кирәк.

2) Күп ноктaлы хәрефләрдән торган сүзләрне язганда, ике юлның берсен сайлау мөмкинлеге бар: а) әүвәл барлык нигез шәкелләрне язып чыгып, соңыннан ноктaлар кую; б) ноктaларны сүзнең бер өлешен яки бер иҗеген язып бетергәч төртеп чыгу. Каләмне кәгазьдән алмыйча языла торган сүзләрдә, әлбәттә, беренче ысулны гына куллану мөмкин.

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә өчәр юл язып кабатларга.
2. Югарыда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Тәкъдим ителгән сүзләрне гарәп графикасында языгыз:

Бата ............................ тап..........

Апа .............................

## 2 нче дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| җ | ﺞ | ﺠ | ﺟ | ج | җим |
| х (өрелмәле) | ﺢ | ﺤ | ﺣ | ح | хи |
| х | ﺦ | ﺨ | ﺧ | خ | хы |
| ч | ﭻ | ﭽ | ﭼ | چ | чи |

«Җим», «хи», «хы», «чи» хәрефләренең нигезе бер-берсенә охшаш, алар бары тик ноктала белән генә аерыла. Әлегә кадәр өйрәнелгән хәрефләрдән аермалы буларак, аларның аерым һәм сүз ахырында язылуы юл өстендә башланып, юл астында тәмамлана.

ج – «җим» татар телендәге «җ» авазын белдерә. Аерым һәм сүз ахырында язылганда, ярты шакмак юл өстендә, бер шакмак ярым юл астында языла, димәк, биеклеге 2 шакмак зурлыгында, киңлеге исә 1 шакмакка тигез була. Сүз башы һәм сүз уртасында – биеклеге – ярты, киңлеге бер шакмак. Аңа охшаш башка хәрефләр дә шул рәвешле языла. (Гарәп алфавитында – «джӣмун».)

ح – «хи», خ – «хы» хәрефләре бары тик гарәп телендә генә бер-берсеннән аерылалар. ح – «хи» – өрелмә хәреф, ә خ – «хы» – каты әйтелешле хәреф, татар телендә исә алар арасындагы аермага әллә ни игътибар ителмәгән, татар сүзләрен язганда, аларның кайсын сайлаганда да зур хата булмас. (Гарәп алфавитында – «хā’ун».)

چ – «чи» татар телендәге «ч» авазын белдерә.

Хәрефләрнең бер-берсе белән кушылу үзенчәлеген аңлау өчен түбәндәге сүзләргә игътибар итегез.

| | |
|---|---|
| حا تا – хата | با جا – баҗа |
| تا ج – таҗ | جا تا – җата |
| حا ج – хаҗ | تا ختا – тахта |

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, ун сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.

## 3 нче дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| д | د | د | د | د | дәл |
| з̱ | ذ | ذ | ذ | ذ | з̱әл |
| р | ر | ر | ر | ر | ра |
| з | ز | ز | ز | ز | зәйн |

Югарыда бирелгән хәрефләр барысы да өзек хәрефләр, ягъни алар үзләреннән соң хәреф кушмыйлар.

د – «дәл» хәрефе яңгырау «д» авазын белдерү өчен кулланыла. (Гарәп алфавитында – «дāлун».)

ذ – «з̱әл» хәрефе «дәл» хәрефе кебек үк юл өстендә языла. Бу хәреф татар телендә сирәк кулланыла, ул күбрәк саф гарәп сүзләрен язганда файдаланыла. «З̱әл» әйтелеше белән кайбер татар диалектларында очрый торган «д» белән «з» арасындагы авазны аңлата. (Гарәп алфавитында – «з̱āлун».)

ر – «ра» татар телендәге «р» авазын белдерү өчен кулланыла. Язганда, юл өстендә шакмакны яртысы биеклегендә башланып, түбәнгә таба бер шакмакка якын озынлыкта языла. Хәрефнең башланган өлеше калынрак, ә түбәнгә таба нәзегрәк итеп эшләнелә. (Гарәп алфавитында – «рā’ун».)

ز – «зәйн». Татар телендә ачык «з» хәрефен күрсәтү өчен иске татар язуында күпчелек очракларда әлеге хәреф кулланылган. Язылыш тәртибе белән ул нәкъ «ра» хәрефе кебек, күренгәнчә, ул бары тик нокта белән генә аерыла. (Гарәп алфавитында – «зā’ун».)

Хәрефләрнең кушылу үзенчәлеге һәм сүзләр ясауда кулланылу тәртибен түбәндә китерелгән мисаллардан күзәтергә мөмкин.

زار – зар
بار – бар
تار – тар
باز – баз
بازار – базар
تاراتا – тарата
تازا – таза
آربا – арба

*Биремнәр:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, ун сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.

# 4 нче дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| с | س | سـ | سـ | س | син |
| ш | ش | شـ | شـ | ش | шин |
| ç | ص | صـ | صـ | ص | съад |
| з | ض | ضـ | ضـ | ض | зъад |
| т | ط | ط | ط | ط | тый |
| з | ظ | ظ | ظ | ظ | зый |

س – «син» саңгырау «с» авазын белдерә. Язганда иң элек хәрефнең өске өлеше, ягъни «сәнәк» формасы язылa. Бу хәреф юл өстендә башланып, юл астында тәмамлана. «Сәнәк» өлешенең биеклеге ярты шакмак, «койрык» өлеше юл астына бер шакмак тирәсе төшә. Сүз башы һәм уртасында аның бары тик өске өлеше генә язылa. (Гарәп алфавитында – «сӣнун».)

ش – «шин» хәрефе «син» кебек үк язылa, аңардан бары тик нокталары белән генә аерылa. Ул – саңгырау «ш»ны белдерүче билге. (Гарәп алфавитында – «шӣнун».)

ص – «съад» каты «с» авазын белдерә. Язылуы юл өстендә башланып, юл астында тәмамлана. Хәрефләр белән ике яктан да тоташа ала. (Гарәп алфавитында – «ҫāдун».)

ض – «зъад» каты әйтелешле «з» авазын белдерә. Язылышы «съад»ныкы кебек үк, бары тик өскә куелган бер нокта белән генә аерылa. (Гарәп алфавитында – «д̣āдун».)

ط – «тый» калын әйтелешле «т» авазын белдерү өчен кулланыла. Хәреф тулысынча юл өстендә языла, алдан нигезе, аннан өстән аска таба «таягы» языла. Хәрефнең биеклеге ике шакмак, киңлеге бер шакмак зурлыгында. (Гарәп алфавитында – «тā'ун».)

ظ – «зый» калын әйтелешле «з» авазын белдерү өчен кулланыла. Аны шулай ук гарәп алынмаларын язганда кулланганнар (*залим, золым* һ.б.). (Гарәп алфавитында – «з̣ā'ун» .)

Бу хәрефләрнең берсе дә өзек хәреф түгел, димәк, алар үзләреннән алда килгән хәрефләргә кушылалар һәм үзләре дә хәрефне кушалар. Күренгәнчә, берничә «с», «т», «з» барлыкка килде. Бу дәрестә бирелә торган ص, ض, ط, ظ хәрефләре, нигездә, татар әдәби теленә гарәп теленнән кергән сүзләрне язганда кулланылган. Шулай да, язу

практикасында аларның саф татар сүзләрен язганда да кулланылулары күренә, ләкин кайсы очракта кайсын язуы хакында аерым кагыйдә юк. Гадәттә, ط – тый, ص – съад, ض – зъад, ظ – зый каты «т», «с», «з» ны белдергәндә язылган. Иске татар язуында, нигездә, «з»ны – ز, «с»ны – س, «т»ны ت белән язганнар.

Югарыдагы хәрефләрне кулланып язылган мисаллардан, бу хәрефләрнең язылу һәм бер-берсенә кушылу үзенчәлеген күрергә мөмкин.

ساتتار – Саттар

ساتا – сата

تا ش – таш

باش – баш

شار –шар

حات – хат

حافظ –Хафиз

Игътибар итегез: сүздә ябык иҗекләрдә кыска «ы», «е» булганда, гарәп хәрефләре белән язганда, ул төшеп кенә кала, ягъни язуда күрсәтелми.

تابش – табыш

تش – теш

بارش – барыш

تشتا – тышта

بر – бер

Җөмлә язганда сүзләрнең язылу тәртибенә игътибар итегез:

ساتتار بازاردا شار ساتا – Саттар базарда шар сата.

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Бирелгән сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

| | |
|---|---|
| Сабыр .............................. | Саба ................................ |
| Аш ашата ......................... | Саташа ............................ |
| Тышта .............................. | Пычрата .......................... |
| Сара ................................ | Шапырдата ...................... |

# 5 нче дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| гъ (өрелмә) | ـع | ـعـ | عـ | ع | ‘әйн |
| гъ | ـغ | ـغـ | غـ | غ | гъайн |
| ф | ـف | ـفـ | فـ | ف | фи |
| къ | ـق | ـقـ | قـ | ق | къаф |

Иске татар язуында ع – «‘әйн» һәм غ – «гъайн» хәрефләре арасында артык аерма булмаган, бу аерма фәкать гарәп телендә генә бар. Шулай да кайбер язмаларда ع – «‘әйн» өрелмәле, йомшаграк әйтелешле авазны билгели, ә غ – «гъайн» катырак әйтелешле авазны белдерә. «Агач», «быргы», «сугу», «гозер» кебек сүзләрне язганда, нәкъ менә шул «гъайн» хәрефен кулланганнар.

Бу хәрефләр, юл өстендә языла башлап, юл астында тәмамлана. Алдан өске өлеше ярты шакмак биеклегендә языла, аннан бер шакмак ярым юл астындагы өлеше языла. Алар өзек хәрефләр түгел, ике яктан да тоташа алалар. (Гарәп алфавитында – «‘айнун», «гайнун».)

ف – «фи» «ф» авазын белдерә. Югарыга түгәрәкләп ярты шакмак биеклегендә, киңлеккә ике шакмакка сыйдырылып языла. (Гарәп алфавитында – «фā’ун».)

ق – «къаф» каты әйтелешле «к» авазын белдерә. «Казан», «кар», «сукыр» һ.б. сүзләрне язганда, «к»ның әлеге варианты кулланыла. Беренче карашка «фи» хәрефен хәтерләтсә дә, аларның язылыш рәвеше аерыла. «Фи» юл өстендә генә языла, ә «къаф»ның аерым һәм сүз азагында язылышы юл өстендә башланып, бер шакмак тирәсе юл сызыгы астына төшеп, «койрыгы» юл өстендә тәмамлана. (Гарәп алфавитында – «кāфун».)

Хәрефләрнең кулланылышын түбәндәге мисалларда күзәтегез:

تاراف – тараф

فاش – фаш

آ غارتا – агарта

آق – ак

قاداق – кадак

قاشقا آت قارغا باتا – кашка ат карга бата.

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Бирелгән сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

Чага........................... саф............................

Балачак..................... шарф.........................

Кала .......................... тарак .........................

Казан ........................ тагарак.......................

Кар............................ кара карга..................

Гата........................... катык ........................

Агач капка................ Такташ.......................

Кабак.........................

Сара кар тарата.........................................................................

Гата кадак кага..........................................................................

Кара тактада ак сызык бар ...............................................................

## 6 нчы дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| кь | ك ک | ک | ک | ک ك | кәф |
| г | ك | گ | گ | گ | гәф |
| л | ل | ﻟ | ﻟ | ل | ләм |
| м | م | ﻤ | ﻣ | م | мим |

ک ك – «кәф»нең ике төрле формасы бар. Ул йомшак «к» авазын белдергәндә кулланыла торган хәреф. Мәсәлән, кәтүк, көн, кич, күз, пәке һ.б шундый сүзләрне язганда «кәф» куела. Бу хәреф юл өстендә генә языла, һәм аның биеклеге – ике шакмак, киңлеге бер шакмак тирәсе.

گ – «гәф» – йомшак әйтелешле хәреф. Мәсәлән, «гүзәл», «тигез», «түгәрәк» кебек сүзләрдә «г» хәрефен «гәф» белән язалар. Борынгы кульязмаларда сирәк кенә булса да گ урынына ک хәрефен генә язу да очрый. Язылу рәвеше нәкъ «кәф» хәрефенә охшаган, бары тик өске өлешендә параллель сызык кына бар.

ل – «ләм», م – «мим» хәрефләренең сүз ахырында һәм аерым языла торган формалары, юл өстендә башланып, юл астында тәмамланалар, ә сүз уртасында һәм сүз башында языла торган формалары һәрвакытта юл өстендә язылалар. (Гарәп алфавитында – «ла̄мун», «мӣмун».)

«Ләм» хәрефенең «әлиф» белән ялгануы үзенчәлекле: «ла» иҗеген язу өчен махсус билге кулланыла.

لا – ла ﻼ – ла

Бу рәвештә язылган иҗектән соң килгән хәреф кушылып язылмый, ягъни хәрефнең сүз башындагы формасы кулланыла.

Мисаллар:

بالالار – балалар

بالق – балык

قالا – кала

بال – бал

سالماق – салмак

قازان – казан

نارات – нарат

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Бирелгән сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

чамаларга................................ кабатлана...........................
тынычлык............................... ташлама.............................
чалма...................................... калдык...............................
башлана................................. кармак................................
шалкан.................................... салкын...............................
җаным..................................... чынлык..............................
Ана балаларга бал сатып ала .............................................................

# 7 нче дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| н | ـن | ـنـ | نـ | ن | нүн |
| һ | ـه ـﻪ | ـهـ | هـ | ه | һи |

ن – «нүн» «н» авазын белдерә. Бу хәреф, юл өстендә ярты шакмак биеклегендә башланып, юл астына бер шакмак тирәсе төшеп, юл өстендә тәмамлана. Сүз башы һәм сүз уртасында килгәндә, бары тик юл өстендә генә языла. Өзек хәреф түгел – ике яктан да хәрефләр белән тоташа. (Гарәп алфавитында – «нӯнун».)

ه – «һи» хәрефе (гарәп алфавитында – «xā'ун») «һава», «һәр», «һәм» кебек сүзләрне язганда кулланыла. Аерым, сүз башы һәм сүз ахырындагы рәвешләре юл өстендә башкарыла, ә сүз уртасында ярты шакмак юл өстендә, ярты шакмак юл сызыгы астында языла. Таблицадан күренгәнчә, сүз ахырындагы язылышы – ике төрле формада. «Һи» хәрефе алдыннан килә торган хәреф белән кушылса, ул ـﻪ формасында языла, ә инде аның алдында өзек хәреф булса– ه формасы кулланыла.

Мисал: شاه – шаһ

ه хәрефе иске татар язуында «ә» авазы билгесе булып йөри, һәм бу очракта ул өзек хәрефкә әйләнә. Мисалларга игътибар итегез:

ته رته – тәртә

خه ته ر – хәтәр

هه ر – һәр

شه هه ر – шәһәр

مه رته به – мәртәбә

ده ره جه – дәрәҗә

Сүз башындагы «ә»не күрсәтер өчен «һи»нең ـﻪ формасына «теш» өстәп, өстенә «һәмзә» – ء билгесе куела. Мисалларга игътибар итегез:

ئه ته چ – этәч

ئه ره مه – әрәмә.

Кайбер очракларда сүз башындагы «ә» хәрефен «әлиф» өстенә «фәтхә» билгесе куеп күрсәтәләр. Мисаллар:

اَره مه– әрәмә

اَ ته چ – әтәч

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Һәр хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыдагы мисалларда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Бирелгән сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

Нарат....................................... надан.................................

Ана........................................... нарзан ..............................

Нахак...................................... наказ..................................

Наласа.................................... нык.....................................

Балалар Казанга баралар .........................................................

Бакчада нарат бар...................................................................

## 8 нче дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| w | و | و | و | و | waw |

و хәрефе (гарәп алфавитында – «ўāўун») – өзек хәреф, үзеннән соң хәреф кушмый. Язылышы юл өстендә башлана, түгәрәкләнеп юл астында тәмамлана. Бу хәреф, сүздә килгән урынына карап, төрле авазларны белдерә:

1) Сүз һәм иҗек башында, сузык авазлар алдыннан «в» («w») булып укыла:

وات – ват

واق – вак

سالاوات – Салават

آ ول – авыл

تاوش – тавыш

2) Сүз башында «у», «ү», «о», «ө» булып укылсын өчен, аның алдына, ягъни уң ягына, «әлиф» куела.

Мисаллар:

اوراق – урак

اورال – урал

اوس – үс

اور – ур, үр

اولان – улан, олан.

3) Сүз уртасында яки ахырында килгәндә, «у», «ү», «о», «ө» булып укыла:

سول – сул

بولو – булу, бүлү

توز – тоз, төз, туз, түз

قول – кул, кол

باو – бау

اورلاو – урлау

Мисаллардан күренгәнчә, و хәрефе кергән бертөрле язылышлы сүзләрне төрлечә укып була. Бу – гарәп графикасындагы иске татар теленең иң мөһим үзенчәлекләреннән һәм шул ук вакытта

җитешсезлекләреннән берсе. Сүзләрнең укылышын күп очракта сүз сөрешеннән (контексттан) чыгып кына аңлап була.

و хәрефенә охшаш ۋ хәрефе ачык «в» авазын белдерә. Бу хәрефнең язылыш тәртибе و – «waw» хәрефенеке кебек үк, бары тик өстенә куелган өч нокта белән генә аерыла. ۋ хәрефен рус теленнән кергән сүзләрне язганда кулланалар.

Мисаллар:

ۋازا – ваза

آۋار – авар (халык исеме)

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыдагы мисалларда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Түбәндәге сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

Урталык................................. тукталыш....................

Матур..................................... туган............................

Кабатлау................................ урман..........................

## 9 нчы дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| и, й | ى | ﻴ | ﻳ | ى | йай |

ى – «йай» хәрефе (гарәп алфавитында – «йā’ун») сүздә төрле урыннарда килүенә карап, калын сүзләрдә – «и», «йы», «ый», «ы», нечкә сүзләрдә «и», «йе, «ий», «е» булып укыла:

1) Сүз башында «и» булып укылсын өчен, аның алдына «әлиф» куела:

ايكمه ك икмәк, ايسه ن исән, ايمه ن имән, ايل ил

2) Сүз уртасында килгәндә, «и» булып укыла:

تيز – тиз, بيش – биш

3) «Әлиф» белән кушылганда, «я» – «йа» авазын белдерә:

يالقن – ялкын, يازا – яза

4) «Waw» белән кушылып, «ю» – «йу», яисә «йо» авазларын аңлата:

يوقا – юка, يول – юл, يون – йон, يوزاق – йозак

5) Сүз яки иҗек башындагы «е» – «йы» авазын белдерә:

يلان – елан, يل – ел, يراق – ерак, اويـن – уен

6) ى – «йай» хәрефе «а», «о», «у» – «ә», «ө», «ү» сузыкларыннан соң килсә һәм артыннан башка сузык аваз булмаса, кыска «й-и» булып укыла:

تاى – тай, ساراى сарай, بوى буй

7) Сүз һәм иҗек уртасында, сүз ахырында тартыклардан соң килгәндә, «ый», «ы», «и (ий)», «е» булып укыла:

آ ليق – алыйк باريق – барыйк ياتتى – ятты بلدى – белде

Кайбер очракларда, бигрәк тә борынгырак язмаларда, сүз башындагы «әлиф» һәм «йай» кыска «э» авазын аңлаталар. Мәсәлән, ايش – эш, ايت – эт, ләкин күпчелек очракта сүз башындагы кыска «э» яки «ы» авазларын күрсәтер өчен бары тик «әлиф» куелган: اش – эш, ات – эт, رعاق – ыргак.

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Хәрефнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.

2. Югарыдагы мисалларда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.

3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.

4. Бирелгән сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

| | |
|---|---|
| Читек............................. | чаян......................... |
| Белик............................. | килик...................... |
| Китте............................. | китек...................... |
| Яфрак............................ | юксыну.................. |
| Ерткыч.......................... | куян........................ |
| Сатты............................ | керде....................... |
| Сизде............................. | ишек........................ |
| Йомшак......................... | куен......................... |
| Ашый............................ | тапты....................... |
| Белде............................. | керде....................... |

Куян кишер кимерә..........................................................................

Бабай читек кия...............................................................................

Йорт ишеге ачык..............................................................................

Әти аш ашый.....................................................................................

Әни ашарга пешерә...........................................................................

# 10 нчы дәрес

| Хәрефнең әйтелеше | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Аерым язылышы | Хәрефнең исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| ң | ڭ ڭ | ڭ | - | ڭ | ңэ |
| ж | ژ | ژ | ژ | ژ | жэ |

Бу хәрефләр классик гарәп әлифбасында юк.

ڭ – «ң» башка хәрефләрдән төрлечә язылуы белән аерылып тора. Ул аерым килгәндә – ڭ, ә сүз ахырында ڭ рәвешендә язылырга мөмкин. Борынгы текстларда «ң» хәрефен күрсәтер өчен «нүн» – ن һәм «кәф» – ک хәрефләрен кушып язганнар – نک.

ژ – «жэ» хәрефе асылда башка телләрдән (рус һәм Көнбатыш Европа телләреннән) кергән сүзләрдә языла.

Мисаллар: ژ ورنال – журнал ژ يراف – жираф

ژ – «жэ» хәрефе өзек хәреф.

Бу алфавитта булган өзек хәрефләр: ه – ه د آ ذ ر ز ژ و

Иске татар язуының 1917 елга кадәрге чорда гамәлдә булган һәм фәндә «иске имля» дип аталган әлифбасы шуның белән тәмамлана, ләкин иске язуыбызда шактый сирәк очрый торган ике ясалма хәреф бар, аларның берсе – ۋ – «в», икенчесе – ڨ – «w». Соңгысының язылу рәвеше ق – «каф» хәрефенә охшаган, бары тик ноктасы өчәү. Бу хәреф өзек түгел, ул бик сирәк, бары тик борынгы кулъязмаларда гына очрый.

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Хәрефләрнең һәр шәкелен шакмаклы дәфтәрдә бишәр юл язып кабатларга.
2. Югарыдагы мисалларда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
3. Өйрәнелгән хәрефләрне кулланып, биш сүз уйлап, дөрес, каллиграфик яктан матур итеп язарга.
4. Бирелгән сүзләрне гарәп хәрефләре белән языгыз:

Журнал………………. хәрәкәт...................

Жираф………………. һава......................

Һаман ………………. гүзәл………………

Соңрак……………… кыңгырау…………

Күгәрчен…………… сызгырган…………

Сизгер……………… карлыган…………..

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканын белсә. (Г.Тукай)

..............................................................................................................................

..............................................................................................................................

# 11 нче дәрес

## Хәрәкәләр

Классик гарәп алфавитында бары тик өч хәреф кенә сузык һәм ярым сузыкларны белдерә (ا ى و). Грамматик формасының нигезендә өч тартыклы тамыр яткан гарәп язуындагы кыска сузык авазлар вазифасын «хәрәкә» дип аталган ярдәмче билгеләр үти. Алар хәрефнең өстенә яки астына куела. Шунысын да әйтергә кирәк, хәрәкәләр иске татар язуында гына түгел, гарәпләрнең үзләрендә дә аз кулланылган. Татарлар хәрәкәләрне, башлыча, Коръәнне күчереп язганда яки басканда, догалыклар язганда, әлифба китапларында һәм кайбер очракта язуга декоратив төсмерләр бирергә теләгәндә (мәсәлән, шәмаилләрдә) кулланганнар. Әмма укырга-язарга өйрәнү процессында хәрәкәләрнең язудагы вазифасын истә тоту зарури, чөнки иске язуда берничә сүзнең язмада бер үк хәрефләр белән генә бирелгән очраклар бар. Мәсәлән, توز сүзен дүрт төрле: тоз, төз, туз, түз дип, مهر – мәһәр, мөһер дип укып була. Мондый сүзләрнең укылышын укучы бары тик сүз сөрешеннән генә аңлый алган. Бу хәл, ягъни күп вариантлылык, сүзләрнең мәгънәләрен бутау куркынычын тудыра. Мондый очракта хәрәкәләр кую мәгънә буталчыкларыннан саклап кала.

*Фәтхә* __ татар телендә «а», «ә» кыска сузык авазын белдерә. Ул хәрефнең өстенә кыска сызык рәвешендә языла.

*Кәсрә* __ татар телендә «и», «е», кыска сузык авазларын белдерә.

*Замма* __ татар телендә «у», «ү», «о», «ө», «е», «ә» кыска сузык авазларын белдерә.

*Сәкен* __ тартык авазны белдерүче хәреф өстенә куела һәм тартыкның һичнинди сузык авазны кабул итмәвен, иҗекнең ябык икәнлеген күрсәтә.

*Тәшдид* __ тартык авазны белдерүче хәреф өстенә куела һәм тартык авазны ике итеп укырга кирәклеген күрсәтә.

*Һәмзә* ء сузык авазны өзеп, кисеп әйтүне, иҗек башындагы сузык алдыннан яки иҗек ахырындагы сузыктан соң тамак төбе белән әйтелә торган үзенчәлекле тартыкны белдерә.

*Матдә* ~ билгесе «әлиф» (ا) хәрефе белән кулланыла һәм «әлиф»не – «а» авазын озынайту өчен хезмәт итә (آ).

Гарәп телендә генә һәм нигездә тартыклардан гына торган сүзләрне уку өчен язуда кулланыла торган хәрәкәләр «тәнвиннәр» дип атала. Аларның төп вазифасы – сүзнең кайсы килештә килгәнлеген күрсәтү һәм нинди дә булса кыска сузык белән берлектә «н» авазын белдерү.

*Бирем:*

Хәрәкәләрне дөрес итеп куеп, түбәндәге сүзләрне языгыз:

1. Тәрҗемә, мәдрәсә, дәфтәр, Мөхәммәд, тәккәбер, мөкаддәс, тәвәккәл, мөэмин, мәсьәлә, тәэмин, тәэсир, афәт, ахир, аһәң, мәктәб, мәҗлес, риза, морад, корбан, бөстан, мәхрүм, мәхбүс, мәркәз, мөхәррәм, мөгаллим.
2. 3 нче кушымтада 152 нче биттә бирелгән хәрәкәле сүзләрне укыгыз.

## 12 нче дәрес

## Саннар

Бу дәрестә иске гарәп язуында кулланылган саннарның бирелү рәвеше һәм язылу үзенчәлекләре каралачак.

Иске язуда кулланыла торган «гарәп саннары» гарәпләр үзләре куллана торган саннардан шактый аерылып торалар. Гарәпләр үзләре аларны «һинди саннары» дип атаганнар.

Алар түбәндәгеләр:

**١ – 1 ٢ – 2 ٣ – 3 ٤ – 4 ٥– 5 ٦ – 6 ٧ – 7 ٨ – 8 ٩ – 9 ١٠ – 10**

Дүртле санының ике төрле варианты бар. Кулъязма шәкеле ۴ языла, ә басма текстларда ул ٤ рәвешендә куела.

Игътибар итегез: гарәп язуындагы хәрефләр, сүзләр уңнан сулга таба язылса да, саннар хәзерге язудагыча, сулдан уңга таба язылалар. Мәсәлән, 1917 – ١٩١٧, 1945 – ١٩٤٥. Еллар аралыгын күрсәткәндә, санның билгеләре уңнан сулга таба куела, ә укылышы яисә хронологик тәртибе язу уңаена, ягъни уңнан сулга таба языла. Бөек Ватан сугышы булган еллар түбәндәгечә күрсәтелә: 1941–1945 ١٩٤٥ _ ١٩٤١

عبدالله توقاي ١٨٨٦ نچى يلدا توعان – Габдулла Тукай 1886 нчы елда туган.

١٩١٣ نچى يلدا وافات بولعان – 1913 нче елда вафат булган.

Гарәп язуында саннар урынына хәрефләр куллану очраклары да бар. Гарәп әлифбасының һәр хәрефе билгеле бер санны белдерә. Моны «әбҗәд исәбе», дип атыйлар. Бу бигрәк тә астрономия, математика һәм хронологиядә киң таралган.

| | | |
|---|---|---|
| 1 – ا | | |
| 2 – ب | 20 – ک | 200 – ر |
| 3 – ج | 30 – ل | 300 – ش |
| 4 – د | 40 – م | 400 – ت |
| 5 – ه | 50 – ن | 500 – ث |
| 6 – و | 60 – س | 600 – خ |
| 7 – ز | 70 – ع | 700 – ذ |
| 8 – ح | 80 – ف | 800 – ض |
| 9 – ط | 90 – ص | 900 – ظ |
| 10 – ى | 100 – ق | 1000 – غ |

Бу хәрефләрне истә калдыру җиңел түгел, аларны шартлы рәвештә ясалма сүзләргә берләштереп ятлау гадәткә кергән. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә укучы шәкертләр аларны нәкъ гарәпләрдә кабул ителгән тәртиптә ятлый торган булганнар. Бердән меңгә кадәрге саннарны белдерүче хәрефләр сигез ясалма сүзне тәшкил итәләр. Алар берничек тә тәрҗемә ителмиләр. Түбәндәге сүзләр: әбҗәд, һауз, хотти, кәләмин, сәгъфас, карашат, сәххаз, дадыйгъ (зазыйгъ).

Әбҗәд исәбе хәрефләре – кайбер тарихи вакыйгаларны белдерү өчен дә кулланылган.

**Атна исемнәренең бирелеше:**

Гарәп илләрендә, шул исәптән барлык мөселман илләрендә дә, атна шимбә көннән башлана:

يوم السب *йәүмүс-сәбти – шимбә*
يوم الاحد *йәүмүл-әхәд – якшәмбе*
يوم الاثنين *йәүмүл-иснәйни – дүшәмбе*
يوم الثلاثاء *йәүмүс-сүләсә-и – сишәмбе*
يوم الاربعاء *йәүмүл-әрбәгъә-и – чәршәмбе*
يوم الخميس *йәүмүл-хәмиси – пәнҗешәмбе*
يوم الجمعة *йәүмүл-җомгъәти – җомга.*

Татарлар хәзерге вакытта көндәлек тормышта фарсы теленнән кергән көн исемнәрен файдалана, ә ай исемнәре исә Европа һ.б. халыклардагы кебек. Ләкин татар халкының гарәп календареннан да файдаланган чагы булган. Ул бүген дә татарларның дини календарьларында файдаланыла. Халык арасында кайбер ай исемнәренең әле дә яратып кулланылганлыгы күренә, алар бүген дә мөселман халыкларының бәйрәмнәрен гарәпчә атап йөртәләр: Мөхәррәм, Сәфәр, Рәбигъ әл-Әүүәл, Рәбигъ әс-Сәни, Җөмадәл Әүүәл, Җөмадәл Әхира, Рәҗәб, Шәгъбан, Рамазан, Шәүүәл, Зүл Кагъдә, Зүл Хиҗҗә.

*Саннарның язылышын өйрәнүне ныгыту өчен күнекмәләр:*

1. Саннар кулланып, үзегезнең автобиографиягезне языгыз.
2. Түбәндә биреләчәк вакыйгаларның датасын языгыз:

Һуннар дәүләтенең яшәү чоры (еллары).

Төрки каһанлыгының оешу елы.

Идел буе Болгар дәүләтенә Багдадтан гарәп илчелегенең килүе һәм дәүләттә рәсми рәвештә ислам динен кабул итү елы.

Болгар дәүләтен монголларның яулап алу елы.

Алтын Урда дәүләтенең төзелү елы.

Алтын Урдада Үзбәк хан идарә иткән еллар.

Алтын Урдада рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү датасы.

Казан ханлыгының Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан яуланып алыну елы.

Казан университеты ачылу елы.

Рус-япон сугышы башлану елы.

Беренче Бөтендөнья сугышы булган еллар.

## 13 нче дәрес

## Иске татар язуының кайбер үзенчәлекләре

Бу дәрестә гарәп хәрефләренә нигезләнгән язуыбызның кайбер үзенчәлекләре турында сүз барачак.

1) Иске китапларда һәм кулъязмаларда «-нар», «-нәр» күплек кушымчаларын һәрвакытта «-лар», «-ләр» لار لر рәвешендә язганнар. Мәсәлән, «килгәнләр», дип языла, ә «килгәннәр» дип укыла.

Кайвакытта لر - кушымчасын сүз тамырыннан аерып язганнар. Мисаллар:

سان لر سانلر – саннар

تاتار لر – татарлар

بارعانلر بارعان لر – барганнар

آعاچلر آعاچلر – агачлар

چهچكلر چهچهك لر – чәчәкләр

2) Килеш кушымчалары язылышындагы кайбер үзенчәлекләр.

Хәзерге язу кагыйдәләре буенча, сүзләрдәге саңгырау авазлардан соң килгән «-ты», «-те», «-та», «-тә», «-тан», «-тән» кушымчалары иске татар язуында «-ды», «-де», «-да», «-дә», «-дан», «-дән» рәвешендә язылганнар. Мәсәлән:

قيتدى – кайтты

آ تدا – атта

باسدر – бастыр

تورتدر – төрттер

Юнәлеш килеш: «-га», «-гә», «-ка», «-кә»

| *Язылган* | *Укыла* |
|---|---|
| آ تعا – атга | атка |
| مكتبگه – мәктәбгә | мәктәпкә |

3) Кайбер очракларда аңлаешлырак булсын өчен кыска «-ы», «-е» урынына و хәрефе язылган:

بارور – барыр

بيرور – бирер

قارشوندا – каршында

حورمه تلو – хөрмәтле

قايتورمون – кайтырмын

Сүз башындагы «-ы» хәрефенә бу кагыйдә кагылмый. Сүз башындагы «-ы» хәрефен «әлиф» (ا) ярдәмендә күрсәтелгән.

اندر – ындыр

ارعاق – ыргак

الس – ылыс

ارو – ыру

ارم – ырым

4) Сүз башындагы «әлиф» (ا) хәрефе төрле авазны белдерергә мөмкин.

«Ы» авазын белдерүе югарыда каралды, моннан тыш:

«И» авазын белдерә.

اعانه – иганә

اداره – идарә

اتفاق – иттифак

افرات – ифрат

اختيار – ихтыяр

«Ә» авазын белдерә:

اعظا – әгъза

اعلا – әгъла

البته – әлбәттә

اما – әмма

«Э» авазын белдерә:

الوك – элек

استرلی تاماق – Эстәрлетамак

ات – эт

اش – эш

از – эз

المەك – элмәк

«О» авазын белдерә:

الوع – олуг

الی – олы

«Ө» авазын белдерә:

الش – өлеш

5) Иске татар теленең тагын бер үзенчәлеге: фигыльләрдә «-мак», «-мәк» кушымчаларының язылуы. Мәсәлән:

آ شامق – ашамак

قايتماق – кайтмак

6) Хәзерге татар телендә кулланылышта булган «-гыз», «-гез» кушымчаларын иске язуда еш кына ڭز итеп күрсәткәннәр, ә «-быз», «-без» кушымчаларын – مز итеп.

Мисаллар:

بارسا ڭز – барсаңыз (барсагыз)

قاريمز – карыймыз (карыйбыз)

*Дөрес, матур язу күнекмәләре булдыру өчен бирем:*

1. Югарыдагы мисалларда бирелгән сүзләрне икешәр юл язарга.
2. Текстны гарәп хәрефләре белән языгыз:

Тау башыннан салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән.
Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем. *(Г. Тукай.)*

Кем белер кадереңне, җаным, дәртле күңел булмаса?
Наз итәр кемнәргә гөл, каршында былбыл булмаса?
Сурәтеңнең иң чыны, бел, шагыйрең күңлендәдер.
Күзгеләрдән чын төсеңне күрмисең, ул булмаса. *(Г. Тукай.)*

# 14 нче дәрес

Бу дәрестә дә иске татар язуының кайбер үзенчәлекләрен карауны дәвам итәбез.

1) 1917 елга кадәр басылган китапларда һәм кулъязмаларда хәзерге вакытта телдән төшеп калган сүзләр һәм кайбер сүзләрнең искечә язылган формалары белән очрашырга туры килә. Мәсәлән:

«кебек» дигән сүзне کبی – «кеби» дип язганнар.

«белән» – برلن яки اله – «илә»,

«булсын» – اولسون – «улсын»

«булды» – اولدی – «улды»

2) Сүз башындагы «м» урынына «б» хәрефен кую очрый:

بوندا – бунда (монда)

«б» хәрефе урынына «в» («w») кую:

وار – вар (бар)

واراچاق – варачак (барачак)

ویردی – вирде (бирде)

«т» урынына «д» кую:

دوش – дөш (төш)

دگل – дәгел (түгел)

3) Шулай ук иске текстларда хәзерге язуда еш кына ике төрле язылышта йөри торган сүзләр очрый. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| یفەك – ефәк | جفەك – җефәк |
| یگت – егет | جگت – җегет |
| یلقی – елкы | جلقی – җылкы |

4) «Җил», «җир», «җимеш» кебек сүзләр еш кына йил, йир, йимеш рәвешендә язылган:

| | |
|---|---|
| جیر – җир | ییر – йир |
| جیل – җил | ییل – йил |
| چیمش – җимеш | ییمش – йимеш |

4) Борынгы текстларда бәйләүче ярдәмлекләрнең бирелеше хәзерге язудагыдан аерылып тора. Аларның иң еш очрый торганнарының кайберләре түбәндә китерелә:

| | |
|---|---|
| و – вә | اما – әмма |
| هم – һәм | یاایسه – яисә |
| یاحود – яхуд | ینه – янә |
| بس - бәс | لکن – ләкин |
| فقط фәкать | یاکی – яки |

شويله – шөйлә гویا – гүя
حلبوکی – хәлбуки اگر – әгәр
که – ки گرچه – гәрчә
مگر – мәгәр تاکه – таки
باکه – бәлки چونکه – чөнки

5) Гарәп һәм фарсы телләреннән татар теленә кереп калган сүзләр шул тел кагыйдәләре нигезендә язылганнар. Биредә барлык сүзләрне дә китерү мөмкин түгел, мисал өчен түбәндә берничәсе тәкъдим ителә.

حير – хәер جمعا – җомга
علم – гыйлем قبلا – кыйбла
قيمت – кыйммәт شفقت – шәфкать
جوهر – җәүһәр دوا – дәва
جمعيت – җәмгыять امتحان – имтихан
عمل – гамәл حقيقت –хакыйкать
برادر – борадәр ضرور – зарур

6) Иске татар язуында тыныш билгеләре кулланылмаган диярлек. Шуңа күрә борынгы текстларда кызыл юл, сорау, өндәү билгеләре, күп нокталар, куштырнаклар, сызык һ. б. тыныш билгеләре очрамый. Татар язуы тарихында тыныш билгеләре турында беренчеләрдән булып күренекле язучыбыз Муса Акъегетзадә язып чыга. «Хисаметдин менла» исемле әсәрендә (1886 ел) ул тыныш билгеләре куюның әһәмиятен билгеләп уза. Шуннан соң К.Насыйри, Г.Госманов, Ф.Садыйков, кебек язучылар, мәгърифәтчеләр, бу эшне дәвам итеп, Октябрь революциясенә кадәр үк татар пунктуациясе кагыйдәләрен булдыруда мәгълүм эш башкаралар.

Басма китаплар һәм кулъязмаларда нокта кую рәвешләрендә кайбер аермалык бар. Мәсәлән, кулъязмаларда ике ноктаны күпчелек вакытта кыска гына сызык рәвешендә куялар (-) яки зигзагсыман иттереп язу бар. Өч ноктаны хәреф өстенә кыска сызык һәм нокта итеп яки өтер рәвешендә куялар. Урта гасыр төрки-татар кулъязмаларында кайбер хәрефләрнең ноктлары куелышында түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә. Мәсәлән, «с», «п», «г» хәрефләренең астына һәм «ш» хәрефенең өстенә вертикаль юнәлештәге икешәр нокта кую очраклары бар. Кайбер кулъязмаларда ر («р») хәрефенең астына – бер, ә س («с») хәрефенең астына өч нокта куеп язу очраклары күзәтелә.

7) Язганда, билгеле, сүзләрне юлдан-юлга күчерергә туры килә. Бу очракта ике төрле эшләргә була: а) сүзне күчергәндә, аны болай

бүлү кулайрак – беренче өлеше сулдан кушылмый торган хәрефкә тәмамланырга тиеш, мәсәлән, «артык» сүзе آر һәм تق өлешләренә бүленә, «багана» сүзе با (яки با عا ) һәм عانا (яки نا ) рәвешендә күчерелә һ. б. Әгәр сүз бер-берсенә тоташкан хәрефләрдән торса, аны бүлеп күчерү отышлы түгел һәм бу хупланмый да, чөнки болай эшләгәндә язуның гомуми тәэсире бозыла; б) күп кенә очракларда сүзне юлдан-юлга гомумән күчермәскә мөмкин. Моңа ирешү өчен юлның ахыргы сүзләрен йә сузыбрак (иске язуыбызда моңа чикләнмәгән диярлек мөмкинлекләр бар), йә, киресенчә, кыса төшеп язарга кирәк.

*Материалны ныгыту өчен бирем:*

1) Г. Тукайның «Бер татар шагыйренең сүзләре» шигыреннән өзекне гарәп хәрефләре белән язып чыгыгыз:

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.
Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү харам.

2)
Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен;
Мескин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен. (Г. Тукай, «Милли моңнар».)

## 15 нче дәрес

## Кеше исемнәренең бирелеше

Гарәп-фарсылардан кергән кеше исемнәре татар халкы арасында киң таралыш тапканнар. XVIII – XIX гасырларда хәтта саф төрки-татар исемнәре икенче планга кысрыклап чыгарыла. Бу кеше исемнәренең язылышы иске татар язуында гарәп-фарсы телләренең кануннары буенча башкарылган, ягъни ишетелгәнчә язуга нигезләнмәгән. Андый исемнәрне уку һәм язу түбәндәге кагыйдәләргә нигезләнгән:

1) Ахырында «дин» сүзе булган исемнәрдә әйтелмәсә дә, «дин» сүзе алдында ال язылган һәм, ул кушып язылганда, الدين рәвешен алган. Составында әлеге الدين булган исемнәрдә الدين алдыннан «т» авазы ишетелсә дә, ул язылмаган. Әмма хәзерге орфографиядә الدين – «аддин» дип түгел, «этдин» формасында, ягъни «т» тартыгы куеп языла: Хөснетдин, Шәйхетдин һ.б.

غين الدين – Гайнетдин علم الدين– Гыйльметдин

كمال الدين – Камалетдин سيف الدين – Сәйфетдин

علاج الدين – Гыйлаҗетдин حسن الدين – Хөснетдин

2) Ахырында «Алла» – الله сүзе булган исемнәрдә «уау» ишетелсә дә, язылмаган.

عبد الله – Габдулла عارف الله – Гарифулла

على الله – Галиулла لطف الله– Лотфулла

عطاء الله – Гатаулла عزت الله– Гыйззәтулла

3) Ике сүздән торган кушма исемнәрдә икенче сүзнең беренче хәрефе тәшдидле булганда, аның алдыннан ال язылган, ләкин ул ال укыганда әйтелмәгән. Шунысын да истән чыгармаска кирәк: кушма исемнәрдә икенче сүзнең беренче хәрефе тәшдидле булса, ягъни ул хәреф ике кат әйтелсә дә, хәзерге татар орфографиясен кагыйдәләре буенча аның берсе генә языла. Мәсәлән, Габдерахман, Габдерәшит, Габдерәзак, Габдерәхим һ.б.

عبدالرحمن – Габдерахман عبدالرحيم – Габдерәхим

4) ز ر س ت ل ن ش ث ض ص ظ ط ذ د хәрефләре «кояш хәрефләре» дип атала. Кояш хәрефләре әлифбада ундүрт. Кояш хәрефе белән башланган сүзләргә, ялгызак исемнәренә «әл» – ال артикле кушылганда ل – «ләм» хәрефе укылмаска, ә беренче хәреф икеләтеп укылырга тиеш була. Мисаллар:

الشمس – кояш

السلام – сәлам

الترتيب – тәртип

Кояш хәрефенә башланган ялгызлык исемнәренең язылышы һәм укылышы:

زين‌الدين – Зәйнеддин

شمس‌الدين – Шәмседдин

نصر‌الدين – Насреддин

Мондый сүзләргә «әл» – ال артикле кушылганда, (дөресрәге, исемнең икенче өлешенә) ل – «ләм» хәрефе йотыла, ә «дин» сүзенең беренче хәрефе икеләтеп укылырга тиеш була.

5) Ике сүздән торган кушма исемнәрдә (сүзләрдә) икенче сүз башында ل ишетелеп тә, шул ل нән соң «ай хәрефләре» дип аталган хәрефләрнең берсе килсә, шул ل алдыннан «әлиф» (ا) языла. Гарәп алфавитында **ز ر س ت ل ن ش ث ض ص ظ ط ذ د** хәрефләреннән тыш калган бөтен тартыклар «ай хәрефләре» дип аталалар.

عبدالكبير – Габделкәбир عبدالخالق – Габделхалик

عبدالحق – Габделхак

«Ай хәрефләре»нә билгелелек артикле кушылганда, алар тулысынча укылалар:

المجلس – мәҗлес الكتاب – китап

6) Гарәптән кергән кайбер исемнәр һәм сүзләр «әлиф» (ا) белән укылса да, сүз ахырында йай (ى) язылган. Мәсәлән:

عيسى – Гайса مرتضى – Мортаза

مصطفى – Мостафа موسى – Муса

دعوى – дәгъва حتى – хәтта

*Белемнәрне тикшерү өчен биремнәр:*

Текстларны гарәп хәрефләре белән языгыз:

Кояшлы язлар килә, нур белән тула дөнья,
Әйләнеп бозлар дулкынга, чабалар ярга.
Агачлар яфрак яра, кошлар коралар оя...
Шулчак йөрәк җилпенеп, күңел ашкына кая?
Туган як искә төшә, туган як искә төшә,
Сизәм мин Идел шавын искән җилдә.
Туган як искә төшә, туган як искә төшә,
Тоям мин Казан күген бөтен җирдә. *(Акъегет.)*

Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу «халык шигырьләрен» туплар да ватмады, уклар да кадамады... Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. *(Г.Тукай.)*

## 16 нчы дәрес

Октябрь революциясеннән соң берничә ел эчендә иске татар язуын камилләштерү максаты белән реформалар уздырыла. Ул реформалар уку-язуны җиңелләштерүне күздә тоткан. Бу яңа кабул ителгән язуны моңа кадәр өйрәнелгән иске имлядан аеру өчен «яңа имля» дип йөртәләр. Галимнәр тарафыннан сузык авазларны аеру өчен төрле вариантлар тәкъдим ителә. Шуларның кайберләре: К.Насыйри, Г.Алпаров фикерләре түбәндәге таблицада күрсәтелә. Реформалаштырылган әлифбага яңа хәрефләр өстәлә. Алар түбәндәге таблицада чагыла.

### Яңа имля әлифбасы

| Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Әйтелеше | Аерым хәреф | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Әйтелеше | Аерым хәреф |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ع | ﻌ | ﻋ | гъ | ع | ا | ا | ئا | а | ئا |
| ف | ﻔ | ﻓ | ф | ف | ه | ه | ئه | ә | ئه |
| ق | ﻘ | ﻗ | къ | ق | ب | ﺑ | ﺑ | б | ب |
| ک | ﻜ | ﻛ | к | ک | ت | ﺗ | ﺗ | т | ت |
| گ | ﮕ | ﮔ | г | گ | پ | ﭘ | ﭘ | п | پ |
| ڭ | ﯖ | | ң | ک | خ | ﺧ | ﺧ | җ | ج |
| ل | ﻠ | ﻟ | л | ل | چ | ﭼ | ﭼ | ч | چ |
| م | ﻤ | ﻣ | м | م | ح | ﺣ | ﺣ | х | ح |
| ن | ﻨ | ﻧ | н | ن | د | د | د | д | د |
| و | و | و | w | و | ر | ر | ر | р | ر |
| ی | ﻴ | ﺋﻴ | и | ﺋﻴ | ز | ز | ز | з | ز |
| و | و | ئو | у, | ئو | ژ | ژ | ژ | ң | ژ |
| و | و | ئو | ү | ئو | س | ﺳ | ﺳ | с | س |
| ىٔ | ﺋ | ﺋ | о, ө<br>ы,е | ﺋ | ش | ﺷ | ﺷ | ш | ش |

Калын сүзләрне нечкәләрдән аеру өчен сүзнең беренче хәрефе астына сызыкча куелган. Әгәр сүздә «әлиф», «каф», «гайн» хәрефләре булса, калынлык билгесе куелмаган.

Татар-гарәп язуының реформалаштырылган хәрефләре.

**ئا, ئيـ, ئو, ئـ.**

| | | а | ә | о | ө | у | ү | ы | е | ый | и |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К.Насыйри | Башта<br>Уртада<br>Азакта<br>Аерым | آ<br>ـا<br>ـا<br>آ | ا<br><br><br>ا | اوٰ<br>ـوٰ<br>ـوٰ<br>وٰ | اوٰ<br>ـوٰ<br>ـوٰ<br>وٰ | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـو<br>ـو<br>و | ا<br><br><br>أ | ا<br><br><br>أ | …<br>ـيـ<br>ى<br>ى | ايـ<br>ـيـ<br>ى<br>ى |
| Ш.Таһири | Башта<br>Уртада<br>Азакта<br>Аерым | آ<br>ـا<br>ـا<br>آ | هـ<br>ـهـ<br>ـه<br>ه | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـۆ<br>ـۆ<br>ۆ | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـو<br>ـو<br>و | أ<br><br>ى<br>أ | أ<br><br>ى<br>أ | …<br>ـيـ<br>ى<br>ى | اى<br>ـيـ<br>ى<br>ى |
| Г.Алпаров | Башта<br>Уртада<br>Азакта<br>Аерым | آ<br>ا<br>ا<br>ا | ئه<br>ـهـ<br>ـه<br>ه | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـو<br>ـو<br>و | او<br>ـهـ<br>ـهـ<br>ـهـ | ئـ<br>ئـ<br>ئـ<br>ئـ | …<br>…<br>…<br>… | ئيـ<br>ـيـ<br>ـيـ<br>ـيـ |

*Түбәндәге текстны яңа имля кагыйдәләренә буйсындырып языгыз:*

**Кыр чәчкәсе**

Кырда бер билгеле гади чәчкәдән сорадылар: «Син гади чәчкә идең, ничек бу рәвештә хуш исле булдың?» – дип. Ул җавап бирде: «Дөрес, мин шулай идем. Ләкин канәфер янында үстем, шул сәбәпле миңа канәфернең хуш исләре сеңеп калды, мин шундый хуш исле булып торамын».

# 17 нче дәрес

## Кульязмаларны укуның кайбер гомуми кагыйдәләре һәм үзенчәлекләре

Сүздәге берничә тиз танылa торган хәрефләрне укып кына текстның эчтәлеге турында фикер йөртергә ярамый. Сүздәге һәрбер хәрефне уку зарури.

Катлаулы яки начар танылa торган хәрефне ачыклаганда (укыганда), ул хәрефне тексттагы башка сүзләрдәге язылышы белән чагыштырырга, шулай ук ул хәрефнең башка хәрефләр белән нинди комбинацияләрдә язылышына игътибар итәргә кирәк.

Нигезе белән бер-берсенә охшаш хәрефләрне укыганда, бик нык игътибарлы булу сорала.

Кульязмаларны укырга өйрәнгәндә, кульязма текстын басылып чыккан текст белән чагыштырып өйрәнү әйбәт нәтиҗәләргә китерә.

Кульязманы укый башлаганда, иң элек укылышы шик тудырмый торган сүзләрне хәзерге хәрефләр белән язып алалар, ә тиз укылмый торган яки авыр аңлаешлы сүзләр яки хәрефләр урынын буш калдыралар. Соңыннан текстны тагын да җентеклэбрәк уку процессында буш калган урыннар тутырыла. Гомумән, борынгы текстларны укырга өйрәнгәндә, аларны тулысынча хәзерге графикага күчереп язу яхшы нәтиҗәләр бирә.

Кульязманы дөрес уку өчен, шул чордагы тел үзенчәлекләрен, гарәп-фарсы алынмаларының язылышын, аларның функциясен белү зарури.

Иске язмаларга орфографик буталчыклык хас, аннан курыкмаска кирәк. Синтаксик хаталар да еш күзәтелә, тыныш билгеләре дә юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә иске кульязмаларны уку зур тырышлык һәм түземлелек таләп итә.

Классик гарәп алфавитын төрки-татар теленә яраклаштыру процессында аңа «яңа» хәрефләр өстәлгән. Мәсәлән, «ң» хәрефен язуда XIX йөзләргә кадәр «нун» – ن һәм «кәф» – ک хәрефен кушып белдергәннәр, XIX–XX йөз башларында бу хәрефне өч нокталы «кәф» – ڭ белән белдерү гамәлгә керә. ݣ хәрефе исә асылда XX йөз башында гына кулланыла башлый. Өч нокталы уау (ڤ) XVI–XVIII йөзләрдә кулланышка керә.

Тиз язуга омтылыш нәтиҗәсендә кайбер хәрефләрнең язылыш шәкелләре бик нык үзгәргән. Мәсәлән, «син» хәрефенең «тешләре коелып», ул сызык рәвешен алган:  нәрсә, сәнә (ел) сә һ.б.

Шулай ук кайбер очракларда хәрефләрнең барлык элементларын да язып бетермәү, кыскарту киң таралган күренеш була. Мәсәлән,  фә (фи), кә (ки), га, Бәләбәй һ. б.

Кайбер язылышларның гарәп графикасы кагыйдәләренә сыешмавы күзәтелә. Мәсәлән, «әлиф», «дал», «рә», «зи», «уау» хәрефләре сулъяк хәрефләргә кушылып язылган.

Кайбер очракларда сүзне, гәрчә анда сулдан кушылмый торган хәрефләр булса да, тоташтырып, каләмне кәгазьдән алмыйча язганнар.

Кулъязмаларда (аеруча документларда) «кәф» шәкеле язылышының төрлелеге белән күзгә ташлана.

«Нун» хәрефенең язылышы да төрлечә булырга мөмкин. 

Бик еш кына «ләм» «әлиф»  шәкелендә язылган.

«Һи» хәрефенең сүз башындагы вариантлары да төрлечә булган.



«Йай» хәрефенең язылыш үзенчәлекләре түбәндәгечә:



Тиз язуда нокта куелу рәвешләре дә игътибарга лаек. Тиз язганда, алар кәкре сызыкны хәтерләтә йә хәрефкә тоташтырыла: 

Әлбәттә, югарыда язылганнар гына иске язуыбызның барлык үзенчәлекләрен тасвирлап бетерә алмый. Иске язуыбызның күпчелек хосусиятләрен бары тик озак вакытлар дәвамында практик эшчәнлек нәтиҗәсендә генә үзләштерергә мөмкин.

# Мөстәкыйль үзләштерү өчен материаллар

## Борынгы төркиләрдә һәм татарларда язмачылык тарихы

Мәгълүм булганча, язу, язмачылык борынгы җәмәгать төзелеше дәверенең сәяси этабында, ягъни борынгы җәмгыятьнең таркалуы, сыйныфларның барлыкка килүе, җитештерүче көчләрнең үсүе һәм дәүләтчелекнең килеп чыгуы дәверендә җәмгыятьнең эчке ихтыяҗлары нәтиҗәсендә барлыкка килә. Борынгы заманнардан ук һәр халыкта белемгә омтылу, укый-яза белү Ходай тарафыннан бирелгән зур дәрәҗә итеп саналган. Төрки халыкларда язу тарихы ике мең елдан артык булган чорны үз эченә ала. Алар тора-бара тарихтагы мәгълүм вакыйгалар тәэсирендә үзгәреп торган.

Борынгы төркиләрнең безнең көннәргә кадәр килеп җиткән язмалары шартлы рәвештә ике төркемгә бүленә: руник язулы тарихи-эпик һәм уйгыр язуындагы этик-дидактик ядкәрләр.

Урта Азия һәм Алтай регионында таралып яшәгән уйгырлар, кыпчаклар, бәҗәнәкләр, болгарлар һ. б. төрки кабиләләр, мәгълүм булганча, VII–VIII гасырларда төрки каганлык дәверендә үк руник язу куллана башлыйлар. Руник язма истәлекләр Орхон һәм Енисей елгасы буйларында табылганга күрә, аларны фәндә «Орхон-Енисей язмалары» дип тә атап йөртәләр.

Төрки рун язуы 35 билгедән торган, алар уңнан сулга таба язылган, хәрефләр бер-берсе белән ялганмыйча, һәрберсе өзек рәвештә ташка чокылган. Академик В.В. Бартольд бу язуның төркиләр кулланган телгә һәм сингармонизм законына уйгыр, гарәп язуына караганда дөресрәк җавап биргәнен, камилрәк булганын билгеләп үтә. Рун язулары Көнчыгыш Европага төрки телле кабиләләрнең күчеше белән үтеп керә, бу территориядә табылган руник истәлекләр VIII–IX гасырларга карый. Хәзерге вакытта татарлар күпләп яши торган Идел-Урал төбәгенә рун язуы төрки-болгар кабиләләре белән килә, һәм бу язу монда халыкның кайбер өлеше тарафыннан хәтта XII йөзгә кадәр дә кулланыла. X гасырдан башлап Көнчыгыш Европада, бигрәк тә Идел буе Болгар дәүләтендә, ислам диненең киң җәелүе һәм ныгуы нәтиҗәсе буларак, гарәп язуы өстенлек ала бара. Чыганаклар рәсми эш кәгазьләрен язуда, әдәби әсәрләрдә гарәп графикасына нигезләнгән язу булуы хакында сөйли. Баштагы чорда Җүчи

Олысының хан канцеляриясе беркадәр уйгыр язуын кулланса да, барыбер гарәп язуы өстенлек иткән, аннары XIV гасыр башында гарәп язуы рәсми язу буларак санала.

Идел-Урал төбәге татар-мөселманнары XV гасырдан XX гасыр башына кадәр бары тик гарәп язуын гына кулланганнар, шул дәрәҗәдә озак вакыт кулланылып та, бу язу үзгәртелмәгән, төзәтелмәгән дияргә була, ләкин шулай да бу язу татар теленең бөтен нечкәлекләрен чагылдыруда кыенлык та тудырган. Безнең бабаларыбыз һәм шулай ук фарсылар тарафыннан классик гарәп әлифбасына берничә хәреф өстәлгән. Мәгълүм булганча, гарәп графикасында сузык авазларны белдерү өчен хәрефләр юк, бу очракта бары тик «аст-өст» билгеләрен генә кулланып була, ләкин алар да бу бушлыкны тутырырлык камил түгелләр. Татар реформаторлары төрки халыклар өчен латин хәрефләре нигезендә яңа алфавит төзү мәсьәләсен күтәрәләр, моны тарихта «яңалиф» дип атыйлар. Бу идеянең теоретиклары төрки тел белгечләре Г. Нугайбәк, М. Корбангалиев, Г. Шәрәф, Г. Алпаров, Л.В. Щерба, Н.Ф. Яковлев һ.б. була. 1920 нче еллар уртасында язуны үзгәртү теләге белән сугарылган хәрәкәт СССРның барлык төрки халыклар яшәгән республикаларына тарала. 1926 елда Баку шәһәрендә узган Беренче тюркологик съездда депутатларның күпчелеге язуны үзгәртүне яклап тавыш бирә. Бу съездда Татарстаннан делегат булып Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Н. Хәким, Г. Сәгъди, С. Гафуров, С. Атнагулов катнаша. Татарстан АССРда бу идеягә каршылык белдерүчеләр (Г. Ибраһимов, К. Мөхтәрев, Г. Мансуров) беренче чиратта гарәп графикасын камилләштерергә кирәк дип саныйлар. Алар язу алыштыру нәтиҗәсендә культурада дәвамчылык югала, күпгасырлык традицияләргә зыян килә дип куркалар. Башка татар делегатлары латин графикасын кире какмасалар да, реформалаштырылган гарәп графикасын саклап калу кулайрак булачагына ышаналар, ә С.Атнагулов бу мәсьәләдә нейтраль позициядә кала.

Язу 1929 елның 7 августыннан рәсми рәвештә латинга күчерелә. 1930 елның 1 гыйнварыннан барлык уку йортлары, газета-журнал нәшриятлары рәсми рәвештә яңа алфавитка күчә. Күпмедер вакыттан соң бу яңа алфавит Совет власте җитәкчеләрен канәгатьләндерми башлый. Алар СССРның барлык халыкларын да кириллица нигезендәге яңа язуга күчерү планын әзерлиләр.

Кириллицага нигезләнгән татар алфавиты 39 билгедән гыйбарәт, аларның утыз өче кириллицаныкы булса, калган алтысы татар телен-

дәге авазларны белдерү өчен эшләнгән яңа билгеләр була. Шулай булса да, бу алфавит билгеләре татар телендә булган 42 фонеманы аңлатырлык камил түгел. Кирилл язуының татар теле өчен тиешле дәрәҗәдә камил булмавы мәсьәләсе 1980 нче елларда кискен тәнкыйтьләнә, хәтта татар алфавитына тагын да өч билге өстәп, аңа үзгәреш кертергә омтылышлар ясала. Шул ук вакытта татар интеллигенциясе яңадан латин графикасына кайту кирәклеген дә күтәреп чыга башлый. 1990 нчы еллардан башлап латин графикасына нигезләнгән алфавитның берничә варианты тәкъдим ителә. Бу мәсьәлә галимнәр тарафыннан тикшерелеп, 1994 елда яңа язу төренә күчү мәсьәләсе Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасына кертелә, һәм 1994 елның 20 июлендә Татарстан Республикасының Югары советы тарафыннан кабул да ителә. Бу катлаулы эш берничә этапта башкарылырга тиеш була. Камилләштерелгән яңа латин графикасы 34 билгедән тора, ул бер яктан яңалифкә таянса, икенче яктан татар теле фонетикасының бөтен якларын да исәпкә алырга тиеш була.

1997 елда узган II Бөтендөнья татар конгрессында латинга күчү мәсьәләсе дөньяның бик күп төбәкләреннән килгән татар делегатлары хозурына да куела. Мондагы фәнни дискуссияләрдә Ә.Г. Кәримуллин, М.З. Зәкиев, Ф.А. Ганиев, Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков кебек мөхтәрәм галимнәр катнаша. Конгресс карары белән латин графикасын өйрәтү өчен түгәрәкләр эшли башлый, хәтта кайбер мәктәпләрдә, эксперименталь рәвештә, латин графикасы белән укыту да башлана.

1999 елның 15 сентябрендә Татарстан Республикасының Дәүләт советы өченче укылышта «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын тергезү» дигән закон кабул итә. 2001 елның 1 сентябреннән латин графикасы рәсми төс алырга тиеш була, латинга тәмам күчеп бетү 2011 елга планлаштырыла. Россия Федерациясенең 2002 елның 11 декабрьгә караган «Россия Федерациясе халыкларының телләре» дигән законның 3 нче маддәсенә өстәмә кертелә, анда «Россия Федерациясенең һәм республикаларның дәүләт телләре кирилл графикасына нигезләнә. Россия Федерациясендә Россия Федерациясенең һәм республикаларның дәүләт телләренең башка графикага нигезләнүе федераль закон нигезендә билгеләнә» дигән сүзләр бар. Бу закон татарларның латинга кайту мөмкинлеген чикли. Шулай да латин

графикасы Татарстан Республикасының кайбер вакытлы матбугатында, басма, электрон чыганакларда кулланыла.

*Белемне тикшерү өчен сораулар:*

1. Рун язма истәлекләре турында мәгълүмат бирегез.
2. Татар тарихында гарәп графикасына нигезләнгән язуның тоткан урыны.
3. Латин графикасы хакында сөйләгез.
4. Кириллица, аның тарихы һәм татар тел белемендәге роле.

Әдәбият:


1. *Xaqov V.X. Telen belgən il acar / V.X.Xaqov. – Qazan, 1993.*
2. *Закиев М.З. Сохраним родной язык – сохраним и нацию /М.З. Закиев // Научный Татарстан. – 1997. – № 3–4.*
3. *Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы /Х.Р. Курбатов. – Казан, 1999.*
4. *Мухаметшин Р.М. Переход на латинскую графику в Татарстане: между научной целесообразностью и политической конъюнктурой /Р.М. Мухаметшин // Гражданское общество в многонациональных и поликонфессиональных регионах. – М., 2005.*
5. *Реформа мусульманской азбуки // Мир ислама. – 1913. – Т. 2, вып. 12.*
6. *Рәмиев С. Безгә тәкъдил вә ислахы хөрүф кирәкме? Әллә бөтенләй тәбдил үк кирәкме? /С. Рәмиев // Идел. – 1911. – 5 июнь.*
7. *Сәйфи-Казанлы Ф. Татарлар арасында "Яңалиф" тарихы / Ф. Сәйфи-Казанлы. – Казан, 1928.*
8. *Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар (80–90 нчы еллар). – Казан, 1989.*
9. *Шараф Г. К вопросу о принятии для тюркских народностей латинского шрифта /Г. Шараф // Вестн. науч. об-ва Татароведения. – 1926. – № 5.*

## Татарлар тарафыннан кулланылган гарәп язуы төрләре

Татарларның бабалары төрле тарихи чорларда берничә төрле язу кулланалар. Шулай да язма мирасның зур өлеше нәкъ менә гарәп язуында сакланып калган һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Тарихи чыганакларда һуннарның һинд язуларын кулланулары хакында мәгълүматлар бар. Борынгы төркиләр согыд, брахми, манихей язуларын тирән үзләштергәннәр. Башлангыч чорда согыд язуы Төрки каһанлыгының рәсми, дәүләт язуы дәрәҗәсенә дә күтәрелгән. Төркиләр арасында киң таралган язу, әлбәттә, уйгыр язуы. Бу язу өстән аска, сулдан уңга таба укылган һәм шулай ук язылган да. Әлеге язу төркиләрнең исламга кадәр булган чорда төп язуларына әверелә.

Үзәк Азия төркиләренең иң борынгы язулары булып руннар исәпләнә. Руннар дип каты әйбергә чокып язылган язуларга әйтәләр. Бу чор төрки язулар икенче төрле Орхон-Енисей язулары дип тә аталалар, чөнки алар беренче тапкыр Себердә Енисей, Монголиядә Орхон елгалары буенда табылалар. Рун язуы Дунай буе болгарларында да гамәлдә булган. Тарихи табылдыклар Хәзәр каһанлыгының да бу язу белән таныш булуы хакында сөйли. Соңрак бу дәүләттә диннәрнең йогынтысы белән борынгы яһүд, гарәп, грек һәм аңа нигезләнгән кириллица да киң таралыш ала. Рун язулары Урта Идел, Кама буйларына килгән болгарларда да яшәвен дәвам итә. Ул хәтта, гарәп әлифбасы гамәлгә кергәч тә, аның белән беррәттән кулланыла.

Болгар җәмгыяте үсешкә ирешә барган саен, гомум аңлаешлы, бердәм, камил язуга ихтыяҗ арта башлый. Феодаль мөнәсәбәт шартларында эш кәгазьләрен алып бару, дәүләтара мөнәсәбәтләр өчен дә язу таныган грамоталы белгечләр кирәк була башлый. Болгарлар гарәп язулары белән инде Азов, Дон буйларында ук таныш булалар. Алга таба гарәп язуының киң таралышында ислам дине хәлиткеч роль уйный.

Гарәп язуының борынгы ватаны – Үзәк Гарәбстан. Гарәп теле килеп чыгышы белән борынгы семит телләр төркеменә карый. Бүгенге көндә гарәп графикасына нигезләнгән язу белән дөньяның 20 ләп гарәп дәүләте, моннан кала Иран, Әфганстан, Пакыстан, Бангладеш, шулай ук өлешчә Һиндстан һәм Эфиопиядә кулланалар. Гарәп язуы белән ислам динен тотучы башка халыклар да файдалана. Тарихларының бер этабында гарәп хәрефләренә нигезләнгән әлифба кулланган халыклар үз мирасларын тикшерү өчен хәзерге көндә дә бу гра-

фикага нигезләнгән язуны өйрәнәләр. Гарәп мәдәниятен, телен өйрәтүче атаклы уку йортлары Мәскәү, Санкт-Петербург, Ташкент, Баку, Алма-Ата, Дүшәмбе, Казан шәһәрләрендә эшләп килә.

Татар халкы тарихы гарәп язуы белән тыгыз бәйләнештә. Идел буенда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгәнче үк, аның инде бу территориягә үтеп керүе мәгълүм, бу хакта төрле тарихи чыганаклар сөйли. Татарларда, китап басу эше җайланганчы, китап күчерү гадәте булган, тора-бара китапларны бизәкләп, сату өчен матур итеп эшләп, китап күчерү осталары үсеп чыккан. Татар халкының мәһшүр хаттатлары шәрык илләреннән китерелгән китапларны күчереп язганнар, халык арасында аларны таратканнар. Татарларның матур язу осталарыннан – Ибнеәмин Әминев, Ибраһим Хәлфин, Гали Мәхмүдев, Хөсәен Фәезханов һ.б. атарга була. Осталар тарафыннан башкарылган хезмәтләр хәзерге вакытта Русиянең күп кенә музей һәм китапханәләрендә саклана. Казан университетының кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге дә мондый уникаль ядкарьләрне саклый.

Гарәп язуы сәнгать әсәре тудырырлык дәрәҗәдә камил һәм «борма» булганлыктан, хаттатлар язу ысулын шул дәрәҗәдә төрлеләндерәләр, хәтта почеркларның исәбе йөз егермегә җитә. Бу хәл, әлбәттә, үзенә күрә кабул итүдә авырлык та тудыра башлый. Гарәп каллиграфиясендә алты төр почерк төп почерклардан санала, шуның өчесе: куфи, сөлс, нәсх – борынгы стиль, ә калган өчесе – нәстәгълик, рокъгә, дийвани соңгырак чорга карыйлар.

Озак вакытлар гарәп язуының иң беренче почеркы итеп куфи язуын санап килделәр, башка төр язулар шул почерк нигезендә барлыкка килгән дип исәпләнелде, ләкин, соңгы еллардагы тикшеренү нәтиҗәсе буларак, моның алай түгеллеге, ә төрле почеркларның үсеше параллель һәм бер-берсенә бәйләнешсез барганлыгы ачыкланды. Куфи язуы белән таш, металл кебек каты әйберләргә язганнар. Бу язуны архитектурада, мәчетләр бизәлешендә, тәңкәләрдә күрергә була. «Почмаклы» куфи язуы белән башкарылган папирустагы язулар да очрый.

Куфи язуы орнамент белән бергә геометрия кагыйдәләренә буйсынып эшләнә. Әйтелгәнчә, ул биналар, тәңкәләр эшләгәндә, һәм шулай ук Коръәнне язганда да кулланыла.

Сөлс I–II гасырларда нигезләнә. Сөлс орнаменталь стиль буларак санала, аны эпитафияләрдә кулланалар.

Нәсх III гасырда барлыкка килә. Язуның вертикаль озынлыгы белән горизонталь өлеше бертигез озынлыкта, хәрефләре «тулы», «борылмалары» тирән, сүзләр арасында интерваллар бертигез калдырыла. Бу стильне, гадәттә, Коръән аятьләрен язганда кулланалар, хәзерге вакытта китап, газета басуда да бу стиль файдаланыла.

Нәстәгълик – Иранда барлыкка килгән язу. Аның үзенчәлеге булып язганда хәрефләрнең өстән аска таба күчә баруы тора, ягъни язу вертикаль рәвештә эшләнгән кебек тоела. Бу стиль Һиндстан, Иран, Әфганстан, Пакыстанда кулланыла.

Рокъгә – сөлс һәм нәсх стильләре нигезендә ясалган «кысынкы» стиль. Ул җиңел почерклардан санала, шуңа күрә дә тиз язуда күбрәк әлеге стильне кулланалар.

Дивани язуы белән дәүләт боерыкларын язганнар, ул дәүләтнең рәсми эш кәгазьләрен язуда файдаланылган.

Татар халкы бу төр язуларның барысы белән дә таныш булган. Шулай да иң еш кулланылганнары: нәсх, сөлс, рокъгә. Куфи язуы исә үзенең формасы белән кабер ташларының язуларын эшләгәндә, биналарны гарәп текстлары белән бизәгәндә куллану өчен кулай булган.

Безнең көннәргәчә сакланган иң борынгы гарәп хәрефле болгар язулары 903–907 елларга карый. Алар – тәңкәләрдәге язулар. X гасыр ахырынача диярлек Болгар илендә сугылган тәңкәләрнең язулары куфи белән башкарылган. Археологик казулар вакытында табылган башка кайбер әйберләрдәге язулар да, нигездә, куфи стилендә. Ләкин бу куфи асылда башка мөселман илләрендә кулланылган стильгә иярә. Чын мәгънәсендәге «болгар куфие» дип аталырлык стиль XIII йөз азагы – XIX йөз башы кабер ташлары язуларында күзәтелә. Әлбәттә, ул да тамырсыз булмый, аның нигезендә X–XI гасырларда күчерелгән Коръән нөсхәләрендәге «кармат куфие» дигән исем астында мәгълүм булган стиль ята. Кабер ташларындагы язулар шулай ук сөлс төре белән дә башкарылган. Кайбер композицион үзенчәлекләр һәм детальләр җәһәтеннән ул Харәзем (Үргәнеч) «сөлесенә» тартым.

Алтын Урда дәверендә (XIII–XV йөзләр) җирле язу рәвешләренә яңа тенденцияләр һәм элементлар өстәлә. «Дүрткел куфи» исемле стиль мөһерләрдә кулланыла башлый. Ул шулай ук XVI гасыр Сәхибгәрәй хан ярлыгында да урын алган. Ханнар диваныннан (канце-

ляриясеннән) чыккан ярлыклар дивани (җәли дивани) һәм сөлес белән башкарылган.

XV–XVI гасырлар тирәсендә гарәп графикалы милли язуыбыз яңа үсеш дәвере кичерә. Моны ташлардагы өсъязмалар һәм сакланып калган аерым язулы кәгазь үрнәкләре мисалында күрергә мөмкин. Бу дәвердә язуда сөлс һәм тәгълик стильләре өстенлек ала.

XVI гасыр урталарыннан алып, милли дәүләтчелегебез җимерелү сәбәпле, мәдәниятнең бер өлеше булган милли язу да торгынлык чоры кичерә, төгәлрәк әйткәндә, сәнгать төре буларак күздән төшә. Шулай да рухи тормыш дәвам итүдән тукталмый, әлбәттә. XVI йөзләрдәге кулъязмалар, төрле эчтәлектәге китапларны күчереп язу әдәбиятыбызның матур үрнәкләрен саклап калуга, рухи-мәдәни традицияләрне югалтмауга хезмәт итә.

Кулъязмаларның сыйфаты хакында сүз йөрткәндә шуны истә тоту зарур: милли дәүләт булмау, идарәче һәм зыялы катлау вәкилләренең күпләп һәлак булып юкка чыгуы һәм шул сәбәпле югары сәнгать дәрәҗәсендә кулъязмаларга ихтыяҗның ифрат нык кимүе хаттатлар продукциясенең таралу мәйданын бик нык чикләгән. Әлбәттә, мондый шартларда югары дәрәҗәдәге, тиешле зәвык белән язылган китаплар юк дәрәҗәсендәге сирәк күренешкә әверелә. Әмма бу авыр шартларда да укымышлы кешеләр катлавы арасыннан шактый күренекле хаттатлар пәйда була.

Кулъязма китаплар һәм документлар төрле язу стильләре белән башкарылган. Иң еш кулланылганнары – нәстәгълик-шикәстә (гадәттә аны нәстәгълик дип кенә йөртәләр) һәм Коръәннәр күчерү өчен үрнәк саналган нәсх. Сирәгрәк сөлс һәм шикәстәдән файдалану да күзәтелә. Күп кенә кулъязмалар үтә дәрәҗәдә индивидуаль стильле булып, аларны төгәл сыйфатлау мөмкин дә түгел.

Күпчелек кулъязмаларның йөзен билгеләүче язу төрләре – нәстәгълик-шикәстә (бу терминның мәгънәсе болай: язу асылда «нәстәгълик» булса да, аңа сизелерлек дәрәҗәдә шикәстә элементлары кушылган). Аның өстенлек итүе, әлбәттә, һич очраклы түгел. Нәстәгълик XIV гасыр азагыннан тизлек белән тарала башлый, Иран, Азәрбайҗан, Урта Азияне яулап ала. Билгеле булганча, Урта Азия дәүләтләре һәм Болгар йорты арасында тыгыз элемтәләр борынгы заманда ук урнашкан. Каллиграфик информация XVII–XVIII гасырларда безнең җирләргә Урта Азиядән килә. Анда исә XV–XVIII гасырларда бөтен кулъязмалар диярлек (Коръән күчермәләреннән

башка) нәстәгълик белән башкарыла. XVII–XVIII йөзләрдә бу стиль инде әкренләп нәстәгълик-шикәстәгә әверелә. Шуны искәртү зарур: татар хаттатлары, Төркиядәге традициягә ияребрәк, бу стильне «тәгълик» дип кенә йөрткәннәр.

Әһәмияте буенча кулъязмаларыбызда икенче урын биләүче стиль – нәсх. Әмма ул да башлыча үзенең классик рәвешендә түгел, ә бәлки башка төр язу (нигездә, нәстәгълик, сирәгрәк куфи) элементлары белән баетылган хәлдә кулланылган. Бу стиль – нәсх – күпмедер дәрәҗәдә XIX йөз башында Казанда басма гарәп шрифтына нигез була, һәм ул җиңел, дөрес уку өчен уңайлылыгы белән аерылып торган. Шул шрифт белән нәшер ителгән Корьән Русиядә генә түгел, башка мөселман илләрендә дә «Казан басмасы» буларак дан казанган.

Куфи



Нәсх



Сөлс



Нәстәгълик-шикәстә



Дивани



*Белемне тикшерү өчен биремнәр:*

1. Борынгы төрки язмачылык тарихы турында мәгълүмат бирегез.
2. Гарәп язуының төрләре турында сөйләгез.

Әдәбият:


*1. Давлетшин Г. Булгарская письменность (раннебулгарский и домонгольский периоды) / Г. Давлетшин // Эхо веков = Гасырлар авазы.–Б.м...–2008.–№1.–С.23-32.*

*2. Давлетшин Г.М. История духовной культуры тюрко-татар: учеб. пособие /Г.М. Давлетшин; М-во образования Респ. Татарстан, Татар. гос. гуманитар. ин-т.–Казан : Gumanitarya, 2004.–99, [9]с.*

*3. Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа: (истоки, становление и развитие) / Г.Давлетшин.–Казань: Татар. кн. изд-во, 2004.–429, [1] с.*

*4. Зәйнуллин Җ. Әссәләмүгаләйкүм / Җ. Зәйнуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1993. – 174 б.*

*5. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV – XVI вв. = XIV – XVI гасыр Җүчи Олысының ярлыкаш актлары / М. А. Усманов. – Казань : Изд-во Казан. ун-та, 1979.–318 с.*

*6. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII – XVIII вв: «Сборник летописей», «Дафтар-и Чингиз-наме», «Таварих-и Булгария», татарские шаджара / М.А. Усманов.–Казань : Изд-во Казан. ун-та, 1972.–221, [2] с.*

*7. Шимел А. Исламская каллиграфия /А. Шимел // Родина, 2001. – № 5. – С. 30.*

## Кятибләр, хаттатлар

Китап күчерү эше саваплы эш дип каралган, аңа бөтен кешеләр дә изге теләктә булырга тиешләр:

*Китаптыр бетегәнем,*
*Догадыр өмит иткәнем.*
*Ошбу китап язгучы фәлән улсын,*
*Бу җиһанда шат улсын!*

Татар хаттаты өчен китап күчереп язу ул – эстетик мәгънәгә дә ия булган сәнгать. Кайбер хаттатларның йөзләрчә том-җилд китап күчерүе хакында мәгълүматлар сакланып калган. Көньяк Урал (Курган) якларында яшәгән атаклы татар хаттаты Габденнасыйр Сабитов (1745–1841) 20 яшеннән алып 95 яшенә хәтле төннәрен чыра яктысында 223 том китап күчергән. «Бу юлларны укыгач, тирән картлык эченә чумган бер хакимнең идәнгә түшәлгән киез өстендә, тәбәнәк өстәл янында, чыра яктысында каурый каләм белән язып утырган сурәте күз алдына килеп баса... Заманасы өчен ничаклы хәерле хезмәт дисең», – дип язган журналист, язучы һәм китап белгече Исмәгыйль Рәми (1895–1969).

Кайбер татар хаттатларының исемнәре безнең көннәргә кадәр сакланып калган: Илми Үтәмеш улы (1700–1740 нчы еллар), Сәйфелмөлек Зәйнетдин улы (1730–1760 нчы еллар), Сөбхан Мәрҗани (XVIII йөз башы), Мәнди Котыш (1761–1849), XIX йөздә хаттат буларак Рәхмәтулла Әмирхан улы, Мостафа Әлдермеш, М. Чутай, И. Әминов (1832–1861), Гали Мәхмүдовлар исем казанган, XX йөз башларында Казанда – Мөхәммәт Идриси (1882–1947), Кыйвам-карый Зөлфокарый (1870–1921), Котдус Фәхретдинов, Галиәсгар Камал, Госман Салиев, Оренбургта – Сәлах Камал, Уфада – Баһаветдин Максудов һ.б. иҗат иткән.

Урта гасыр кятибләре, аяк бөкләп идәнгә утырып, кәгазьне уң тезгә (аякка) куеп язганнар. Өстәл гамәлгә кергәч тә традиция буенча идәнгә-сәкегә утырып язу дәвам иткән. Кятиб алдында язу кораллары, кәгазь салынган кечкенә генә сандык (сумка) торган.

Фасыл башларын кызыл, яшел һәм кара буяу белән язганда эре хәрефләрнең түгәрәк элементларын җәзбә (циркуль) белән сызганнар. Туры сызыкларны язганда, линейка (тигезләмә, мәхтат) да кулланылган. Матур язу, каллиграфия үрнәкләре яисә рәсем (бизәк) өчен файдаланылган дәфтәр-альбомны «мөрәкгат» дип атаганнар.

Кятибләр, китап күчерүчеләр еш кына үзләрен кечерәйтү, түбәнсетү титулы белән бик озын итеп «фәкыйрь», «хакыйрь», «горьян», «гасый» дип атаганнар. Әмма, шулай булса да, алар үзләре күчергән китапларның «бакый» (мәңге) калачагына өмет иткәннәр һәм киләчәк буыннарга васыять рәвешендә түбәндәге юлларны теркәгәннәр:

*Буны яздым ядкяр улмак өчен.*
*Укыганнар бер дога кылмак өчен.*
*Укыганнар укысын, галим булсын,*
*Йөрегәннәр йөресен, җаһил улсын.*

Көнбатыш Европада һәм руста кулъязма китапларның күпчелеге монастырь һәм скрипторийларда күчерелгән. Татарда бу рольне мәдрәсәләр башкарган. Белем чишмәсенең башы саналган мәктәп-мәдрәсәдә белем алу белән бергә китап күчерү киң таралган күренеш була. Алай гына да түгел, яшәү шартлары никадәр авыр булмасын, татар мәдрәсәне хәтта оҗмах белән тиңли:

*Бу дөньяның оҗмахы –*
*Мәдрәсәләрнең почмагы.*

Гадәттә, мәдрәсә шәкертләре кече яшьтән китап күчереп язу эше белән шөгыльләнгәннәр. Басма китап җитәрлек булмаганлыктан, мәдрәсәләрдә бу эш киң таралган күренеш була. Язуы матур, каләме йөгерек булган шәкертләр үзләре өчен генә түгел, билгеле бер хакка чит кешеләргә дә китап күчергәннәр. Бу шәкертләргә матди яктан да файдалы булган. Күренекле татар галиме К. Насыйри (1825–1902), мәдрәсәдә укыган елларын искә төшереп, болай дип язган: «Мәдрәсәдә бик фәкыйрьлек белән кичендем, күп язу яздым. Китап басу һөнәре күп таралган иде. Әмма шунысы гаҗәп, кая китте минем ул язуларым! Асла берсе дә күренгәне юк. Басма китаплар булгач, язма китапларны утка яктылармы әллә?»

Кайбер очракларда китапларны өмә ясап та күчергәннәр. Андый китапларны актарып карагач, төрле дәфтәрләре төрле кеше язуы белән язылганлыгы «кычкырып» тора. Кайвакытта өмә ясап китап күчерү хакында конкрет мәгълүматлар да сакланып калган. Мәсәлән, 1878 елда кятиб Мөхәммәт бине Габдулла әд-Думави каләме белән Зәбир бине Мөхәммәтшәриф өчен күчерелгән төрек әдәбияты әсәре «Гарибнамә» (авторы – Гашыйк паша) исемле кулъязманың (№ 201т. (2633) 149а кәгазендә мондый юллар бар: «Язылды мең дә сигез йөздә йитмеш сигезенче елда фи сәнәи Русия, февральнең йегерме бишенче йәүмендә бән Зәбир бине Мөхәммәтшәриф яздыр-

дым өмә җыеп, язучыларны өч сум көмешлек сыйладым...». Кол Галинең үлемсез «Кыйссаи Йосыф» әсәрен 1845 елда (№ 2646т. 8а кгз) ике кятиб: Мәүләветдин Таҗетдин (23а кгз) һәм Биккенә Мәлләтамакый (26а кгз) күчергән.

Мондый өмәләрдә катнашучы кятибләрнең саны кайвакытта 10 га җиткән.

Томар рәвешендәге китаплар тоташ буй итеп озын кәгазьгә язылып, урап куелган. Шәҗәрәләр асылда томар рәвешендә булган.

Сирәк кенә очракларда башка төр әсәрләр дә томар рәвешендә төзелгән: мәсәлән, төрки-татарча дәүләт догасы 247 см озынлыкта, иңе 11 см булган кәгазьгә язылган.

Татарда китапны саклауга бәйле әсбаплар һәм ысуллар күптөрле. Коръәнне саклау өчен кайвакытта махсус каплар ясаганнар. Мәсәлән, Касыйм ханы Уразмөхәммәднең Коръән кабы көмештән эшләнгән һәм аның артына гарәп хәрефләре белән ханның шәҗәрәсе кисеп-сырлап язылган була. Китапны шулай ук традиция буенча идәнгә (сәкегә) утырып укыганнар. Дәү китапларны уку өчен махсус җайланма да кулланылган. Китапны уку, өйрәнү, үзләштерү «моталага кылу» дип аталган. Аерым китапларны, мәсәлән, махсус кулланмаларны «дәстүр-ел-гамәл» дип атаганнар.

Татар элек-электән китаплы булырга, аны күчерергә, мәгърифәтле, гыйлемле булырга тырышкан, гади генә итеп күчерелгән йөзләрчә, меңнәрчә кульязма китаплар әнә шундый бер гыйбрәтле хатирә булып торалар.

*Биремнәр:*

1. Татарлардагы китап күчерү традициясе турында мәгълүмат бирегез.
2. Кульязма китапның татар тарихындагы роле.

Әдәбият:

*1. Абзалов Л. Ф. Ханские писцы. Из истории становления и развития канцелярской службы ханов Золотой Орды /Л.Ф. Абзалов. – Казань : Изд-во «Яз», 2011. – 252 с.*

*2. Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы /М. Әхмәтҗанов. – Казан., 2000. – 285 б.*

*3. Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения : Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / сост.: Р.Ф. Исламов, С.Ф. Галимов. – Казань, 2011. – 268 с.*

*4. Госманов М. Каурый каләм эзеннән : археограф язмалары. Тулыландырылган икенче басма. / М.Госманов – Казан : Татар. кит. нәшр., 1994. – 463 б.*

*5. Дульский П.М. Казанский каллиграф Али Махмудов /П.М. Дульский. – Казань, 1930. – 8 с.*

*6. Программа спецкурса "Каллиграфия" / Казан. гос. ун-т, Ин-т востоковедения; [сост. Д. А. Шарафутдинов; науч. ред. А.Б. Халидов].–Казань: [б. и.], 2001.–11 с.*

*7. Проненко Л.И. Каллиграфия для всех /Л.И. Проненко. – М.: Книга, 1990. – 248 с.*

*8. Рукописная книга в культуре народов Востока. Кн. 1. – М.: Наука, 1981. – 557 с.; кн. 2. – 1988. – 547 б.*

*9. Сабиров А.Р. Арабская каллиграфия /А.Р. Сабиров. – Казань: Иман, 2006. – 32 с.*

*10. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. /М.А. Усманов. – Казань : Изд-во Казан. ун-та,1972. – 223 с.*

*11. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. /М.А Усманов – Казань : Изд-во Казан.ун-та,1979. – 318 с.*

## Язу материаллары

### *Кәгазь*

Борынгы заманнарда язу материалы буларак таш, гранит, балчык плитәләр кулланганнар. Борынгы Мисырда папируска да язганнар. Озак вакытлар язу материалы сыйфатында пергамент кулланылган. «Пергамент» дигән сүз Кече Азиядә урнашкан Пергам шәһәреннән алынган (хәзер Бергам). Б.э.к. II гасырда бу шәһәрдә пергамент эшләп чыгару технологиясе камилләштерелә, шуңа күрә бу материал да шәһәр исеме белән бәйләп йөртелә. Пергамент – хайван тиресен махсус эшкәртеп ясалган материал. Чимал буларак, асылда, сарык, кәҗә, бозау тиресе кулланылган. Пергаментның иң яхшы сорты яңа туган бозау тиресеннән эшләнгән. Эшкәртелгән пергамент ак яисә

саргылтрак төстә булган. Борынгы Руська пергамент Византия аша үтеп кергән. Руслар пергаментны башта «кожа» (тире) һәм «телятина» дип атаганнар. Ә «пергамент» сүзе Россиядә XVII гасырда поляк теле аша кулланышка керә. Ул язу материалы буларак, әлбәттә, кыйммәт торган. Шуңа күрә аны кат-кат файдаланганнар, элеккеге язуны кырып төшереп, яңа текст язганнар.

Пергаментка язылган татар кулъязмалары сакланып калмаган. Әмма татарның борынгы бабалары пергаментны язу материалы буларак кулланганнар дип әйтергә мөмкин. Мәсәлән, археографик экспедицияләр вакытында бабайлардан «элек күнгә язылган китаплар бар иде» дигән сүзләр ишетергә була иде.

Бабаларыбыз язу материалы сыйфатында каен тузын да кулланганнар. «Тузга язмаганны сөйләмә» дигән әйтем нәкъ шуңа ишарәли. Әмма безнең төбәктәге кискен континенталь климат шартларында алар сакланып калмаганнар.

Россиядә, татарда да шулай ук XIV йөзләрдә пергаментны язу материалы буларак кәгазь кысрыклап чыгара һәм хәзергә кадәр уңышлы файдаланыла.

Кәгазьнең ватаны – Борынгы Кытай һәм Шәркый Төркестан. VIII йөздә кәгазь эшләү Сәмәркандта да юлга салына һәм гарәп яулап алуларыннан соң бөтен мөселман дөньясына тарала. Урта гасырларда кәгазьне мөселманнардан европалылар кабул итеп ала.

Алтын Урда дәверендә татарлар Урта Азиядән китерелгән кәгазь белән эш иткәннәр. Мәсәлән, Олы Мөхәммәд ханның – 1428 ел, Мәхмүт – 1466, Әхмәд – 1477 һәм Казан ханы Сәхибгәрәйнең 1523 елгы ярлыклары Урта Азиядән китерелгән кәгазьгә язылган. Ефәк калдыкларыннан эшләнгән кәгазь бу дәвердә аеруча популяр саналган. Алтын Урда ханнарының канцеляриясендә шулай ук Якын Көнчыгыштан (Багдадтан) китерелгән кәгазь дә кулланылган.

XV–XVI йөзләрдә татарлар арасында Европада җитештерелгән кәгазь дә тарала башлый. Бу дәвердә Генуя сәүдәгәрләре итальян кәгазе белән сәүдә итә башлыйлар һәм ул кәгазь Кырым аша Көнчыгыш Европада, шулай ук татарлар арасында да кулланышка керә. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверендә татарлар Һиндстаннан китерелгән кәгазьне дә кулланганнар дип әйтергә мөмкин. Һәрхәлдә Кавказда һинд кәгазенә язылган кулъязмалар очрый, ә Кавказ белән татарлар тыгыз мәдәни элемтәдә торганнар.

XVI йөздә Россиядә кәгазь тегермәннәре төзеп, кәгазь эшләп чыгару уңышсызлыкка очрый, шуңа күрә XVIII йөзнең беренче унъеллыкларына кадәр, асылда, читтән китертелгән кәгазь кулланганнар. XVI гасыр ахырыннан алып Россиядә француз кәгазе тарала башлый. XVII йөзнең икенче яртысында Россиядә француз кәгазен Голландия кәгазе кысрыклап чыгара. Гомумән, XVII гасырда Россиядәге кәгазь мануфактуралары голланд осталары кулында булган.

Әлбәттә, татарлар Урта Азиядән китерелгән кәгазь белән бергә Европа илләреннән килгән кәгазьдән дә файдаланганнар. Мәсәлән, фәндә XVII йөздә Голландия кәгазендә язылган татар кулъязмалары билгеле. XVIII–XIX йөз башларында Урта Азиядә кәгазь җитештерү торгынлык кичерә, шуңа күрә Әстерхан аша Урта Азиягә китертелгән Россия кәгазен бохаралылар «эштархани» дип атап йөрткәннәр. Сыйфат ягыннан XVIII–XIX гасыр башындагы рус кәгазе мактанырлык түгел. Бу чорда җитештерелгән кәгазь кытыршы һәм уалучан.

Читтән китерелгән кәгазь белән бергә татарлар үзләре эшләп чыгарган кәгазьдән дә файдаланганнар. Мәсәлән, 1789 елда Уржум өязендә Мөхәммәт Рәхимовның кәгазь мануфактурасына нигез салына. 1812 елгы мәгълүматларга караганда 2 кәгазь мануфактурасында 102 кеше эшләгән. 1816 елда Уржум өязендә тагын 2 мануфактура эшли башлый. Эшкуар С.Галиевнең «С.Г.» филигране белән кәгазь эшләп чыгаруы билгеле. XIX йөз урталарыннан соң татар кәгазь мануфактуралары турында мәгълүматлар очрамый. Алар конкуренциягә каршы тора алмыйча ябылганнар дип уйларга кирәк.

XVII йөздә татарлар язу кәгазе мәгънәсендә «пичу каты» һәм «мамык» дигән атамалар кулланганнар. Ә XVIII йөздә «кәгазь» сүзе аларны кысрыклап чыгара. Кәгазь табагы – «такта кәгазь» яисә «табак кәгазь», кулъязма өчен төпләнгән кәгазьне «нөсхәлек» дип атаганнар. Герблы кәгазь атамасы татар теленә XVIII йөз башында керә башлый.

Кәгазь эшләп чыгару өчен Россиядә киндер сүсе кулланылган. Иң элек аны кайнатканнар, аннары юганнар, ваклаганнар һәм известь белән агарткannar һәм шул массаны махсус формаларга салганнар. Форманың эченә нечкә тимер сетка куелган, кәгазь массасы шул сетка өстенә җәелгән, суы саркыган. Шул сеткага нечкә тимер чыбыктан ясалган төрле рәсем-бизәкләр дә куелган һәм шул рәсем кәгазь эшләп чыгаручы фабриканың маркасын күрсәткән. Суы саркыгач, пресс аша уздырганнар, аннары язып шомартканнар.

Су билгеләре (филигрань) Европа кәгазь фабрикаларында XIII йөздә үк кулланыла башлый һәм хәзергә кадәр аеруча мөһим дәүләт документларын һәм кәгазь акчаларны бастырганда кулланыла. Хәзерге вакыттта фәндә берничә дистә мең филигрань билгеле. XIII–XVI йөзләрдә эшләнгән кәгазь файдаланылмыйча 5–8 ел ятырга мөмкин дип исәпләнелә. Бик сирәк очракларда гына «борынгы» кәгазьгә язылган яңа документлар очрый. Мәсәлән, 1840 елда эшләп чыгарылган филиграньле кәгазьгә 1909 елда язылган татарча хат сакланып калган. Бу, әлбәттә, сирәк очрый торган күренеш.

Күпчелек татар кульязмалары нигездә рус-Европа кәгазенә теркәлгән. XVIII йөзнең яртысы – XIX йөзнең беренче чирекләрендә Россиядә күгелҗем-яшькелт кәгазь эшләп чыгару өстенлек иткән. Димәк, бу чорда күчерелгән китапларның яшен билгеләгәндә, кәгазьнең төсе дә чыганак-информация ролен үтәргә мөмкин.

Кульязма китапларның бит саннарын цифрлар белән күрсәтү XIX йөздә генә гамәлгә керә башлый. Классик мөселман татар китабында бит санын белдерү вазифасын «хафиз» (көнбатыш традициясендә кустод) башкарган, ягъни, уңдагы биттә текст тәмамлангач, сул почмакта аерым юлга сул бит башындагы беренче сүзне язып куйганнар. Әнә шул хафиз ярдәмендә сәхифәләре буталган кульязманы тәртипкә салып була.

Кәгазь, әлбәттә, кыйммәт булган. Шуңа күрә кайбер өстәмә язмаларны, кайбер документларны кульязма китапларның буш калган битләренә язганнар.

XIX йөз урталарына кадәр кәгазьгә юл сызыклары төшерелмәгән. Моның өчен махсус җайланма – мистар кулланылган. Мистар катыргыга тегәрҗеп тарттырып эшләнгән. Мистар өстенә куелган кәгазьгә кул белән басып юл сызыгы төшерелгән.

## *Язу карасы*

Тиз бозылмый һәм кәгазьдә ачык күренеп торган кара эшләп чыгару ысулын кешеләр бик озак эзләгәннәр. Һәм хәзергә кадәр язу карасын эшләүнең бик күп рецептлары бар.

Татарда язу карасы табигый органик компонентлардан ясалган. Мәсәлән: корым, камедь (чәер, сагыз), глицерин, тимер купоросы, уксус, акбур, карбол кислотасы, күгәргән кадак, каен яфраклары,

имән, алмагач, зирек, корыч агач (дардар агачы) кайрысы, квас, ачы бал, лимон согы, су һ.б.

Татар кульязмаларын язганда, асылда, зәгъфрән һәм шулай ук кызыл, яшел төстәге каралар кулланылган.

Язу карасының мәдәният тарихындагы кодрәтле көче Байронның метафорик сүзләрендә ачык чагылыш тапкан. «Миллионлаган кешенең фикерен уяту өчен бер тамчы кара җитә», – дигән шагыйрь. Бу җәһәттән татар халкы да төшеп калмаган, язу карасы турында төрле әйтемнәр, табышмаклар иҗат иткән. Мәсәлән:

*Менә табышмак уйлап кара,*
*Суы тәмсез, үзе кара,*
*Чиләгенең төбе юк,*
*Файдасының чиге юк.*

*(Кара һәм кара савыты.)*

Язу карасын – «мөрәккәб» яки «мөрәккәб сияһ», кара савытын «дәват», «сияһдан» дип атаганнар. Урта гасырларда кара савытларын төрле материалдан (керамик, металл) ясаганнар, соңрак пыяладан ясау да гамәлгә кергән.

Тарихтан билгеле булганча, кайбер экстремаль очракларда язу карасы урынына кеше канын да кулланганнар. Акыл ияләренең язу карасы шәһитләрнең каны кебек үк кыйммәтле, диелә атаклы гарәп мәкалендә.

Озак вакытлар буе (бигрәк тә урта гасырларда) язу карасын кустарь ысул белән әзерләгәннәр. Кайвакытта коммерция максатларын күз уңында тотып, әйбәт язу карасы ясау рецептларын осталар сер итеп саклаганнар, кайбер очракларда исә рецептларны махсус рәвештә бозып язганнар (үзенә күрә промышленность шпионажына каршы тору чарасы).

Татарда промышленность нигезендә җитештерелгән кара куллану киң күләмдә XIX йөз ахырларында гына таралыш таба башлый.

Тотрыклы, әйбәт язу карасы булдыру юнәлешендә 1885 елда зур уңышка ирешелә: бу елда ализарин кара ясау технологиясе эшләнә. Бу язу карасы марена үләне тамырларын эшкәртү нигезендә ясалган. Мондый кара озак вакытлар төпкә утырмаган, яхшы сакланган. Әмма аның бик зур бер кимчелеге була: ул бик начар исле.

Соңрак химик анилин кара уйлап табыла. Озак вакытлар яхшы каралар Россиягә чит илләрдән кертелә. 1870 нче елларда француз фирмалары тарафыннан эшләнгән каралар бик популяр була.

Язу карасын фабрикада җитештерү дәверендә кара ясауның рецептлары бик нык азая һәм язу карасы ГОСТ таләпләренә туры китереп чыгарыла. Хәзерге язу каралары синтетик буяуларга куертучы матдәләр кушып һәм, әлбәттә, су белән сыегайтылып ясала. Язу карасы эшләүдә спирт куллану караның тагын да тизрәк кибүенә китерә. Шуңа күрә, язгач, язулы текстны чистартылган елга комы белән киптерүнең кирәге калмый. Шулай ук хәзер киптергеч куллану да гамәлдән төшеп бара дип әйтергә мөмкин. Бик аз урыннарда (очракларда) гына язу карасын киптерү өчен махсус киптергеч кулланыла (загс, паспорт өстәлләрендә, мөһим документлар язганда). Элеккеге гомумсоюз стандарты буенча язу карасының 40 секундта кибүе норма булып саналган.

## *Каләм*

Мөселман дөньясында язу коралларының озын тарихы бар. Төрле почерклар һәм төрле материалларга язу өчен кулланылган каләмнәр турында махсус хезмәтләр язылган, инструкцияләр төзелгән. «Каләм» сүзе греклардан таралган (каламос). Каләмне бик күп шәрык халыклары: кобытлар, гарәпләр, фарсылар, төркиләр (шул исәптән татарлар), Һиндстан һәм Урта Азия халыклары кулланган. Шәрык илләрендә язу коралы – каләм сыйфатында камыш актив файдаланылган, чөнки аның белән язганда кәгазьгә кара тотрыклырак төшкән.

Татар хаттатлары-каллиграфлар язу коралы буларак төрле материаллардан эшләнгән каләмнәр кулланганнар. Гадәттә, каләм камыштан яки каз каурыеннан ясалган. Шул ук вакытта Җүчи Олысы (Алтын Урда) заманында сөяктән эшләнгән каләмнәр куллану хакында мәгълүматлар бар. Археологик казу эшләре вакытында металл (бронза) каләмнәр табылу очраклары да теркәлгән. Шундый каләмнәрнең берсе XIV йөздә җимерелгән Сарай-Бәркә шәһәре калдыкларын казып тикшергәндә табылган. Хәзерге вакытта ул Эрмитажда саклана.

Иң киң таралган каләм, югарыда әйтелгәнчә, камыш яки каз каурыеннан ясалган. Каләм сыйфатында кош каурые (кайвакытта аны «кавырсын» дип тә атаганнар) кулланганда, иң әүвәл аны майдан арындыру өчен кайнар суга яки комга тыгып торганнар. Каләмне махсус пәке белән тактага (найкат) куеп кыеклап кискәннәр. Язуның

сыйфаты, матурлыгы каләмнең кыеклап киселгән өлешенең озынлыгы һәм сыгылмалылыгына бәйле булган. Каләмнең кыеклап киселгән өлешен «каләм боты» дип тә атаганнар. Бу хакта кайбер шаян шәкертләр, хаттатлар ике юллык «шигырь» дә иҗат иткәннәр:

*Каләм юнсаң, озын юнгыл ботыни,*

*Хатын алсаң, элек алгыл котыни.*

Яхшы киселгән каләмне карага манып, төртке ясап сынап караганнар, әгәр төртке ромбик рәвешендә төшсә, каләм дөрес әзерләнгән була. Каләмне махсус савытта – каләмданда саклаганнар. XIX йөз урталарында Казанда каләм ясаучы осталарның үз товарларын базарларга чыгарып сатулары хакында мәгълүматлар бар.

Татар хаттатлары кайвакытта, кулъязманы язып тәмамлаганда, каләмгә хөрмәт күрсәтеп, түбәндәге юлларны теркәп куя торган булганнар:

*Ошбуны бән язмадым, язды каләм,*
*Ошбуның артынча чук-чук сәлам.*

Яисә:

*Каләм юндым, хат бетедем – ошбудыр хатым,*
*Ошбуны бән язмадым, язды каләм.*

Хәер, каләм һәрвакытта да бик үк дөрес ясалмаган булырга мөмкин. Мондый очракларда күчерүче-кятиб түбәндәге юлларны теркәргә кирәк санаган:

*Буны язганда кыш иде,*
*Каләмем камыш иде,*
*Гаеп итмәңез, муллалар,*
*Каләмем килешмәде.*

Каләмгә багышланып бәетләр дә иҗат ителгән:

***Каләм бәете***

*Кара савыты тора, көмеш башлы җиз каләм,*
*Каләмнең хезмәте илә агарды бөтен галәм.*

*И каләмем, каләмем, сәңа улсын сәламем,*
*Сәнең кылган хезмәтеңә юктыр һичбер кәлямем.*

*Күз өстең каралттың, дөнья йөзен агарттың,*
*Ничә миллион нөсхәләрне җир йөзенә таралттың.*

*Китаплар килерме иде, адәмнәр белерме иде,*
*Әгәр каләм булмаса, хөкемнәр йөрерме иде?*

*Диңгез кичергән каләм, җиһан гиздергән каләм,*
*Ярны ишеп, тауны тишеп, ташны ваттырган каләм.*

*Тупны аттырган каләм, шәһәр ваттырган каләм,*
*Дау чыгарса – солых кыла, шул каләмгә йөз сәлам.*

Каләм һәм каләм ияләре турында 1870 нче елларда элеккеге Уфа губернасы Адай авылының мелла Мөхәммәтшәриф мулла Таһир улы тарафыннан күчерелгән татарча шигырьләр дәфтәрендә искиткеч мәгънәле юллар теркәлгән:

*Каләм үгрән – каләм изгегә тартар,*
*Каләм илән кешенең ризкы артар.*
*И каләм, хак ризасы өчен килеш,*
*Әгәр килешмәсәң, пычак берлән бирермен үкеш.*
*Каләмгә әйттем: «Имди язмагыл күп,*
*Ки күргәннәр укырга, күрмәгәй хуб.*
*Бу язмактан каләмнең туясы юк,*
*Кәгазь бетмәй каләмнең куясы юк.*

Менә бу юллар татар шәкертенең, татар китап күчерүченең девизы булып тора дип әйтергә мөмкин.

Каләмгә багышлап шигырь язмаган шагыйрьләр сирәктер. Классик әдибебез Дәрдемәнд тә каләмгә багышлап үзенең үлемсез шигъри юлларын иҗат иткән:

***Каләмгә хитаб***

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!*

*Бабалар кабре янында күңел зар,*
*Аталар рухының армандәсе бар...*
*Кара тунрак тулы мәзлум нидасы,*

*Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?..*

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!..*

Бик сирәк очракларда, төсле каралар белән китап, фасыл-баб исемнәрен язганда һәм бизәк төшергәндә, нечкә нәфис пумала да кулланылган.

XIX йөзнең 30 нчы елларында Россиядә читтән китерелгән металл каләмнәр кулланышка керә башлый. Алар, асылда, Бөекбританиядәге Бирмингем шәһәрендәге каләм фабрикаларында эшләнгән. 1830 елда бу шәһәрдә ике каләм фабрикасы ачылып эшли башлый. 1851 елда исә, өченче фабрика ачылып, алтын һәм көмеш каләмнәр чыгару юлга салына. Тора-бара металл каләмнәр Германия, Франция һ.б. илләрдә дә җитештерелә башлый.

Каурый каләмнән металл каләмгә күчү акрынлык белән барган, иң әүвәл металл каләм Мәскәү һәм Санкт-Петербургта, аннан соң губерна үзәкләрендә һәм авыл җирендә дә таралыш таба. Татар мәктәп-мәдрәсәләренә металл каләм XIX йөзнең 80 нче елларында үтеп керә башлый.

*Белемнәрне тикшерү өчен сораулар:*

1. Татарлар, аларның бабалары кулланган язу материаллары турында мәгълүмат бирегез.
2. Кара һәм аның төрләре турында сөйләгез.
3. Каләм тарихы.

Әдәбият:

*1. Абзалов Л.Ф. Ханские писцы. Из истории становления и развития канцелярской службы ханов Золотой Орды /Л.Ф. Абзалов. – Казань : Изд-во «Яз», 2011. – 252 с.*

*2. Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы /М. Әхмәтҗанов. – Казан., 2000. – 285 б.*

*3. Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения : Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / сост.: Р.Ф. Исламов, С.Ф. Галимов. – Казань, 2011. – 268 с.*

*4. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. /М.А.Усманов. – Казань : Изд-во Казан. ун-та,1972. – 223 с.*
*5. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. /М.А.Усманов – Казань : Изд-во Казан. ун-та,1979. – 318 с.*

## Кулъязма китапның состав өлешләре

Мәгълүм булганча, китап, хәзерге рәвешкә килгәнче, бик озын юл үткән. Китапның төп ике формасы булган. Кодекс (латин сүзе – китап) – китапның иң киң таралган формасы. Кодекс – кәгазь, пергамент яисә башка язу материалын бергә төпләп бер тышлык эченә алынган китап. Китап – язу материаллары (папирус, пергамент, кәгазь) күпләп тарала башлаган заманнарда барлыкка килә. Аның турында беренче мәгълүматлар б.э.к. 1 нче гасырга карый. Б.э. 4–5 нче гасырларында төзелгән кодекслар – Библияләр сакланып калган.

Кодексның икенче мәгънәсе – законнар җыелмасы. Борынгы Римда кодекслар иң беренче законнар җыентыгы булган. Кодекс-китап византиялеләр аркылы гарәпләргә үтеп кергән, ә гарәпләр аны бөтен Якын Көнчыгышта кулланышка керткәннәр.

Томар (төргәк, свиток) – китапның иң борынгы формасы, Мисырда б.э.к. 3 нче меңьеллыкта барлыкка килгән. Иң беренче томарлар папируска язылган һәм бер-берсенә ябыштырылган битләрдән гыйбарәт булган. Соңрак томарлар (төргәкләр, свитоклар) пергамент, ефәк, тире, аннан соң кәгазьдән дә ясала торган була.

Хәзергә кадәр билгеле булган иң зур томар Британия музее китапханәсендә саклана. «Папирус Гарриса» дип аталучы бу томарның размеры 42,5 X 405 см.

Русларда документация өлкәсендә томар XVII йөзгә кадәр кулланышта була.

Һиндстанда кодекс шулай ук мөселманлык дәверендә барлыкка килә һәм андагы беренче кодекслар гарәпчә язылган китап-кодекс була. Алар VII – IX йөзләрдә тарала башлый.

Татарларга китап-кодекс ислам дине кабул итү белән килеп керә. Һәм, гомумән, татар телендә китап эшенә, китапчылыкка, язмачылыкка караган терминнарның абсолют күпчелеген гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итә: китап, көтебханә, китапханә, китабәт, китабдар (китапханәче), китабфуруш (китап сатучы), кәгазьфуруш, кя-

тиб (күчереп язучы), сәркятип (секретарь), хаттат, дәват-кара савыты, пенал һ.б.

Бер биткә төгәл бер сандагы юл язылган. Ул чакта кәгазь фабрикаларыннан чыккан кәгазьдә язу юлы сызыклары төшерелмәгән була. Кәгазьгә язу юлы сызыгын төшерү махсус җайланма ярдәмендә башкарылган. Ул «мистар» дип атала. Хәзер моңа охшаш җайланмаларны «транспарант» дип атыйлар.

Биттәге текст кайвакытта кыса (рамка) эченә алынган. Бигрәк тә китапның баштагы һәм азактагы өлешендәге текст кыса эченә алынган була. Китапның исеме, шулай ук бүлек, ягъни баб исемнәре башка кара, еш кына кызыл яисә яшел төстәге кара белән язылган. Иң элек текст язылган, ә баб-бүлек исемнәрен язу өчен буш урын калдырылган, текст язылып беткәч кенә, баб исемнәре куелган.

Китапның кереш өлешен – «мөкаддәмә» яисә «дибаҗә», бетем өлешен «хәтимә» дип атаганнар, эчтәлек «фиһрист», яисә «мөндәриҗә» дип аталган. Типик татар кулъязмаларының форматы: биеклеге 18–25 см, киңлеге 12–16 см. Әлбәттә, зур һәм шырпы кабы форматындагылары да очрый. Китап форматын татар үзенчә дә билгеләгән: мәсәлән, зур кул, урта кул, кечкенә кул китап. Китапларда полялар шактый киң, 6–7 см калдырылган – комментарий (шәрех) язу өчен. Үзе өчен генә күчерелгән кулъязмаларда полялар калдырылмаган диярлек. Битләрнең нумерациясенә игътибар итсәк, XIX йөз урталарына кадәр татар кулъязмаларында бит саннары куелмаган. Нумерация урынына «кустод» кулланылган, гарәпчә аны «хафиз» дип атаганнар («саклаучы» мәгънәсендә).

Кулъязма китап (кодекс) төрле өлешләрдән тора. Ул иң әүвәл төрле характердагы бизәкләр белән зиннәтләнгән гонван, ягъни китап (бүлек) исеме белән башланып китә. Әгәр дә китап төрле әсәрләр җыелмасыннан тора икән, ул «мәҗмагъ (мәҗмуга) җыентык» дип аталган. Китапка теркәлгән әсәр композицион яктан түбәндәге өлешләрдән торган: баб, кыйсем, җилд, җөзьә. Коръән, Шәрхел-викая, Хөласәтел-фәтави кебек төп, абруйлы һәм зур, калын кулъязмалар, кагыйдә буларак, баб һәм фасылларга бүленгән.

Элек татарда әдәбият теориясе (гаруз) – жанр ачыклыгы хөкем сөргән, ягъни кулъязмада теге яки бу әсәрнең жанры ачык күрсәтелгән: бәет, мәснәви, нәзым, робагый, хикәят, кыйсса, рисалә, газәл, касыйдә.

Әсәрнең эчендә үк еш кына исеме аталып, кызыл кара язу белән төп тексттан аерылып торган. Хәзерге вакытта мәгънә ягыннан башка сүзне һәм җөмләне аеру ысулы аерым юлга чыгару (кызыл юл), бүлгәләү булса, элек төс белән генә аеру гамәлдә булган.

Бүлек-фасыл башлары, гадәттә, кызыл яисә яшел кара белән төп тексттан аерым буларак стильдә язылган.

Кульъязма азагында, гадәттә, колофон, икенче төрле әйткәндә, аның үзенә күрә «паспорты» урнаштырылган. Анда авторның яисә күчерүченең исеме (кайвакытта кыскача шәҗәрәсе), кульъязманың кайда һәм кайчан күчерелүе хакында мәгълүматлар теркәлгән. Колофонның әһәмияте шунда ки, андагы мәгълүматлар нигезендә теге яки бу төбәктә урнашкан мәгърифәт учаклары – мәдрәсәләр һәм күренекле педагог-галимнәр хакында мәгълүмат алып була. Еш кына күчерүче кульъязма азагына киләчәктә бу китапны укучыларга үзенең шигъри теләк-васыятьләрен дә теркәп куя торган була.

*Моны яздым ядкәрь улмак өчен,*
*укыганнар бер дога кылмак өчен.*

Әгәр дә күчерүчедә юмор хисе ташып тора икән, ул бу багышлауны түбәндәге рәвештә теркәгән:

*Ошбу китап иясе*
*Яшел чикмән киясе,*
*Ходай язган булса,*
*Кыз куйнына керәсе.*

Әмма күпчелек кульъязмалар күчерүченең үзе өчен эшләнгәнлектән, анда конкрет мәгълүматлар бик саран теркәлгән.

Кайбер очракларда китап күчерүченең исеме сан (цифр) белән дә күрсәтелгән.

Китап саклауның төрле ысуллары булган. Кайбер китап сөючеләр аларны махсус сандыкларда саклаганнар. Торак йортларда зур булмаган китап шүрлеген түрдә, түшәм астына ук урнаштырганнар. Бу яшь балалар кулы җитмәсен һәм кыш көннәре ишектән кергән салкын белән китап парланмасын өчен эшләнгән. XVIII йөзнең икенче яртысында кайбер морза яки бай сәүдәгәр йортларында китап шкафлары күренә башлый. Аеруча кыйммәтле китапларны саклау өчен махсус каплар да кулланылган. Өстәлдә яки шүрлектәге китап өстенә махсус япма да япканнар. Киштәдә яки өстәлдә яткан Коръән өстенә башка китаплар кую тыелган.

## Китап бизәү сәнгате

«Миниатюра» атамасы итальянча кызыл буяуның бер төрен аңлатучы сүздән ясалган. Миниатюра композицион төзелеше ягыннан да, тематиканы колачлау җәһәтеннән дә зур картина шикелле, ләкин аның кечерәйтеп ясалган күчермәсе рәвешендә була.

Борынгы Греция, Рим кулъязмалары, шулай ук Көнбатыш Европа кулъязмалары өчен миниатюралар ят нәрсә түгел, дөресрәге бу кулъязмаларда миниатюралар гадәти элемент дип әйтергә була. Шулай ук борынгы рус-славян кулъязмалары да миниатюралар белән бизәлгән. Мәсәлән, XVI гасырның II яртысында Мәскәүдә митрополит Макарий инициативасы буенча 10 томлы Лицевой свод дигән хезмәт төзелә. Бу унтомлыкка төрле елъязмалар, мәсәлән, Никон елъязмасы, 1512 елгы Хронограф һ.б. тарихи хезмәтләр кертелгән. Хезмәт үзенә күрә иллюстрацияләнгән бөтендөнья тарихын күз алдына китерергә һәм Иван Грозный монархиясе бөтендөнья тарихының дәвамы һәм аның иң югары ноктасы дигән фикерне уздырырга тиеш булган. Бу 10 томда барысы 16 меңгә якын иллюстрация файдаланылган. Лицевой свод текстка караганда иллюстрацияләр күбрәк урын алып торган беренче рус китабы булып та санала. Әлеге тарихи хезмәт Мәскәү князьләренең балаларын тәрбияләү, аларга белем бирү өчен төзелгән дигән фикер дә бар. Мондый китапларда, хезмәтләрдә миниатюраларга идеологик йөкләмә дә салынган, ягъни иллюстрацияләр князь хакимиятенә мәдхия җырларга, аның законлылыгын расларга, абруен күтәрергә тиеш булган. XIV йөз ахырында – XV йөз башында кайбер миниатюраларда кеше фигуралары реалистик пландарак ясала башлый. Рус-славян кулъязмаларындагы миниатюраларның күбесендә дини сюжетлар тасвирланган. Библия, Евангелия кулъязмаларындагы бизәкләрдән тагын үсемлек орнаментын (үлән, ботак, яфрак, чәчәк, җиләк-җимеш һ.б.) күрсәтергә була.

Татар кулъязмаларында орнамент, бизәк бик ярлы. Ни өчен шулай, сәбәбе нидә бу күренешнең? Төп сәбәбе – 1552 елда татар халкының дәүләтчелеге бетерелү. Беренче карашка дәүләтчелек һәм кулъязма китап, андагы миниатюралар арасында бернинди бәйләнеш юк кебек. Ләкин бу беренче карашка гына. Дәүләтчелек бетерелгәч, патша царизмы үзенең колониаль сәясәтен, иң беренче чиратта татарның өстен катлауларына, морза-дворяннарга һәм руханиларга каршы юнәлдергән, чөнки 1552 елдан соң оппозициядә калган

татар морзалары царизмның потенциаль дошманнары булган. Шуңа күрә патша хөкүмәте төрле юллар белән татар феодалларын бетерергә тырышкан, аларны сәяси яктан чәрдәкләгән (оешмалары булмаган) һәм, җирләрен тартып алып, икътисади яктан зәгыйфьләндергән. Шуның өстенә татар халкына, бигрәк тә аның өстен катлауларына карата руслаштыру, чукындыру сәясәте уздырган, ягъни аларны идеологик яктан да изелүгә дучар иткән. Бу уңайдан Беренче Петрның 1713, 1714 еллардагы указларын да искә төшерү җитә. Әйтик, бу еллардагы указлар буенча чукынмаган татар феодалларының крепостнойлары азат ителә, җирләре, биләмәләре дә тартып алына. Шулай итеп феодаллар сыйныфы икътисади яктан зәгыйфьләнә, алар «чабаталы морзалар» дәрәҗәсенә төшәләр. Ә инде хәерчелеккә төшкән, җиреннән куылган кешедә бизәкле китап кайгысы калмый.

Феодаллар сыйныфының тарихи язмышын белми торып, татар тарихының күп кенә мәсьәләләрен дөрес аңлап булмый. Феодализм дәверендә китапның, кулъязма китапның төп заказчылары морзалар, ягъни феодаллар була. Димәк, татарда феодаллар сыйфаты шул дәрәҗәгә төшкәч, төп заказчы да үзгәрә, бетә бара, ә XVIII гасыр азакларында татарның дөньяви феодаллар урынын руханилар ала бара. Мөселман руханиларының рәсемгә, сурәткә мөнәсәбәте тискәре икәнлеге мәгълүм факт. Хәзерге көнгә килеп җиткән татар кулъязмаларында классик Иран, Төркия, Һиндстан кулъязмаларына хас булган миниатюралар күзәтелми. Бу 1552 елдан соң мондый төр кулъязмаларның заказчысы булган дөньяви татар феодалларының сыйныф буларак юкка чыгуы белән аңлатыла. Тора-бара җәмгыятьтә алар урынын алган дин әһелләре, әлбәттә, мондый «көферлеккә» бара алмаган. Бары тик кайбер кулъязмалар гонваны килешле генә чәчәк орнаменты һәм геометрик формалар белән бизәлгән.

Коръәндә турыдан-туры рәсем ясауны тыйган аятьләр юк. Әмма, ислам дине, асылда, рәсемгә, җан ияләрен сурәтләүгә каршы чыккан. Кайбер галимнәр моны болай аңлаталар: ислам барлыкка килгәнче, мәҗүси гарәпләрнең һәр кабиләсенең үз алласы булган һәм аның сыны Кәгъбәтуллада да торган, шул рәвешле аларга табыну, культ ясау яшәп килгән. Христиан динендә икона ясау, аңа табыну традициясе дә ныклап урнашкан. Яңа барлыкка килгән ислам дине, әлбәттә, башка дин атрибутларын турыдан-туры үзенә кабул итә алмаган. Һәрбер дин үзенең атрибутлары, ритуаллары белән башка диннәрдән аерылып тора. Шуңа да карамастан, ислам дине таралган илләрдә

урта гасырларда ук (Төркия, Иран, Һиндстан) кеше сурәте ясалган кулъязма китаплар язылган. Эре чиновник заказы белән ясалган бу кулъязмаларда дини һәм дөньяви манзаралар сурәтләнгән. Әлбәттә, композицион яктан караганда бу кулъязмалардагы миниатюралар Көнбатыш Европа рәсем сәнгатеннән бик нык аерыла.

Татарда рәсем сәнгатенең алга китмәвен ислам дине тәэсире белән генә аңлатуның ялгыш, дөрес булмавын безгә күрше халыклар мисалында да күрергә була. Мәсәлән, христиан динендә булган мари, чуаш, удмурт, коми, мордва халыкларында рәсем сәнгате 1917 елга кадәр үсеш алмаган. Бу, иң беренче чиратта, матди мөмкинлек һәм мәдәни мохит булмау белән аңлатыла.

Югарыда әйтелгәннәргә караганда, татар кулъязмалары бизәлеш ягыннан ярлы, чөнки алар асылда заказ буенча эшләнмәгән, ягъни сату өчен түгел, ә күчереп язучының үзе өчен язылган, күчерелгән. Әлбәттә, заказга эшләү очраклары да бар. Әмма заказга эшләү, татарлар колониаль хәлдә яшәгәндә, типик күренеш булмаган. Татар кулъязмасының бар бизәге: кайвакытта бүлек башындагы сүзләрне төрле буяулар белән язганнар һәм текстны рамка (кыса) эченә алганнар. Әлбәттә, аерым очраклар бар. Әйтик, Гали Мәхмүдовның кайбер кулъязмалары бик матур үсемлек орнаменты белән бизәлгән. Татар кулъязмасының бизәге ул – язуның матурлыгы, күчерүченең, хаттатның каллиграфик осталыгы.

## Китап төпләү

Кулъязма китапларның тышлыклары төрле материалдан эшләнгән. Калын, саллы дини китаплар – Коръән, шәригать кануннары һ.б. шундый китапларны гадәттә куе көрән төстәге күн белән тышлаганнар. Бик сирәк булса да металл тышлыклар да очраштыргалый. Мәсәлән, Болгар шәһәрләре урыннарында археологик казу эшләре вакытында табылган шундый тышлыкларның берсе хәзерге вакытта Финляндиянең башкаласы Һельсинки шәһәре музеенда саклана. Күпчелек кулъязмалар исә катыргы белән тышланган. Кул астында катыргы булмаган очракта, берничә иске кулъязма битен камыр белән ябыштырып, катыргы тыш ясаганнар һәм аны өйдә тукылган киндер материя белән тагын бер кат тышлап куйганнар. Кайвакытта

тышлык катыргысын татарга кагылышлы русча кулъязма/басма документлардан кораштырып ясаганнар.

Тышлыклар арасында тактадан, гадәттә юкә тактасыннан эшләгәннәре дә очрый. Кырып юылган идән тактасы яисә агач өйнең бүрәнәсе сап-сары булып, көзге бодай төсле, күрер күзгә ямьле булып тора – бу китап тышлары да иң әүвәл шулай булгандыр. Гасыр, гасыр ярым, ике гасыр кулдан-кулга йөри-йөри алар инде шактый карала төшкәннәр. Кипкәннәр, таш идәнгә төшсә, чынаяк тәлинкәсе шикелле келтерәп урталай ярылырга гына тора. Мондый тышлыкларны кулга алгач, сап-сары тактага каурый каләм белән Әбугалисина шигырьләрен күчереп утыра торган борынгы татар битекчесе күз алдына килә. Һәр илнең халкы үзенең хәле җиткән материал белән эш иткән. Китап кебек олы мәдәни, тирән мәгънәле бернәрсәгә әнә шундый җирле материалның кулланылуы ул – бик тә гыйбрәтле тарихи бер факт. Шәрыкъта китап тышлыгы сыйфатында мондый (такта) тышлык очрамый. Бу бары безгә генә – урманлы илгә генә хас нәрсә (әлбәттә, руста да кулланылган). XVIII йөзнең соңгы чирегеннән башлап яңа язылган китапларга мондый тышлыклар кую гамәлдән чыга башлый. Әмма татар укымышлылары – библиофиллар – «инде боларның заманы үтте» дип, бер дә иске китапларны чыгарып ташламаганнар яисә тышлыгын да каерып алып атмаганнар – саклаганнар, кадерен белгәннәр, тарихи хатирә итеп караганнар.

Кулъязма китаплар шактый чыдамлы итеп эшләнгән: ул тиз генә тарала торган түгел, тышлык катыргысын җиңел генә төбеннән кубарып алырлык түгел, ул дәфтәрнең төбенә шулчаклы нык итеп, кысып беркетелгән: инде 100–200 ел гамәлдә йөреп, ничәмә буын укучылар ачып тарткалаган булса да, аны аерып алыр өчен шактый көч куярга туры килә.

Китап тышлыгы эстетик функция дә үтәгән, сакланып калган бизәкле тышлыкка ия кулъязмалар шуны ачык күрсәтә. Татар җәмгыятенең матди җитештерә алу, көнкүреш сәнгате дәрәҗәсен дә күрсәтә бу тышлыклар.

Кулъязма китап тышлыкларындагы һәм төпләрендәге күн һәм төрле тукымалар XVIII–XIX йөзләрдә Казан татар фабрикаларында эшләнгән. Димәк, бу ягы белән тышлыклар татар матди культура, һөнәрчелек тарихы өчен бер материал булып тора. Чөнки, гадәттә, аның үрнәкләре бүтән рәвештә сакланмаучан була, ә китапта кагылгысыз тора бирә.

Китап төпләү эше дә, китап бизәү кебек үк, зур сәнгать булып тора. Әлбәттә, бу эшнең дә үз осталары була. Аларны гарәпчә «сәххаф» дип тә атап йөрткәннәр. Кульязма китапларда «фәлән сумга фәләннән төпләтеп алынды» дигән юллар әнә шул хакта сөйли. XIX йөз башларында билгеле булган кайбер китап төпләүче осталарның исемнәре сакланып калган. Китап тышлыгының эчке ягына яки буш битләргә имза кую, китапны сату-алу, бүләк һәм васыять итү, сәдака итеп бирү хакында язмалар еш очрый. Китап битләре арасына эрелеваклы кәгазьләр кыстырып төпләү төп текстка караган төрле искәрмәләр язу өчен эшләнгән.

Әлбәттә, тормышта синкритик характердагы китап тышлыклары да булган, дөресрәге, теге яки бу төбәк тәэсирен татыган китаплар. Мәсәлән, 1846–1856 елларда Бохара шәһәрендәге мәдрәсәләрнең берсендә – мелла Ирназар мәдрәсәсендә – татар егете Таҗетдин бине Бәшир әл-Болгари исемле шәкерт тарафыннан күчерелгән китап (теле гарәпчә, шулай ук фарсыча шигырьләр дә бар). Язу стиле-палеографиясе Дагыстанныкына тартым, тышлыгы Бохара стилендә яшел катыргыдан эшләнгән, бизәкле, төбе алсу, кызыл күн, ягъни монда һичнинди татарлык юк. Әмма әсәр татарныкы, китапны күчерүче, эшләүче – татар.

Китап дәфтәрләрен тегү өчен тегәрҗеп, ефәк җеп, тимерчыбык кулланылган. XIX йөз азагында – XX йөз башларында Казанда китап төпләү остаханәләре – мөҗәлләдханәләр эшләп килгән. 1910 елларда Пермь Мөселман хәйрия җәмгыяте балаларга китап төпләү һәм футляр ясау һөнәренә өйрәтү остаханәсе ача.

*Белемне тикшерү өчен сораулар:*

1. Кульязма китапның өлешләре хакында сөйләгез.
2. Китапны бизәү сәнгате.
3. Китап төпләү тәртибе.

Әдәбият:

*1. Абзалов Л.Ф. Ханские писцы. Из истории становления и развития канцелярской службы ханов Золотой Орды /Л.Ф. Абзалов. – Казань : Изд-во «Яз», 2011. – 252 с.*

*2. Бибикова О.П. Калам острее сабли /О.П. Бибикова // Восточная коллекция, 2005. – № 1 (20). – 66–83 с.*

*3. Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения : Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / сост.: Р.Ф. Исламов, С.Ф. Галимов. – Казань, 2011. – 268 с.*

*4. Дульский П.М. Оформление татарской книги за революционный период /П.М. Дульский. – 1930.*

*5. Рукописная книга в культуре народов Востока. – Кн. 1. – М. : Наука, 1981. – 557 с.; кн. 2. – 1988. – 547 б.*

*6. Сафиуллина Р. История арабского книгопечатания / Р. Сафиуллина; науч. рук. А.Б, Халидов. – Казань : Иман, 1999.–40 с.*

*7. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. /М.А. Усманов. – Казань : Изд-во Казан. ун-та, 1972. – 223 с.*

*8. Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева улуса XIV–XVI вв. /М.А. Усманов – Казань: Изд-во Казан. ун-та,1979. – 318 с.*

*9. Халидов А.Б. Арабские рукописи и арабская рукописная традиция / А.Б. Халидов; Акад. наук СССР. Отд. истории. Ин-т востоковедения.–М. : Наука, Гл. ред. вост. лит., 1985.–302 с.*

# Татарларда гарәп язуында тудырылган сәнгать әсәрләре һәм рухи һәйкәлләр

## Тугра һәм шәмаилләр

Татарларда гарәп графикасында эшләнә торган каллиграфик сәнгать төрләреннән шәмаил һәм тугралар билгеле.

Тугра ул – хәлифнең, солтанның, ханның, дәүләт җитәкчесенең шәхси билгесе. Ул – гарәп хәрефләрен матур итеп «боргалап» сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән язу. Исемне генә язганда да, аңа формасы белән ниндидер мәгънә бирергә була. Тугра, гадәттә, дәүләт эш кәгазьләренә куелган, ул бу документның авторының билгесе булып торган. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, «тугра» сүзе «мөһер», «ярлык» мәгънәсен аңлата. Хәзерге вакытта да бу сәнгати матур язу төре популярлашып китте. Үзләренә туграны аерым кешеләр генә ясатмыйча, хәтта ки гаилә, нәсел тугралары булдыру да гамәлгә керә башлады.

Шәмаил гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «бәла-казалардан саклаучы язу» мәгънәсен аңлата, ә фарсы теленнән «портрет», «сурәт»

рәвешендә тәрҗемә кылына. Элеккерәк заманда шәмаилләр һәр татар гаиләсенең өй түрендә торган яисә аны ишек башына элеп куйганнар һәм, шулай итеп, ул йортны төрле күңелсезлекләрдән саклавына ышанганнар. Шәмаил – диварга куела торган сурәт, панно. Гадәттә, ул пыялага буяу белән төшерелгән сурәт рәвешендә эшләнә торган булган, хәзерге вакытта график юл белән, компьютерда эшләү очраклары күбәйде, шулай ук кәгазьгә тушь белән дә, хәтта алтын җепләр белән чигеп тә ясыйлар. Ул үз эченә Коръән сүрәләрен, Коръәннән алынган төрле фәлсәфи өзекләрне, афоризмнарны, еш кына Шәрык шигъриятеннән алынган цитаталарны да ала. Күп очракта шәмаилләрдә гарәп хәрефләреннән «Бисмилләһи-р-рахмәни-р-рәхим» дип язылган кош рәсемен очратырга була. XIX–XX йөз башына караган басма шәмаилләрдә, гарәп текстларына өстәп, татарча текстлар да кертү очраклары бар. Басма шәмаилләрне эшләгәндә фон итеп мөселман дөньясының төрле күренешләрен: Мәккәдәге, Мәдинәдәге, Истанбулдагы, Каһирәдәге мәчетләрне төшергәннәр. Шәмаил сәнгать төрен аңлатучы сүз буларак бары тик Иранда гына очрый. Татарлар бу сүзне нәкъ менә фарсылардан алганнар. Татарлар, фарсы шәмаилләреннән аермалы буларак, үз шәмаилләренә җан ияләренең сурәтләрен ясамаганнар.

Тарихтан билгеле булганча, мөселман халкында, шул исәптән татарларда да, биналарны каллиграфик язу белән бизәү традициясе була, соңрак мондый мөмкинлек югалгач, татарлар бу ихтыяҗны шәмаилләрдә канәгатьләндерә башлыйлар, татарларда бәла-казалардан, күңелсезлекләрдән саклаучы, кешенең үз янында йөртә торган Коръән сүрәләре язылган «бөти» дигән язуы булган, менә шушы ике нәрсәнең кушылуы шәмаил сәнгатен үстерергә этәргеч булгандыр да. Татарларда беренче шәмаилләр, пыяланы фольга белән «яктыртып», майлы буяу белән ясалган. Андый шәмаилләрне әле хәзер дә татар өйләрендә очратып була. Мондый төр шәмаилләрне эшләү техникасы белән татарлар Төркия аша танышкан булырга тиеш. Пыяла чәчәкле-яфраклы орнамент белән бизәлә торган булган. Типографияләр ачылу белән, шәмаилләр басма рәвештә эшләнә башлаган, һәм алар шактый популярлашып китә. Казанда XIX йөзнең 40 нчы елларында китаплар белән беррәттән шәмаилләр бастыра торган берничә басмаханә эшли. Аның берсе – Яңа татар бистәсендә, ә икенчесе исә – шәһәр үзәгендәге Л. Шевиц басмаханәсе. Соңрак моннан кала татар дөньясында билгеле булган И.Н. Харитонов, бертуган Кәримов-

ларның басмаханәсе дә мондый эш белән шөгыльләнә. Татарларда шәмаилләргә сорау зур булганлыктан, аларның тиражлары да аз булмый. Басма шәмаилләргә зур сорау тугач, аларны эшләүче осталар да барлыкка килә. Шундыйлардан Госман Салиев, Мөтаһир Яхъя, Морадым бине Ибраһим, Мөхәммәтҗан Хәлиулла улы Хуҗа Сәид, бертуган Әхмәтовлар һ.б. билгеле. 1829 елда Азия басмаханәсе, Казан университеты типографиясе белән кушылгач, Казанда шәмаилләр бастыручы иң зур үзәккә әверелә. Шул ук вакытта кулдан эшләнгән гади генә шәмаилләр дә татар өйләренең диварларын бизәп торганнар.

1928–1931 елларда гарәп графикасының бетерелүе сәбәпле, шәмаил эшләү сәнгате дә сүнеп кала, басма шәмаилләр эшләнми башлый, бу төр сәнгать белән авылда яшәүче халык осталары гына шөгыльләнгән. Шәмаил эшләү сәнгате бары тик XX йөзнең 90 нчы елларында гына яңадан тернәкләнә башлады.

Татар каллиграфларыннан билгеле шәхесләрнен берсе, әлбәттә, Бакый Урманче (1897-1990). Ул Татарстанның, Россия Федерациясенең халык рәссамы, Казахстанның атказанган рәссамы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе. Бакый Урманчы хәзерге Буа районы Күл Черкене авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Аннан 1920 нче елларда Мәскәүдә рәссам сәнгате буенча укый. 1926 елда Казанга әйләнеп кайтып, керамика сәнгатен торгызып җибәрә. Б. Урманче 1960 елдан башлап студентларны Казан университетында каллиграфия сәнгатенә өйрәтә, ул шулай итеп Казан университетында матур язу сәнгатен өйрәткән Мөхәммәдгали Мәхмүдов традицияләрен дәвам итә.

Хәзерге рәссамнарның иҗатында да бу сәнгать төренә игътибар итүчеләр шактый. Шундыйлардан С. Гыйләҗетдинов, Ф. Гыйрфанов, Р. Мөхәммәтҗанов, Н. Нәккашны, Р. Сәлахетдинов, Л. Фәсхетдинова, Ә. Хәлиуллина, В. Ханнановларны күрсәтергә була. Шәмаилләр эшләп кенә калмыйча, шул шәмаил сәнгатен фәнни яктан өйрәнүче Рөстәм Шәмсутов эшчәнлеге игътибарга лаеклы.

*Белемне тикшерү өчен сораулар:*

1. Тугра турында белешмә бирегез.
2. Шәмаилләр турында белешмә.
3. Кулъязма шәмаилләр.

4. Басма шәмаилләр.
5. Каллиграф Мөхәммәдгали Мәхмүдовның эшчәнлеге.
6. Б.Урманче эшчәнлеге.
7. Хәзерге вакытта шәмаил сәнгатенең торышы.

Әдәбият:


*1. Абзалина Р.Ә. Татар халкы тормышында матур язу сәнгатенең рухи мәгънәсе (Татарстан Милли музее тупламалары мисалында) / Р.Ә. Абзалина // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов = Төрки халыкларның сәнгати мәдәнияте чыганаклары һәм эволюциясе : Сборник материалов Международной научно-практической конференции, посвященной 150-летию со дня рождения педагога-просветителя, художника Ш.А. Тагирова (17–18 апреля 2008) / [редкол. Р.Р. Султанова, к. иск. (сост. и отв. ред.) и др.].–С. 120–126.–Казань, 2008.*

*2. Арабская каллиграфия: связь времен и народов = Arabic Calligraphy: Link of Times and Peoples = [каталог выставки мусульманских искусств] / М-во культуры Респ. Татарстан, Гос. музей изобраз. искусств Респ. Татарстан, М-во вакфов и по делам Ислама Государства Кувейт, Кувейт. центр мусульм. искусств; [идея выст.: Рустем Шамсутов, Фарид Аль Али; сост. кат. выст. Лилия Саттарова; ред. и пер. на араб., англ. и рус. яз. Нурия Гараева].–Казань : [Заман], 2010.–64 с.*

*3. Галеев Б.М. "Поющий шамаиль" Баки Урманче / Б.М. Галеев // КАЗАНЬ.–Б.м...–2007.–№4.–С.114.*

*4. Гарәп язуы палеографиясе һәм каллиграфиясе : Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен уку-укыту методик комплексы / В.И. Ульянов-Ленин ис. Казан дәүләт ун-ты; [төз. Ә.Р. Исхакова; ред. Ф Ш. Нуриева].–Казан : Казан дәүләт университеты, 2009.–56 б.*

*5. Исмагилов Н.Ф. Жанр тугры в современном татарском арабографическом искусстве / Н.Ф. Исмагилов // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов : Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 150-летию со дня рождения педагога-просветителя, художника Ш.А. Тагирова (Казань, 17–18 апреля 2008) / [отв. ред. и сост. Р.Р. Султанова].–С. 223–227.–Казань, 2009.–(Серия "Искусство тюркского мира"; Вып. 1).*

*6. Исмәгыйль Н.Ф. Хәзерге татар гарәби язу сәнгатендә тугра жанры / Н.Ф. Исмәгыйль // Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов = Төрки халыкларның сәнгати мәдәнияте чыганаклары һәм эволюциясе : Сборник материалов Международной научно-практической конференции, посвященной 150-летию со дня рождения педагога-просветителя, художника Ш.А. Тагирова (17–18 апреля 2008) / [редкол.: Р.Р. Султанова, к. иск. (сост. и отв. ред.) и др.].–С. 139–142.–Казань, 2008.*

*7. Исхакова А.Р. Состояние искусства красивого письма у татар (конец XVIII – нач. XXI веков) / А.Р. Исхакова // Татарская культура в контексте европейской цивилизации : Материалы Международной научной конференции. (Казань, 3–4 ноября 2009) / [науч. ред. проф. Гилязов И.А.].–С. 32–33.–(Казань, 2010).*

*8. Исхакова Ә.Р. Гарәп язуы палеографиясе һәм каллиграфиясе: Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен уку-укыту методик кулланмасы / Ә.Р. Исхакова; Казан дәүләт ун-ты.–Казан : КДМСУ мәгъл.-нәшр. үзәге, 2009.–80 б.*

*9. Монасыйпов Ш. Бакый Урманче шәмаилләре / Ш.Монасыйпов // Мәдәни җомга.–Б.м...–2002.–22 февр. (№8).–18 б.*

*10. Нәккаш Н. Хәрефләр, тарихлар терелә...: (Н. Нәккаш белән Р. Ягъфәров әңгәмәсе) / Н. Нәккаш // Казан утлары.–Казань.–2008.–№6.–131–137 б.*

*11. Программа спецкурса "Каллиграфия" / Казан. гос. ун-т, Ин-т востоковедения; [сост. Д. А. Шарафутдинов; науч. ред. А.Б. Халидов].–Казань: [б. и.], 2001.–11 с.*

*12. Татарский шамаиль: слово и образ: каталог выставки / Гос. музей Востока, Гос. музей изобраз. искусств Респ. Татарстан, Ин-т яз., лит. и искусства им. Г. Ибрагимова АН Респ. Татарстан, Фонд Марджани; [сост.: И.Л. Алексеев и др.; авт. ст.: Александр Седов, д. ист. н. и др.].–М.: Марджани, 2009.–111, [1] с.*

*13. Фаизов С.Ф. Тугра и Вселенная: мохаббат-наме и шерт-наме крым. ханов и принцев в орнамент., сакрал. и дипломат. контекстах : (альбом) / Сагит Фаиз.–М.; Бахчисарай : Древлехранилище, 2002.–99 с.*

*14. Шамаилы из коллекции Национального музея Республики Татарстан (конец XIX – начало XX вв.): Собрания профессоров И.М.Покровского и Н.Ф.Катанова = Татарстан Республикасы Милли музеенда шәмаилләр коллекциясе (XIX гасыр ахыры – XX гасыр*

*башы) И.М. Покровский һәм Н.Ф. Катанов тупламалары : Альбом / [авт.-сост. Р. Абзалина; редкол.: к.и.н. Р.М. Валеев и др.].–Казань: [б.и.], 2003.–[115] с.*

*15. Шамсутов Р.И. Искусство татарского шамаиля (сер. XIX – нач. XX вв.) / Р.И. Шамсутов; науч. ред. Г.Ф. Сулейманова.–Казань: РенгентЪ, 2001.–183 с.*

*16. Шамсутов Р.И. Символ веры мусульман. Казань – центр формирования профессионального искусства шамаилей / Р.И. Шамсутов // КАЗАНЬ.–Б.м...–1999.–№ 5/6.–С. 89–91*

*17. Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле от прошлого до настоящего /Р . Шамсутов; авт. предисл. Г.Ф. Валеева-Сулейманова.–Казань : Татар. кн. изд-во, 2003.–199 с.*

*18. Юсупова Г. Хранилище легенд, старинный шамаиль / Г.Юсупова // Татарстан –1997.–№2.–С.71–76.*

## Кабер таш язмалары

Татарлар арасында гарәп язулы иң киң таралган истәлекләрнең берсе ул – кабер таш язмалары. Идел буе ислам дине белән танышкач ук, монда яшәүче мөселман халкында кабер өстенә куела торган гарәп язулы, Коръәннән китерелгән өзекләр белән эшләнгән ташлар ясаучы осталар барлыкка килә. Мондый борынгы истәлекләр безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Борынгы Болгар кабер ташларын өйрәнүгә Петр I үзенең 1772 елдагы Болгар шәһәренә сәяхәте вакытында нигез сала. Аның әмере белән иң беренче булып 50 кабер ташының язмалары күчерелә һәм русчага тәрҗемә ителә. Соңрак гарәп язулы кабер ташлары татар галимнәре Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, Г.Әхмәрев, К.Насыйри тарафыннан фәнни рәвештә тикшерелә. Соңрак бу галимнәрнең эшен Һ.Йосыпов дәвам итеп, болгар-татар эпиграфик истәлекләрен өйрәнгән саллы хезмәт нәшер итә. Ф.Хәкимҗанов исә, болгар кабер ташларының телен өйрәнеп, аларны филологик яктан тикшерә. Бу төр тарихи истәлекләрне өйрәнүгә беркадәр игътибар кимеп торганнан соң төрле төбәкләрнең эпиграфик истәлекләре турында матбугатта төрле характердагы мәкаләләр еш күренә башлады.

Кабер таш язмаларын эшләүнең борынгыдан килгән үз традициясе була, XIX–XX йөз башына караган кабер ташлары, нигездә, тү-

бәндәгечә тәртиптә эшләнгән: кабер ташының алгы яктагы иң өске өлешенә чәчәк-яфрак үрелмәләре, ярымай, биш-алты-сигезпочмаклы йолдыз яисә чәчәк рәвешендәге бизәк төшерелгән, тугра сыман яисә гади итеп кенә Аллаһны данлаган, үлемнең котылгысыз икәнлеген искәргән гыйбарә язылган. Ташның урта өлешендә мәрхүмнең кем икәнлеге, исеме, әтисенең исеме бирелгән. Җирләнгән кеше читтән килгән булса, аның ватаны күрсәтелгән. Мәрхүмнең вафат булу датасы һиҗри яки милади ел исәбе белән язылган, кайбер очракларда ике төрле ел исәбе системасы да чагылыш таба. Текст мәрхүмнең гөнаһларын кичерүне сораган төрле формадагы гыйбарәләр белән тәмамлана. Мисал өчен: Аллаһ рәхмәт кыйлсын, Аллаһы шәфәгатьче булсын, Аллаһы Тәгалә каберен нурлы кылсын, Аллаһы Тәгалә каберен оҗмах бакчаларыннан бер бакча итсен һ.б.

Совет чорында куелган кабер таш язмалары югарыда күрсәтелгән традициядән нык кына читләшәләр, хәзерге заман кабер ташларының зур күпчелеге дә борынгы традицияләргә бөтенләй дә туры килми.

Татар кабер ташларының текстлары, гадәттә, татар һәм гарәп телләрендә катнаш язылган. Эпитафияләрдәге язмалар гарәп язуының танылган, киң таралган сөлс, тәгълик, нәсх почеркларында эшләнгән. Кабер таш язмасы, нигездә, оста тарафыннан сайлап алынган бер төрле почерк белән генә эшләнгән, ләкин шулай да, текстының бер төрле, ә Коръәннән китерелгән өзекнең икенче төрле почеркта эшләнү очраклары да бар. Шулай ук дога сүзләре «кабартылып», ә текст чокып ясалу рәвеше дә еш очрый. Осталар кабер таш язмаларының өске өлешен бик матур итеп эшләнгән каллиграфик язу белән бизиләр, гарәп хәрефләрен бик «боргалап» язылган гарәп текстларын кайвакытта укуы да бик авыр. Кайбер кабер ташларының ян-якларында да язулары була, анда Аллаһка мөрәҗәгать сүзләре яки шигъри юллар языла. Ташның арткы ягына язу очраклары бик еш булмаса да, очраштыргалый, монда дини гыйбарәләр языла, ул алгы яктагы язуның дәвамы булып тора, ләкин арткы яктагы язуның аерым мөстәкыйль кабер ташы язуы булу очрагы да бар. Кабер ташының эшләнеш, бизәлеш һәм язуына карап җирләнгән кешенең статусын да билгеләргә мөмкин, бай һәм шөһрәтле кешеләрнең ташлары да мәһабәт, зәвыклы һәм Коръән сүрәләреннән китерелгән өзекләр белән эшләнгән.

Кайбер кабер таш язмаларыннан мисаллар:

*Әл-хөкме Аллаһы*
*Бу мәркадькә дахил улды*
*Казан сәүдәгәре*
*Шакирҗан бине Шәмседдин*
*67 яшендә маһи рамазанның 11 ендә 1329*
*22 нче августта 1911 сәнәи румия*
*Гафәрә Аллаһы зөнүбиһи.*

*Бихөкме Аллаһы Тәгалә*
*Сөнгатулла Хәйрулла мәрхүм угылы*
*Мәмәшев 37 яшендә дарел бәкайа рихләт әйләде*
*1312 сәнәи һиҗрия маһи шәүвәлдә*
*1894 елда мартның 5 нче көнендә*
*мәдфүн улды. Рәхмәтуллаһи рәхмәтән уасигатән.*
*Амин.*

Кабер ташларда төрле гыйбарәләр, гыйбрәтле сүзләр бирү очраклары да бар:

*Үлем – касәдер, һәркем шул касәдән эчәр.*
*Кабер – ишектер, һәркем шул ишектән керер.*

Кабер ташның ян-ягына язылган язулардан Җәлаледдин Яхъя угылының match кaберташ язмасыннан мисал китереп була. Анда болай, дип язылган:

Сул ян як: *Каберемә заир улан әхвалемә идеи нигяһ.*

Уң ян як: *Рухыма кыйлсын дога вә халедән улсын агяһ.*

(Мәгънәсе: Каберемне зиярәт итәргә килүче хәлләремне күрсен, рухыма дога кылсын һәм үзенең дә шул хәлләрне кичерәчәген дә белеп торсын.)

Кабер таш язмаларында шигъри юллар да очратырга була:

*Кәрәм әйләп (киң күңеллек күрсәтеп), догада итегез йад,*
*Тәсаддыкълә (сәдака биреп) кыйлыгыз рухымны шат.*
*Бу кабер хәлләрен сагышласагыз,*
*Безгә Коръән укып багышлайасыз.*
*Безем (безнең) Коръән укырга хәлемез юк,*
*Хәер-ихсан кыйлырга (сәдака белән ярдәм итәргә) малымыз юк.*

*Мәркадеңдә (гүреңдә) ят син, әнкәм,*
*Кайгы-гамьләр чикмичә.*
*Юк күрешмәк инде безгә,*

*Йәүме мәхшәр (мәхшәр көне) җитмичә.*

*Әй мөселман, Аллаһының киң рәхмәте булсын сиңа,*
*Бу кабергә утырып кыйлсаң әгәр изге дога.*

*Йа, вакыйфән би кабри*
*мөтәфәккирән би әмри.*
*Бил-әмси күнтү мисликә*
*гадән тәсайир мисли.*

*(*Татарча: *Әй, каберем янына килеп басучы, минем хәлне фикерлә. Бүген шушы хәлендә булсаң, иртәгә минем кебек булырсың.)*

Кабер ташын язучы оста ташларга үзенең исемен дә уеп язган.

Мисаллар И.Һадиевның «Зират тынлыгында еллар хәтере» (Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2000. – № 1/2) һәм И.Һадиев, Р.Мәрдановның «Саба төбәгенең эпиграфик истәлекләре» (Казан утлары. – 2006. – № 8.) мәкаләләреннән алынды.

*Белемнәрне тикшерү өчен бирем:*

1. Кабер таш язмаларын өйрәнү тарихы.
2. Болгар чоры кабер таш язмалары, аларның үзенчәлекләре.
3. Казан ханлыгы чоры кабер таш язмалары, аларның үзенчәлекләре.
4. Һәр студентның үз төбәгендәге борынгы кабер ташлары, аларны өйрәнү, саклау проблемаларына караган иҗади эше (доклад).

Әдәбият:

*1. Әхмәтҗанов М. Ташка тарих теркәүчеләр / М. Әхмәтҗанов // Фән һәм тел = Наука и язык.–Казань.–2006.–№4.–19–21 б.*

*2. Әхмәтҗанов М. И. Татар эпитафиясе сәнгате хакында / М.И. Әхмәтҗанов // [Татарский народ после 1552 года: потери и приобретения] = Татар халкы 1552 елдан соң: югалтулар һәм табышлар: [Материалы науч.-практ. конф., 4 окт. 2002 г., Казань] / [Исполн. ком. "Всемир. конгресса татар", Акад. наук Респ. Татарстан, Ин-т истории им. Ш. Марджани; отв. ред. Р.Р. Хайретдинов].–Казань, 2003. –167–173 б.*

*3. Әхмәтҗанов М. Татар зиратлары / М. Әхмәтҗанов // Казан утлары.–1997.–№12.–143–153 б.*

*4. Мәрданов Р.Ф. Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре / Р. Мәрданов, И. Һадиев.–Казан : Тамга, 2008.–147 б.*

*5. Мөхәммәтшин Җ. "Үлгәннәрнең каберен бел..." / Җ.Мөхәммәтшин // Мирас.–Б.м...–2002.–№6.–154–156 б.*

*6. Мухаметшин Дж.Г. Эпиграфические памятники татар Поволжья и Приуралья. Региональные особенности и этнокультурные варианты : Автореф. дис. канд. ист. наук / Д. Г. Мухаметшин; Ин-т истории им. Ш. Марджани.–Казань: Б.и., 2004.–28 с.*

*7. Мухаметшин Дж. Г. Эпиграфические памятники города Булгара / Д. Г. Мухаметшин, Ф. С. Хакимзянов.–Казань: Тат. кн. изд-во, 1987.–125,[3] с.*

*8. Һадиев И. Саба төбәгенең эпиграфик истәлекләре / И. Һадиев, Р. Мәрданов // Казан утлары. –2006.–№8.–162–170 б.*

*9. Һадиев И. Зират тынлыгында еллар хәтере. / И.Һадиев // Гасырлар авазы=Эхо веков. –2000.–№1/2.–82–90 б.*

*10. Основные археологические и этнографические памятники Зеленодольского района // Татарстан.–2006.–№5.–С.39.*

*11. Список археологических, эпиграфических и историко-архитектурных памятников Ютазинского района Республики Татарстан // Ютазинский регион: проблемы истории и культуры : Материалы Региональной научно-практической конференции "Ютазинский регион: проблемы истории и культуры (Село Байряка и Ютазинский район в системе культур и цивилизаций Юго-Восточного Татарстана и Волго-Уральского региона)" (пгт Уруссу – с. Байряка, 17-18 мая 2012 г.) / науч. ред. и сост. вып. – А.А. Бурханов; Район. совет и Исполн. ком. Ютаз. муницип. р-на РТ [и др.].–С. 348–350.–Казань, 2012. (Восток-Запад: Диалог культур и цивилизаций Евразии; Вып. 11).–Прилож.*

*12. Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык / Ф С. Хакимзянов; отв. ред. Э.Р. Тенишев; АН СССР, Казан. фил., Ин-т яз., лит. и истории им. Г. Ибрагимова.–М.: Наука, 1987.–191,[1] с.*

*13. Хисамиева Г. Надгробие как исторический документ: региональный аспект / Г. Хисамиева // Эхо веков = Гасырлар авазы.–2007.–№1.–С. 27-33.*

*14. Хисамиева Г.К. История изучения надгробий юго-востока Татарстана: Материалы Лихачевских чтений. 3–5 апреля 2008 г./*

*Г.К.Хисамиева // [отв. ред. С. Ю. Измайлова].–Казань, 2008.– С. 287–291.*

*15. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Г.В. Юсупов; АН СССР, Казан. фил.; отв.ред. М.Х. Гайнуллин.–М.; Ленинград : Изд-во Акад. наук СССР, 1960.–[322]с.: табл.*

## Хөсне хат – матур язу

Җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр белем бирү өлкәсендә югары бер баскычка күтәреләләр. Балаларга төрле яклы, киң кырлы гыйлем бирү максат ителә башлый. Уку гына түгел, ә яза белү, бигрәк тә матур яза белүнең мөһимлеге алгы планнарның берсенә куела. XX йөз башында күптөрле дәреслекләр языла башлый. Шул исәптән матур язарга өйрәтә торган «Хөсне хат» дәреслекләре дә дөнья күрә. Шундыйлардан бертуган Кәримевләр басмаханәсендә нәшер ителгән «Хат мөгаллиме» дигән дәреслек-китаптан өзек китерәбез.

*«Сөекле балалар!*

*Сез кечкенә булсагыз да, язуны таныйсыз, матур булмаса да, бик дөрес итеп яза да беләсез. Инде шул язуны матур итеп язу бар, аңарга «хөсне хат» дип әйтәләрдер. Хөсне хат мәктәптә чагында өйрәнергә тиешле вә бик кирәкле һөнәрләрнең беренчеседер. Менә шул һөнәрне алырга сезне кызыктырыр өчен, бик матур итеп язу турысында берникадәр сүзләр язып, китап шәкеленә куям. Сез дә аны укып, күзегез матур язуга өйрәнер, һәм үзегез дә шуның төсле матур итеп яза башларсыз.*

*Мәктәптә хөсне хат өйрәтә торган мөгаллимегезнең биргән вазифаларын бик чын күңелегез илә матур чыгарырга тырышырсыз. Дөрестән дә, балалар, язуың матур чыкса, үзеңә дә күңелле, укытучыга да күңелле буладыр. Матур язуның төрле исемнәре бар, әмма сезгә бу китапта күрсәтелгән язулар «хатты сөлс», «хатты нәсх», «хатты тәгълик», дип аталадыр. Сез тырышсагыз, ул язуларның барлыгын да өйрәнерсез дә «хаттат» (матур язучы) исемен алырсыз. Әгәр дә сез язулардан берничә төрлесен өйрәнеп матур-матур язулар язсагыз, сезнең ул язуларыгызга һәркем: «Аһ, шуның кебек яза белсә идем», – дип кызыгып күзләрен алмастай булып карап торырлар. Күрәсез бит: матур язылган язуларны кадерләп стеналарга күз алдына тагып куялар. Бәһасен чикләргә һич мөмкин булмаган яшь-*

*лек заманының кадерен белеп, гыйлем, мәгърифәт хасил итәргә бик тырышырга вә бар гайрәтегезне сарыф итәргә кирәк, чөнки яшь чагында кешенең фикере, уе әллә нинди артык нәрсәләр илән чубалан-мыйдыр. Яшь чагында күңелгә алган нәрсәләр, никадәр заманнар үтсә дә, ташка язган кеби, бетмидер. Бала вакыттагы һәрнәрсә олыгайгач та күз алдындагы кеби зиһендә торадыр.*

*Шулай да, яшь чагында белгән нәрсәләр илә генә канәгатьләнеп калырга ярамый. Пәйгамбәребезнең: «Гыйлемне бишектән ләхеткә кадәр эстәгез», – дигән сүзен күңелдә тотып, һәрвакыт белемне арттырырга тырышырга кирәк, чөнки мәктәптә бар нәрсәне дә белеп булмый, беленмәгән бик күп нәрсәләр каладыр. Шуның өчен һәрвакыт китап илән башыгызны киңәйтергә тырышырга кирәк.*

*Уку-язу ни эшкә ярый?*

*Балалар! Сез укыйсыз, язасыз. Уку-язуның эшкә яраганлыгын мин сезгә аңлатыйм: укып-яза белгән адәмнәр бакчадагы җимешле агачларга охшаганнар. Бакчачылар җимеш бирә торган агачларны һәрвакыт карыйлар, су сибәләр, коры ботаклары булса, кисеп ташлыйлар. Уку-язу белгән адәмнәргә дә шуның шикелле һәркем игътибар итеп, аларга һәрвакыт кадер-хөрмәт итәләр. Беләсез, бакчада җимеш бирми торган агачлар да буладыр, әмма бакчачылар аларны һич карамыйлар, кыш килеп җитсә, аларны төпләреннән үк кисеп, утын ясыйлар.*

*Уку-язу белмәгән адәмнәр дә җимешсез агачлар шикелле һич кадәр үк кирәкләре булмаган кеше сурәтле агачлардыр. Уку-язу белгән адәмнәр дөньяның икенче кырыендагы адәмнәр илән күрешер, алар белән сөйләшер.*

*Ничек сөйләшерме, дисез?*

*Менә хәзер сезгә әйтәм: икенче падишаһ йортында торган бер адәм сезгә хат язар да, аны сезгә җибәрер, сез ул хатны укып, аның ни язганнарын барын да белерсез, менә ул хатны уку – аны язган адәм илә сөйләшүдер.*

*Янә мин сезгә уку-язу белгән бер кешенең хикәясен сөйлим, сез тыңлагыз: бервакытны бер адәм, кая гына бер язу күрсә дә, аны укымыйча китмәскә гадәтләнмеш. Бу кеше беркөн су эчү өчен бер чишмәгә бара. Чишмәнең янында язулы бер таш күрә, ул ташта: «Бу ташның артында бер язулы таш бар, аны укыган кешегә бик зур шатлык булыр», – дип язылган. «Бу чишмәдән бераз читтәрәк бер чүлмәк күмеп куелган алтын бар: аны ал да бу чишмәне төзәт-*

*тер, артканы сиңа булыр». Бу язуны укыгач, ул җирне табып, алтыннарны казып чыгара да бай буладыр. Әгәр ул адәм укый белмәсә иде, чишмә янында булган таштагы язуны укый алмас иде дә алтыннардан баш кагар иде.*

*Менә, балалар, уку-язу белү адәмнең бәхетле булуына ярый икән.*

*Балалар! Адәмгә дөньяда торыр өчен коры гыйлем генә җитмидер, гыйлем өстенә гүзәл холык та кирәк. Гыйлем булып та, әхлагы начар булса, ул кешедән һәркем кача, аның гыйлеменнән һичкем файда ала алмыйдыр.*

*Кеше кеше булганлыгы өчен кешедән башка тора алмыйдыр. Синдә никадәр гыйлем булса да, әхлагың начар булса, кешеләр синнән кача, кеше илән катыша алмыйсың. Кеше илә катышмадыңмы, дөнья сиңа бер зиндан булып күренәдер, зиндан кешене туйдырган кебек, син дә дөньядан туясың, дөньяда торуның кызыгы китәдер».*

1911 елда галим, педагог Гайнетдин Әхмәрев, бу проблемага фәнни яктан якын килеп, матур язуга өйрәтүнең мөһимлеге белән бергә аны укыту методикасын да ачып бирә. Ул үзе дә, мәктәп-мәдрәсәләрдә белем биргән укытучы буларак, бу мәсьәләнең җитдилеген аңлый һәм «Хөсне хат» дигән китабында бу проблеманы яктырта. Шулай ук аның китабының да кереш сүзе биредә тәкъдим ителә. Текст XX йөз башында кулланылган тел белән, үзгәртелмичә бирелде.

*«Голүм мәктәпләрендә балаларны заманның ысулынча укытуга муафикъ рәвештә тәртип ителгән берничә төрле әлифба вә кыйраәт китаплары күрелсә, язу дәресләре өчен, ягъни уку илә бәрабәр язуны да үзенә махсус ысуллар үзрә үгрәтергә ярарлык рәвештә тәртип ителгән һичбер төрле әсәр күрелгәне юк. Моның сәбәбе: мөхәррирләр тарафыннан язуга тиешенчә әһәмият бирелмәгәнлектән булырга кирәк. Әмма адәм баласына укый белүенә дәрәҗә зарур булса, яза белү дә шулкадәр үк зарурдыр. Укуга караганда язуга үгрәнү әһәмиятлерәк булганлыктан, иске тәртип илә укып йөргән кемсәләрнең бәгъзеләре бөтенләй яза белмиләр яки, белсәләр дә, язулары бик зәгыйфь була, хәтта үз исемнәрен дөрес яза белмәгәннәре дә бик күп. Бу рәвештә нәкыслык һичбер милләттә күрелгән юк, һәр милләттә укый белгән кемсә үз дәрәҗәсендә яза да белә. Укый белеп тә, яза белмәү, әлбәттә, баланың зиһенсезлегеннән яки язуның читенлегеннән килмидер, бәлки язуга бөтенләй үгрәтелмәгәнлектән яки тәртипсез рәвештә үгрәтүдән киләдер. Шул ук адәмнәр, җи-*

*ңелрәк ысулда гүзәл тәртипләр илә үгрәткәндә, һич шөбһәсез, яза беләчәкләр, хәтта гүзәл язуларга да муафикъ була алалар иде.*

*Һәр фәннең үзенә махсус ысул вә тәртипләре булган кеби, язуның да үзенә махсус ысуллары бар. Безнең мөгаллимнәргә дә, балаларны тиз заманда йиңеллек илә гүзәл вә дөрес язарга үгрәтер өчен мәгърифәтле таифәләрдә күрелгән мәкамәл вә яңа ысулларны белү лязим буладыр. Ысулсыз вә тәртипсез рәвештә үгрәтү юлсыз йөрү илә бәрабәр.*

*Язуга махсус ысуллардан мәгълүмрәкләре шулар:*

*1) Иске тәртип. Монда язуга яки бөтенләй үгрәтелми, ягъни хатт тәгълиме юк, хәлфә укырга гына үгрәтә, яки хәрефләрнең аерым языла торган рәвешләрен һәҗҗа тәртибендә әүвәл хәлфә үзе укып күрсәтә. Балалар шуны тәмам күңелләренә беркеткәнчә тәкрар-тәкрар күчереп язалар, әмма хәрефләрнең ничек язылганын (кайдан башлап, кайда туктаганын) белмәенчә, хәрефнең үлчәвен вә ниндәен хәрефнең сурәтен ясап кына утыралар. Аерым хәрефләрне бер дәрәҗә язарга үгрәнгәннән соң, махсус язмалардан күчереп, икеөч хәрефле һәҗҗалар, ягъни сүз кисәкләре вә аерым сүзләр (кеше исемләре) дә яза башлыйлар. Кагыйдәи хөсне хат илә ашна булмаган хәлфәләрнең язуга үгрәтүе шуннан гыйбарәт. Соң гасырларда Европада мәшһүр педагоглар чыгып, укыту тәртипләрен үгрәтү илә бәрабәр язу ысулын йиңеләйтергә дә чаралар эзли башлаганнар.*

*2) XIX гасыр әүвәлендә мәшһүр Песталлоццының шәкертләре балаларны язуга йиңелрәк рәвештә үгрәтү өчен яңа бер ысул уйлап тапканнар. Тәртибе шул рәвешле: мөгаллим хәрефләрне (хәреф-һәҗҗа тәртибендә) әүвәл үзе язып яки аерым нокталардан хәреф сурәте ясап, балалар шуның өстеннән сызып йөртәләр. Яңарак чыккан заманнарда бу ысулның тарафдарлары күбәеп, бәгъзы урыннарда истигъмале дә озакка тартылган. Мәшһүр философ Гиллард 1839 нчы сәнадә Вена шәһәрендә басылган китабы илә нокталардан оештырылган хәрефләр өстеннән сызып йөртү балаларга зиһен арттыру өчен дә файдалы икәнен исбат кылырга тырышкан, ләкин ул бу фикерендә ялгыз берүзе генә калган. Мөхәррирләрнең күбесе әүвәлдән язып куелган хәрефләр өстеннән сызып йөртү ысулының зиһен арттыруга һичбер төрле файдасы юклыгын, хәтта балаларның истигъдар куәтен манигъ булмаганлыгын да сөйләгәннәр. Файдасызлыгы вә бер микъдар зарары барлыгы да исбат ителгәннән соң, бу ысул мәктәпләрдән бөтенләй чыгарылган. Бу көннәрдә Европа мәк-*

*тәпләрендә истигъмаль ителгәне ишетелгән юк. Шулай да безнең китапчылар шул яраксызлык сәбәпле, Европа мәктәпләреннән чыгарылып ташланган ысул үзрә тәртип ителгән язу дәфтәрләре бастырып, хәзер дә таратып яталар. Ишетдекемезгә күрә, бу рәвешле иске хәрефләрнең күчергечләре Истанбулдан китерелә, имеш. Әүвәлдән язып куелган хәрефләр өстеннән сызып йөртү ысулы үзрә үгрәтү өчен тәртип ителгән дәфтәрләрдә һәрбер хәрефкә тигез урын калдырыла, ягъни хисабы тигез була. Әмма хәрефләрнең язылуы читенлектә бар да бер дәрәҗәдә түгел, күбрәк җөзэле хәрефләрне язарга башкаларга караганда артыграк вакыт һәм күбрәк урын да кирәк була. Күп мәртәбә бер хәрефне генә язып утыру (хосуса, электә язып куелган хәрефләр өстеннән һичбер уйсыз, фикерсез, машина кебек кенә сызып йөртү) дәрестән балаларның ихлас кайтуга сәбәп була. Әлбәттә, ихлас белән зәвыкланып эшләгәндә генә дәрес алга бара. Читенлек вә зәвыксызлык сәбәпле, әүвәлге бер-ике сәтырда хәрефләрне бер дәрәҗә язарлык рәвештә язалар, әмма өченче-дүртенче сәтырларда язулары начарлана башлый, ахырда бөтенләй зәгыйфьләнә. Дәхи күчергеч нәкадәр яхшы вә гүзәл рәвештә язылган булса да, мөгаллимнең балалар алдында күзәтеп язуына йитмидер, һәр хәрефнең язылу рәвешләрен, үлчәвен вә ниндәен җөзэләрдән мәркәб булганлыгын телдән сөйләп аңлатуны һичбер төрле күчергечкә алыштырылмый. Хәрефне язып күрсәткәндә, балалар кулның нә рәвештә хәрәкәт иткәнлеген дә белеп калырга тиешле. Бәгъзы мөхәррирләрнең фикеренчә, алдан язып куелган хәрефләр өстеннән сызып йөртү ысулының бары бер генә төрле хасияте бар, имеш: ул да педагогия гыйлеменнән хәбәре булмаган тәҗрибәсез мөгаллимнәр өчендер. Мөгаллим тарафыннан артык иҗтиһад сарыф ителмәенчә, көчләнмичә, дәхи язу дәресләренә күп вакыт та сарыф ителмәенчә, балаларны шул дәфтәрдә язылып куелган хәрефләр буенча гына бер дәрәҗә язуга үгрәтү мөмкин була, диләр.*

*3) Балаларны тиз вакытта укырга үгрәтү өчен иске ысулларны йиңеләйтүгә төрле чаралар эзләп, ахырда ысулы сәүтия чыгарылган кеби язуга үгрәтү өчен дә, иске тәртипләр урынына бер йиңелрәк ысул табылган. Хәзер дә Европа мәктәпләрендә язуны гомума шул ысул берлә үгрәтелә. Хәрефләрнең үлчәвен вә язылу рәвешләрен ачыграк аңлату өчен, дәхи, балаларның зәвыкларын вә һәвәсләрен арттыру нияте илә бәгъзы бер педагоглар тарафыннан күрсәтелгән җөзэи аермалар гына бар, әмма ысулы һаман да шул бер,*

*тәртибе шул рәвештә: хәрефләрене искечә хәреф-һәҗҗа тәртибендә үгрәтелми, бәлки язылу рәвешләрендә бер-берсенә охшавына карап, берничә кыйсемгә бүленә. Беренче кыйсемгә иң ансат рәвештә языла торган хәрефләр куелып, аннан соң читенрәкләре дә язылып бара. Һәр кыйсемдә әүвәл хәрефләрнең җөзэләре язылып, аннан соң шул җөзэләрдән мәркәб булган хәрефләр, ракыймнәр вә аерым сүзләр илә җөмләләр дә языла. Хәрефләр илә җөзэләрнең үлчәвен вә язылу рәвешләрен ачыграк күрсәтү өчен әүвәл дәрәҗә махсус сызыклар вә алардан ясалган мәрбиглар истигъмаль ителә, ләкин боны артык озакка сузмаенча, хәрефләрне бер мәртәбә язып чыгу илә кифая ителер, аннан соң ике сызыклы, ахырда бер сызыклы дәфтәрләргә языладыр. Әүвәл мәртәбә эре хоруфат илә язылган, аннан соң вак язуга әйләндерелә. Язу рәвешләрендә балаларның рухларын күтәреп, һушларын арттыру өчен, бәгъзы вакыт хәрефләрне телдән әйтеп яки махсус ишарәләр белән бөтен сыйныфка берьюлы яздырыла, ягъни хәреф ничә җөзэдән мәркәб булса, балалар шул җөзэләрне (мөгаллимнең ишарәте берлән) берьюлы сызарга тиешле. Бу тарикъ белән үгрәткәндә балалар тиз язарга гадәтләнәләр һәм бөтен сыйныфның язуы бер сурәттә була, әмма бу рәвешле дәресләр мөмкин кадәр кыскарак вә сирәгрәк булырга тиешле, артыкка китсә, файда урынына зарар булу ихтималы да бар.*

*Хөсне хат дәресләреннән максуд – балаларны яхшы язуга үгрәтүдер.*

*«Яхшы язу» дигән нәрсәдә өч төрле сыйфат барлыгы аңлана:*

*1) интизам, ягъни сызылу рәвешләренең дөреслеге;*

*2) ачык вә танырлык булу;*

*3) гүзәл вә нәфислек.*

*Бу сыйфатларның берничәсе – һәрбер аерым хәрефне дөрес рәвештә вә башкалар илә бер үлчәүдә язып, алардан сүзләр тәшкил итү вә ул сүзләрнең язу сәтырларында мөнасиб үлчәү үзрә төәелүеннән килә. Язуның ачыклыгы – һәрбер хәрефнең вә һәрбер сүзнең күзгә аерым ачык рәвештә күренүеннән вә гадәтенчә генә укый-яза белә торган адәмнәргә дә мәшәкатьсез танырлык булуыннан гыйбарәттер. Әлбәттә, ачыклык вә дөреслек бер-берсенә башка, ягъни икесе бер түгел: бәгъзы адәмнәрнең бик дөрес язуларын да тиз генә танырлык булмый, ашыгыч язуда хәрефләр бер-берсен кушылып, дөрес язылса да, танырга читен була, язуның гүзәллеге, дөреслеге белән ачыклыгында һәм төрле сызыклар арттырып хәрефләрне ма-*

*турлавыннан килә. Бу рәвешле арттырылган сызыкларның дөрес вә ачыклык өчен һич хаҗәте юк.*

*Язуның нәфислеген ачык рәвештә тәгъриф кылу, әлбәттә, ансат түгел, әмма аны бик тиз сизеп була. Нәфис язу адәмнең хисенә хуш тәэсир итү рәхәтлек китерә, шулай булса да, артык гүзәл вә нәфис язуның гавам мәктәбе өчен лязүме юк, диләр.*

*Вакытның азлыгы вә хөсне хат мәгыйшәт өчен нә дәрәҗә кирәклеген хәтердә тотып, яхшы язуның әүвәлге ике сыйфатына артыграк илтифат итәргә тиешле була, ягъни балаларның язулары дөрес рәвештә ачык вә һәркем таныpлык булсын. Дәхи, мөмкин кадәр тиз язарга үгрәтүне арзу итеlә, ләкин гавам мәктәпләрендә вак хәреф илә тиз язуга угрәнү мөмкин түгел, ул күп еллар язу белән шөгыльләнгәндә генә була торган эш. Шул сәбәпле тиз язу сыйфаты бик азы белән дә канәгатьләнергә туры килә. Мәктәп тәмам иткән бала уртача хорафат илә гадәтчә (ягъни урта гына) тизлектә яза алса, кафидер.*

*Гавам мәктәпләрендә вакытның тарлыгыннан, хөсне хат бабында артык зур нәтиҗә чыгарып булмый. Шул сәбәпле мөгаллим әүвәлдән үк туп-тугры максудка илтә торган йиңел ысулга тотынырга тиешледер.*

*Хөсне хат тәгълименә керешүдән мөкаддәм, балаларны нә кыяфәтендә утырырга, нә рәвештә каләм вә кагазь тотарга үгрәтү тиешле була, чөнки бу шартлар табылмаганда, ачык вә гүзәл язуга ирешү мөмкин булмыйдыр. Язу дәресләрендә мөхаләф кәгазь үзрә утыру, хафиз сөхать җәһәтеннән дә зарарлы санала, мәктәп балаларында күрелгән арка, күкрәк, күз авырулары күбесенчә шул сәбәпләрдән була, имеш».*

*Белемне тикшерү өчен биремнәр:*

1. Хөсне хат нәрсә ул?

2. Югарыда бирелгән текстлардан хәзерге көндә аңлашылмый торган сүзләрне җыеп, аларга, сүзлектән карап, аңлатмалар эшләгез.

Әдәбият:

*1. Программа спецкурса "Каллиграфия" / Казан. гос. ун-т, Ин-т востоковедения; [сост. Д.А. Шарафутдинов; науч. ред. А.Б. Халидов].–Казань : [б. и.], 2001.–11 с.*

*2. Проненко Л.И. Каллиграфия для всех /Л.И. Проненко. – М.: Книга, 1990. – 248 с.*

*3. Сабиров А.Р. Арабская каллиграфия /А.Р. Сабиров. – Казань : Иман, 2006. – 32 с.*

## Текст белән эшләү кагыйдәләре

Һәр мәдәни милләт үзенең язма һәм тарихи мирасын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалауны кайгырта. Бу эш белән филологиянең, әдәбият гыйлеменең бер тармагын тәшкил итүче фән – текстология шөгыльләнә.

Текстология (лат. textus – тукыма (нигез) һәм -логия) – язма һәм басма әдәбият, фольклор әсәрләре текстларын тәнкыйди тикшерү, ачыклау, чыганакларын, тарихын өйрәнеп басмага әзерләү белән шөгыльләнә торган фән. Мәгълүм булганча, анықланган ышанычлы текстларга нигезләнмичә, әсәрне идея-художество һ.б. яклардан өйрәнү, әсәргә яисә язучы, галим, автор иҗатына идея-эстетик анализ ясап булмый.

Төрле вакытта иҗат ителгән әсәрләргә, ягъни тикшерү объектына карап, текстология антик дәвер, урта гасырлар (яисә медиевистик текстология) һәм яңа әдәбият тармакларына бүленә.

Төрки-татар текстологиясен түбәндәге төрләргә бүлү кабул ителгән:

1) татар әдәбиятының борынгы һәм урта гасырлар кульязма ядкәрләре текстологиясе;

2) яңа әдәбият текстологиясе (XVIII йөз ахырыннан басма татар китабы);

3) халык авыз иҗаты әсәрләре текстологиясе.

Татар әдәбияты текстологиясе үзенең тамырлары белән түбәндәге ике традициягә барып тоташа:

– ислам фәненә караган, фәлсәфи, филологик эчтәлекле китапларга Шәрыктәгечә аңлатма бирү традициясе;

– урта гасырлардагы гомумтөрки филологик ядкәрләр.

Текстологиянең төп ысулы – текстка филологик анализ ясау. Шулай ук ихтималлык-статистик, фотомеханик ысуллар да кулланыла.

Һәрбер дәвердә әдәби әсәрләрнең һәм тарихи хезмәтләрнең барлыкка килүендә үзләренә генә хас ысуллар (методлар), үзен-

чәлекләр бар. Әйтик, борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты яисә фольклор әсәрләре кулдан күчерелеп, телдән-телгә сөйләнеп таралганнар һәм шуңа күрә аларга төрле үзгәрешләр кергән, вариантлары барлыкка килгән. Текстолог төрле вариантларны үзара чагыштырып, иң борынгы һәм ышанычлы күчермәне нигезгә алып, тәнкыйди текстлар эшләү белән шөгыльләнә, ягъни ул әсәрләрне басмага әзерли.

Урта гасырларда иҗат ителгән күп кенә әсәрләрнең, тарихи хезмәтләрнең кем тарафыннан язылуы мәгълүм түгел. Текстолог шулай итеп теге яки бу әсәрнең авторын ачыклау, тәгаенләү (атрибутика), әсәрнең язылу урынын һәм вакытын ачыклау, әгәр дә әсәр басылып чыккан булса, басмаларын ачыклау (исәпкә алу) белән дә шөгыльләнә.

Язучының, авторның иҗат процессын аңлау, иҗат психологиясен төшенү өчен, иҗтимагый һәм әдәби-эстетик карашлары эволюциясен аңлау өчен аның кулъязмаларының тарихын, икенче төрле әйткәндә, «текст тарихын» өйрәнү зарури. Беренчедән, язучы үз әсәрен кат-кат эшкәртә, камилләштерә. Икенчедән, әсәрнең басмаларында цензура һәм мөхәррирләр тарафыннан төрле үзгәрешләр кертелергә мөмкин. Өченчедән, әсәр басылганда, төрле хаталар китәргә, кайбер җөмләләр, хәтта әсәрнең кайбер кисәкләре төшеп калырга мөмкин. Шуңа күрә әдипнең иҗат процессын тулырак күз алдына китерү өчен аның кулъязмаларын, үзе карап төзәтеп чыккан корректураларын өйрәнергә кирәк. Әсәрнең нәшрият, цензура архивында сакланган нөсхәләрен тәнкыйди тикшерергә һәм баскан вакытта җибәрелгән хаталарны ачыклау зарури. Менә шушы таләпләрне үтәү, әсәрнең автор үзе язган вариантын тулысынча басарга әзерләү текстолог-галимнең төп бурычы булып тора. Шушы эшләр эшләнми торып, ягъни язучының, гомумән, теге яки бу авторның җентекләп тикшерелеп дөньяга чыгарылган хезмәтләре булмый торып, аның иҗаты, әдәби-эстетик, иҗтимагый-сәяси карашлары турында фикер йөртү, аңа бәя бирү берьяклы гына булачак.

## Әдәбият чыганаклары һәм текстология

Әдәбият чыганаклары белеме яңа оешып килгән фән тармакларыннан санала. Шуңа да бу өлкәдәге хәл ителмәгән мәсьәләләрнең күп булуы аңлашыла. Фән белән бергә аның терминнары да барлыкка килә, төп эчтәлеге, мәсьәләләре, юнәлешләре ачыклана. Яңа оешып килүче фән тармагы булу сәбәпле, аның әдәбият фәнендәге урыны да ныклап ачыкланып җитмәвен танырга кирәк. Әдәбият теориясенә караган хәзерге дәреслекләргә мөрәҗәгать иткәндә дә, чыганаклар белән эш итүче фән тармакларына түбәнсетеп карау ачык күзгә ташлана. Мәсәлән, «Әдәбият теориясенә кереш» (1987) китабында әдәбият белеме төп өч мөстәкыйль тармакка бүленгән итеп күрсәтелә (әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть). «Болардан тыш, – диелә анда, – әдәбият белеме кайбер бүтән ярдәмчел тармакларны да эченә ала» һәм мисал итеп текстология һәм библиография өлкәләре китерелә. Мондый караш – фән тармакларын мөстәкыйль һәм мөстәкыйль булмаганнарга, «төп» һәм «ярдәмчел», ягъни икенчел дәрәҗәдәгеләргә аеру русча чыккан хезмәтләрдә дә, төрки телләрдә басылган әдәбият теориясе дәреслекләрендә дә очрый. Әдәбият чыганаклары белеменең фән тармагы буларак мөстәкыйльлеген танымаган мондый бүленешнең хәзерге югары уку йортлары программаларында һәм дәреслекләрендә урын алуы галимнәребезнең һаман да иске кысалардан арына алмавын искәртә.

Әдәбият чыганаклары белеме әдәбият фәненең мөстәкыйль бер тармагы булып саналырга хаклы – әдәбият фәненең үсеш юлы, төрле ил галимнәренең шушы өлкәдәге эшчәнлекләре әлеге фикергә этәрә.

Әдәбият теориясе дәреслекләрендә әдәбият чыганаклары белән эш итүче өлкәне рус әдәбиятчылары «вспомогательная научная дисциплина» дип атыйлар. Татарча аны «ярдәмчел фән тармагы» дип тәрҗемә иткәннәр. Аны «булышучы фән тармагы» дип алу мәгънәгә төгәлрәк туры килә кебек. Әмма мәсьәлә терминда гына түгел, ә аның урынын бәяләүдә. Галимнәр, мәсәлән, чыганаклар белеменең үзәген тәшкил иткән текстология кебек фән тармагын төп тармакларга «булышучы» итеп кенә санау белән килешмиләр, мондый карашны аның әһәмиятен, ролен түбәнсетеп карау дип атыйлар. Цюрих университеты профессоры Макс Верли, мәсәлән, текстологияне әдәбият белеменең нигезендә яткан бер мөстәкыйль тармагы итеп карый. Б. Томашевский, Д. Лихачев кебек рус галимнәре дә, тексто-

логияне текстны китап итеп басуга әзерләү мәгънәсендә тар, механистик аңлауны тәнкыйтьләп, аны текст тарихын фәнни өйрәнүгә нигезләгән мөстәкыйль фән тармагы буларак киң итеп аңлауны алга сөрделәр.

Татар галимнәре, мәсәлән, күренекле әдәбият белгече Н.Г. Юзиев та (1931–1996) текстологиянең мөстәкыйльлеген яклый. Әмма бер җитди өстәмә дә бар. Әдәбият чыганаклары белеме өлкәсен текстология белән генә чикләнмичә, аңа чыганаклар белән эш итүче башка фән тармакларын да өстәргә кирәк. Әдәбият чыганаклары белеменең Н.Г. Юзиев тарафыннан тәкъдим ителгән структурасы түбәндәге фән тармакларын үзенә берләштерә:

1. Текстология;
2. Археографиянең әдәбият белән бәйле тармагы;
3. Архив фәненең әдәбият чыганаклары, язучы архивлары белән бәйле тармагы;
4. Музей фәненең әдәбиятка бәйле тармагы;
5. Библиография һәм китап белеменең әдәбиятка бәйле тармагы;
6. Хронология;
7. Палеографиянең әдәбият чыганаклары белән бәйле тармагы.

«Әдәбият чыганаклары белеме» – әдәбият чыганаклары белән эш итүгә бәйле күп кенә төрле фән тармакларын комплекслы берләштергән, әнә шул өлкәләрдәге профессиональ серләрнең әдәбиятчыга кирәкле гыйлемен туплаган, әдәбият фәненең мөстәкыйль бер тармагы буларак яшәргә хаклы өлкәсе ул.

«Чыганаклар», «әдәбият чыганаклары» дигән атамалар безнең фәнни хезмәтләрдә очрамый түгел, очрый. Практик кулланышта алар нигездә әдәбиятны укучыга һәм тикшерүче галимгә әдәбият итеп күз алдына бастырырга ярдәм итүче чыганакларны – әдәби һәм фәнни кулланмаларны-әсәрләрне аңлаталар. Күбесенчә «әдәбият чыганаклары» дигәннән тәмамланган һәм басылып чыккан әдәби әсәрләр күздә тотыла. «Әдәбият чыганаклары белеме» дигән төшенчәнең контекстта, фәнни кулланышта мәгънә төсмере үзгәрәк. «Әдәбият чыганаклары» термины тәмамланган һәм басылып чыккан әсәрләрдән тыш төрле сәбәпләр аркасында басылмый калганнарын да, кульязма хәлендә сакланганнарын да, тәмамлана алмаганнарын да, әсәрнең төрле вариантларын да, әдипнең әсәр язу барышында тупланган материалларын да, көндәлекләрен дә, куен дәфтәрләрен дә, истәлекләрен дә, фоторәсемнәрен, магнитофонга язылган сүзләрен дә,

язышкан хатларын да үз эченә ала. Бу чыганакларны галимнәр төрлечә төркемлиләр. Иң олы бүленеш – аларны әдәби һәм фәнни чыганаклар дип аеру. Һәрбер төркем тагын үз эчендә эчтәлекләренә, хасиятләренә, функцияләренә карап төрле төркемнәргә бүленә. Әйтик, беренчел чыганаклар, икенчел чыганаклар – болары чыганакларның басылу-басылмауларына карап төркемләнә. Архив чыганаклары, китапханә чыганаклары, музей чыганаклары – бу бүленеш аларның саклану урыннарына, куллану функцияләренә ишарәли. «Әдәбият чыганаклары белеме» атамасы чыганакларның әнә шундый фәнни кулланышка бәйле төрле өлкәләрдә тупланган гыйлемнәрне күздә тота. Яңгырашы сәер тоелуы да ихтимал. Моңа аның өч сүздән торуы да (терминнар бит гадәттә бер-ике сүздән генә оешалар), татар әдәбиятына караган фәнни хезмәтләрдә очрамавы да тәэсир ясый торгандыр. Әдәбият теориясенә багышланган хезмәтләрдә, «Әдәбият теориясенә кереш» (1987) китабында да, «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә дә (1990) әлегә ул термин буларак очрамый.

«Әдәбият чыганаклары белеме» терминының моңарчы кулланмавы ул аңлаткан күренешнең татар әдәбияты фәнендә булмавы турында сөйләми, әлбәттә. Бу мәсьәләгә бездә игътибар җитеп бетмәвен генә аңлата. Гомуми әдәбият белемендә мондый төшенчә күптән кабул ителгән.

Чыганаклар белән эш итү тәҗрибәсе әдәбият фәне белән бергә барлыкка килә, әмма аннары аның үсешенә төрлечә – йә бик көчле, йә сизелмәслек йомшак тәэсир ясый. Моның өчен андагы тәҗрибәләрнең гомумиләштерелүе гаять зур роль уйный. Әйтик, «текстология» атамасы үтә яңа термин – 1928 елда гына кулланыла башлый. Ә аның төшенчәсе, якынча мәгънәсе бик борынгы заманнарга барып тоташа. Коръән, Инҗилләр барлыкка килү белән, аларның текстын өйрәнүгә бәйле белемнәр – фән тармаклары барлыкка килә (шәрехләү, герменевтика, экзегетика). Чыганаклар белеме өлкәсе белән дә шул ук хәл. Әдәбият фәненең бер тармагы буларак ул бездә яңа оешып килә, әмма бу өлкәдәге тәҗрибә, гыйлем татар әдәбият фәне туу белән барлыкка килә. Әдәбият фәне XIX гасырда һәм XX гасыр башында күзгә күренерлек уңышларга ирешә, дибез икән, монда, иң беренче чиратта, Г. Утыз-Имәни (1754–1834), Ибраһим Хәлфин (1779–1829), Ш. Мәрҗани (1818–1889), Р. Фәхретдин (1859–1936) кебек галимнәребезнең әдәбият һәм мәдәният чыганаклары белән эш итүдәге олы казанышларын, шул тармактагы титаник эшчәнлекл-

рен күздә тотабыз. И. Хәлфин, Г. Утыз-Имәнинең текстология һәм шәрехләү эшчәнлеген, Ш. Мәрҗанинең алты томнан торган «Вафиат ел әл-әслаф» энциклопедик сүзлеген, Р.Фәхретдиневнең «Асар» томнарын, энциклопедик, текстологик, шәрехләү эшчәнлеген искә төшерү дә бу өлкәдә кыйммәтле бай тәҗрибәләрнең электән үк туплана килүе турында сөйли. Бу традицияләр XX гасыр дәвамында да күпмедер дәрәҗәдә үстерелә, баетыла.

Хәзерге практик тормыш та «әдәбият чыганаклары белеме» төшенчәсенең кирәклеген, хәтта зарурилыгын һаман саен искәртеп тора. Шушы зарурият нигезендә хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 1986 елны кулъязмалар һәм текстология бүлеге оештырылды. Бүлекнең шушы вакыт эчендәге татар халкының рухи мирасын җыйнау буенча алып барган эшчәнлеге аның бик тә вакытлы барлыкка килүен раслады. Ул кыска вакыт эчендә әдәби мирасны туплау, барлау, фәнни эшкәртү, аны халыкның үзенә кайтарып бирү юнәлешендә зур эшләр башкарды. Чыганаклар өлкәсенә игътибарның көчәюен Казан университеты мисалында да расларга мөмкин (Х. Госман (1908–1992), М. Госманов (1934–2010), А. Фәтхи (1937–1992).

Әдәбият чыганаклары белеменә игътибарның көчәюе һәм аның әдәбият фәнендә абруе үсүе ул татар әдәбият фәненең генә хосусый үзенчәлеге түгел. Элекке совет республикаларының байтагында Кулъязмалар институтының ачылуы яки А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбиятларын өйрәнү институтында (Мәскәүдә) «литературное источниковедение» бүлегенең оештырылуы, Фәннәр академиясе системасында әдәбият чыганаклары белеменең дә приоритетка ия юнәлеш буларак танылуы – шушы тенденцияне характерлаучы мисаллар. Болар барысы да иҗтимагый-сәяси хәлләр нәтиҗәсендә озак еллар кыерсытылып яшәргә мәҗбүр ителгән фән тармагының, ниһаять, фән дөньясында лаеклы үз урынын яуларга тырышуы турында сөйли.

Яңа оешып килүче фән тармагы буларак әдәбият чыганаклары белеменең хәл ителәсе мәсьәләләре дә байтак. Шундыйлардан Н.Г. Юзиев түбәндәгеләрне билгели:

1. Бу фән тармагының терминнарын ачыклау, атамаларын билгеле бер тәртипкә китерү – актуаль бурычларның берсе. Һәр фән өлкәсе чыганаклар белән эш итә. Әмма һәр өлкәдә ул чыганакларның роле, урыны тигез түгел. Шуңа да төрле атамалар кулланыла. Аларның төрлелеге

аңлашыла. Шулай да иҗтимагый фәннәрдә атамаларның уртак кулланылышы, ягъни унификацияләнүе турында уйлануны дәвам итү кирәктер. Бу аеруча әдәбиятчылар белән телчеләрнең, тарихчыларның бергәләшеп эшләвен сорый. Әйтик, галимнәр «текстология», «археография» атамаларының тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарафыннан термин буларак үзгәрәк мәгънә белән кулланылуын әйтәләр. Килешенеп бетмәгән кулланышлар башка терминнарда да очрый.

2. Терминнарның уртаклыгына ирешү фәннәрнең төрле өлкәләрендә (тел, тарих, әдәбият) эшләүчеләр өчен генә түгел, төрле телләрдә иҗат итүче әдәбият галимнәре өчен дә әһәмиятле. Төрки телләрдә чыккан кайбер әдәбият сүзлекләренә мөрәҗәгать иткәндә, әдәбият чыганаклары белеме өлкәсенә караган атамаларның тик русчадан алынуы күзгә ташлана. Бу өлкәдә дә яңа атамалар табарга һәм уртак төрки терминнарга күчәргә омтылырга кирәктер.

3. Әдәбият чыганаклары белеменең эчтәлеген, чикләрен, төп тармакларын да ачыклау зарури. Хәзерге бүленештә төрлелек хөкем сөрә. Әйтик, бер иш галимнәрдә текстология әдәбият чыганаклары белеменең бер тармагы буларак хисаплана, башкалары исә аны бу өлкәдән читтәге – үзенә бер мөстәкыйль тармак итеп саный.

4. Әдәбият чыганаклары белеме – практик як белән теоретик якны берләштерүе белән үзенчәлекле фән тармагы. Архив, китапханә, музей, нәшрият (практик текстология) белән турыдан-туры бәйле булуы шуны ачык дәлилли. Шуңа таянып, нигезләнеп, әдәбият чыганаклары белеменең теоретик әһәмиятен киметергә омтылыш тенденциясенең хәзергәчә яшәп килүен дә онытырга ярамый. Бу өлкәдә эшләүче белгечләр мондый тенденция белән даими очрашып торалар. Чыганаклар белеменең әһәмиятен күтәрергә телибез икән – ул бу өлкәдәге хезмәтләрне дөньяга чыгару белән дә бәйле икәнен һәрчак истә тотарга тиешбез.

5. Әдәбият чыганаклары белеменең практика белән бәйле бер тармагы ул – әдәби мирасны, язма ядкәрләрне саклауның торышы. Бу өлкәдә, киресенчә, практик якның аксавы нык сизелә һәм күңелдә борчу уята. Бу өлкәдәге фаҗигале күренешләр турында күп язылды, мәдәният һәм әдәбият ядкәрләрен саклау турында закон да кабул ителде. Әмма аның практик үтәлеше теоретик куелышта нык калыша. Бу бигрәк тә мирасханәләрнең материаль-техник коралланышның ифрат та түбән дәрәҗәдә булуына бәйле. Күчермәләр аша язма ядкәрләрнең гомерләрен озынайта торган техник чаралар (микро-

фиш, микрофильм, ксерокс һ.б) кулланылмый. Ә әдипләребезнең кулъязмалары мәңгелек түгел – искерә, туза һәм танып була алмастай хәлгә килә. Бу күренеш белән галимнәр М. Гафури (1880–1934), Ф. Әмирхан (1886–1926), Һ. Такташ (1901–1934) әсәрләре җыелмасын хәзерләгәндә еш очрашалар – аерым битләр укый алмаслык дәрәҗәдә таушалганнары күренә. Чит илләрдә саклаучы язма истәлекләрнең күчермәләрен туплауга да ныклап керешергә кирәк.

6. Әдәбият чыганакларын җыйнау, фәнни өйрәнү мәсьәләләрендә төрки әдәбиятлары белгечләренең үзара бәйләнешләренең җитәрлек булмавын да әйтергә кирәк. Хәл ителәсе уртак мәсьәләләр бу өлкәдә дә тулып ята.

7. Язма ядкәрләрне җыйнау, саклау, фәнни эшкәртү буенча Татарстанда гыйльми үзәкнең булмавы үзен нык сиздерә. Үз мәдәниятләренә хөрмәт белән караган дәүләтләрдә һәм халыкларда мондый үзәкләр күптән эшләп килә. Әрмәнстанда, Грузиядә, Үзбәкстанда, Азәрбайҗанда бу эш белән махсус институтлар шөгыльләнә. Татарстанда да шундый институтны – Кулъязмалар институтын – академия системасында булдыру көн тәртибенә баса.

*Биремнәр:*

1. Текстология, аның бурычлары.
2. Текст белән эшләү кагыйдәләре.

Әдәбият:

*1. Әдәби мирас һәм текстология: Мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 164 б.*

*2. Лихачев Д.С. Текстология. На материале русской литературы X–XVII веков. Изд. 2–е /Д.С. Лихачев. – Л. Наука, 1983. – 639 с.*

*3. Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты (авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре) /З. Рәмиев. – Казан: РИЦ «Школа», 2000. – 180 б.*

*4. Хәкимҗанов Ф.С., Шәкүрова М.М. Хәзерге татар теле: Пунктуация / Ф.С. Хәкимҗанов, М.М. Шәкүрова. – Казан : Gitapitarya, 2003. – 388 б.*

*5. Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века /З.З. Рамеев. – Казань : Алма–Лит, 2008. – 188 с.*

*6. Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (урта гасырлар – XX йөз башы). – Казан, 2006. – 192 б.*

7. *Юзиев Н. Әдәбият хәзинәләре / Н. Юзиев. – Казан, 1978. – 192 б.*
8. *Юзиев Н. Әдәбият чыганаклары белеме (әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре) / Н. Юзиев. – Казан : Фикер, 1998. – 175 б.*

## Тыныш билгеләре

Узган гасырның 20 нче елларына кадәр гарәби хәрефләргә нигезләнгән татар язмачылыгының орфография-пунктуация кагыйдәләре тиешле дәрәҗәдә эшләнмәве, текстларны транскрипцияләгәндә, өстәмә кыенлыклар тудыра. XIX йөзнең 70 нче елларына кадәр татар текстларында тыныш билгеләре бик тә саран кулланылган. Тыныш билгесе функциясен җөмлә азагында куелган нокта яисә ромашка рәвешендәге чәчәк уйнап килгән. Кайбер очракларда, аеруча мөһим сүзләрне ассызыклаганда, аның өске ягына гадәттә кызыл кара белән сызык сызганнар. Татарда тыныш билгеләре хакында беренчеләрдән булып Муса Акъегетзадә «Хисаметдин менла» (1886) әсәрендә язып чыга. Шулай ук Г.Госманов, Ф.Садыйков, К.Насыйрилар да бу өлкәдә мәгълүм эш башкаралар. Әмма узган гасырның 20 нче елларына кадәр пунктуация кагыйдәләре тиешле дәрәҗәдә эшләнмәгәнлектән ,хәзергә кадәр кайбер гарәби хәрефле әсәрләрне, хезмәтләрне транскрипцияләгәндә, йөрәкне тырнап торган хата-ялгышлар күзәтелә.

Мисалга ерак бармыйча ике классик шагыйребез – Дәрдемәнд һәм Г.Тукай әсәрләрен алыйк. «Вакыт» газетасының 1906 елгы 18 апрель санында Дәрдемәнднең «Кыйтга» дип аталган дүртьюллыгы дөнья күрә һәм ул 1980 елда әдипнең «Исә җилләр» исемле җыентыгында түбәндәгечә транскрипцияләнгән ( 27 б.)

***Кыйтга***
*Ятимнәр күңелене кырдың, җимердең,*
*Көчең җитсә – бу зиндан ишеген ват!*
*Туган, алдауда мин синнән калышмам,*
*Күрим сине – йә, бу солдатны алдат.*

Шигырьнең беренче ике юлы аңлашыла: ул шагыйрьнең төрмәдә утырган танышына адресланган. Әмма өченче-дүртенче юллары аңлашылып бетми. Өченче юл «туган, алдауда мин синнән калыш-

мам», рәвешендә бирелгән. Шигырьнең беренче басмасында Вакыт. – 1906. – 18 апрель) «туган» сүзеннән соң өтер куелмаган. Хәер, әйткәнебезчә ул вакытта әле пунктуация нормалары эшләнеп җитмәгән була. Дәрдемәнднең 1928 елгы басмасында өтер куелмаган, ә 1959 елгы басмада өтер куелган. Димәк, өтер куелган очракта, шагыйрь төрмәдәге җинаятьчегә «туган» дип эндәшә булып чыга. Бу, әлбәттә, сәер хәл. Әлеге шигъри юл мәгънәсе «үз туганыңны алдауда» булырга тиеш.

Мәгълүм ки, татар телендә шундый кыскартылган килеш формасы бар: Казан йөрү, базар йөрү (Казанга, базарга түгел); суган сату, бәрәңге алу (суганны сату, бәрәңгене алу түгел).

Шигырьдәге «алдат» сүзе дә аңлатуны таләп итә. Дәрдемәнд җинаятьчене төрмә сакчысын алдатырга өнди килеп чыга. Бу ситуациядә «алдату» һич тә җинаятьчегә ирек бирмәячәк. Язучы һәм галим М.Мәһдиев (1930–1995) фикеренчә, шагыйрь болай дип әйтә: син ятимнәрне каһәрләдең, таладың. Аларны каһәрләргә, алдарга зур осталык кирәкми. Туганымны алдарга мин дә булдыра алам. Ә менә син хәзер үзеңне саклаучы солдатны (алдат түгел!) «ал да ат». Шигырь ритмикасы таләбенчә бу сүз кушылып укыла һәм янәшә килгән ике сузык (а–а) кушыла һәм бер иҗеккә кала. Күрик әле, ди шагыйрь, алай бик оста булсаң, бу солдатны урыныннан алып атып ташла әле. Моңа охшаш хәлләр, ягъни янәшә килгән ике сузыкның кушылу күренеше халык җырларында да күзәтелә. Ә хәзер исә Г.Тукайның мәшһүр «Китмибез!» исемле шигыренә мөрәҗәгать итик. Бу шигырьне кириллицада бастырганда пунктуация мәсьәләсенә саксыз килү аркасында шагыйрьнең әйтергә теләгән фикере тупас бозылу хакында шагыйрь Зиннур Мансуров бик тәфсилле язып чыкты (Мәдәни җомга. – 2012. – 18, 25 ноябрь). Әлеге атаклы шигырьнең ахыргы өлешендә шундый декларатив белдермә бар:

*Иң бөек максат безем:*
*Хөр мәмләкәт, хөр Русия!*

Шигырьнең ахыргы өлеше менә шушы рәвештә нәшер ителгәндә барысы да үз урынында булыр иде, ягъни шагыйрь үз туган халкын да дәүләтчел милләт итеп күрергә һәм Русия дә хөр (демократик) дәүләт булуын тели. Икенче төрле әйткәндә, Тукай ике халыкның да мөстәкыйль (үзбаш) рәвештә милли тигезлек шартларында яшәргә тиешлеген искәртә. Әмма шагыйрьнең 1955–1956 елларда дөнья күргән дүрттомлыклардан аермалы буларак, соңрак чыккан басмала-

рында «хөр мәмләкәт» белән «хөр Русия» арасындагы өтер сызыкка алыштырылган. Бу очракта шагыйрьнең фикере тупас бозыла: Тукай бары тик Русиянең генә азат ил-дәүләт буларак яшәвен тели килеп чыга.

«Лингвистик күзлектән караганда да «Иң бөек максат безем» кебек төп бүлектән соң ике нокта торган очракта санау бүлегендәге тиңдәш кисәкләр арасында өтер кую тел белеме тәртибенә ярашлырак була», – дип билгеләп уза З. Мансуров. Кыскасы, әнә шул өтернең куелмавы шигырь рухын бозып аңлата һәм «элек дәүләт тоткан халыкның иң бөек максатын» дөрес куелмаган тыныш билгеләре астында күмеп калдыра.

Хәзерге кагыйдәләр буенча элеккеге текстларны транскрипцияләп күчереп бастырганда, тыныш билгеләре гамәлдәге пунктуация кагыйдәләре нигезендә куела һәм текстолог-төзүче бу хакта махсус искәрмә ясарга тиеш.

*Бирем:*

1. Гарәби язмалы XX йөз башы текстларында тыныш билгеләре мәсьәләсе.
2. Гарәби язмалы текстларны транскрипцияләү кагыйдәләре.

Әдәбият:

1. *Әдәби мирас һәм текстология : Мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 164 б.*

*2. Госманов М. Каурый каләм эзеннән : Археограф язмалары. Тулыландырылган икенче басма / М. Госманов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1994. – 463 б.*

*3. Госманов М.Г. Иске татар язуы нигезләре: Студентлар өчен методик кулланма-таблицалар. 1 кисәк / М. Госманов – Казан: Казан ун–ты нәшр., 1983. – 34 б.*

*4. Курбатов Х.Р. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы /Х.Р. Курбатов. – Казан: Татар, кит. нәшр., 1960. – 130 б.*

*5. Лихачев Д.С. Текстология. На материале русской литературы X–XVII веков. Изд. 2-е / Д.С. Лихачев. – Л. Наука, 1983. – 639 с.*

*6. Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века /З.З. Рамеев. – Казань : Алма–Лит, 2008. – 188 б.*

*7. Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты (авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре) /З. Рәмиев. – Казан : РИЦ «Школа», 2000. – 180 б.*

*8. Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (урта гасырлар – XX йөз башы). – Казан, 2006. – 192 б.*

*9. Хәкимҗанов Ф.С. Хәзерге татар теле : Пунктуация / Ф.С. Хәкимҗанов, М.М. Шәкүрова. – Казан : Gumanitarya, 2003. – 388 б.*

*10. Юзиев Н. Әдәбият хәзинәләре. – Казан, 1978. – 192 б.*

*11. Юзиев Н. Әдәбият чыганаклары белеме (әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре) / Н. Юзеев). – Казан : Фикер, 1998. – 175 б.*

## Транскрипция

Текстологиядә транскрипция төп мәсьәләләрнең берсе булып тора. Татар текстологларының күпчелеге гарәби хәрефле текстларны басмага әзерләү белән шөгыльләнә. Чөнки мең елдан артык вакыт эчендә иҗат ителгән язма мирасыбыз гарәп графикасы ярдәмендә теркәлеп калган.

Бер графикада язылган текстларны икенче графикага күчергәндә, ике төрле ысул белән эш итәләр:

– Транскрипция;

– Транслитерация.

Транскрипция – transcription – латин термины, «күчереп язу» дигән мәгънәгә туры килә. Транскрипция нинди дә булса берәр тел яки диалект авазларын, бу телнең язу системасыннан үзгәрәк булган хәрефләр, шартлы билгеләр белән бирү, шундый билгеләр системасы.

Транскрипцияне транслитерация белән бутамаска кирәк. Транслитерация – бер язу системасы хәрефләрен икенче язу системасы хәрефләре белән алыштырып язу. Транслитерация «асылда» бик борынгы текстларны икенче графикага күчергәндә кулланыла.

Транскрипция ике төрле була:

– Фәнни;

– Практик.

Фәнни транскрипция лингвистик тикшеренүләрдә кулланыла һәм ике типка бүленә:

– Фонетик;

– Фонематик.

Фонетик транскрипция сүзнең авазлар составын, басым урыннары һәм позицион вариантларны төгәл бирүне күздә тота.

Фонематик транскрипция сүзнең фонемалар составын позицион вариантларын искә алмыйча чагылдыруны алга сөрә.

Фонетик транскрипция телара сүзлекләрдә кулланыла, ул, кагыйдә буларак, квадрат җәяләр эчендә бирелә, ә фонематик транскрипция үрнәкләре кыек яки сынык җәяләр эченә урнаштырыла.

Кагыйдә буларак, транскрипция латин графикасы нигезендә башкарыла, кирәк булган очракта махсус хәрефләр һәм диакритик билгеләр өстәлә. 1886 елда халыкара фонетик ассоциация тарафыннан эшләнгән транскрипция системасы иң киң таралганнардан санала.

Кирилл язмалы телләр өчен кириллицага нигезләнгән транскрипция системасы да кулланыла.

Практик транскрипция чит телдәге сүзләрне теге яки бу милли алфавит ярдәмендә язуны күздә тота. Практик транскрипция төгәллеге ягыннан фәнни транскрипциядән, әлбәттә, калыша һәм һәрбер тел өчен индивидуаль характерда була. Практик транскрипциядә теге яки бу телнең алфавитында булмаган махсус билгеләр дә юк. Мәсәлән, «Пушкин» исеме французча текстта – «Pouchkine», алманча текстта – «Puschkin», венгрча текстта – «Puskin» рәвешендә языла.

Сыйфатлы эшләнгән практик транскрипция һәрвакытта сүзләрнең асыл яңгырашын чагылдыра. Шул ук вакытта традиция буенча практик транскрипциянең дөрес булмаган үрнәкләре дә гамәлдә йөри. Мәсәлән, инглизчә «Хадсон» (Hudson) урынына русча Гудзон дип язалар.

Элек гарәби язулы булган төрки телләр өчен транскрипциянең берничә варианты эшләнгән. СССР дәверендә тюркологларның төп басмасы булган «Советская тюркология» журналы (1970–1991) тарафыннан латин графикасына нигезләнгән халыкара фонетик транскрипция кабул ителгән иде. Хәзерге вакытта исә бердәм транскрипция системасы юк. Теге яки бу текстологик хезмәтне нәшер иткәндә, һәрбер автор дип әйтерлек үзе кулланган системаны күрсәтеп узарга мәҗбүр.

# XX йөз башы гарәби язулы татарча текстларны кириллица нигезендә транскрипцияләүнең кайбер кагыйдәләре

## I. Фонетика

§1. Латин графикасындагы текстларны хәзерге татар графикасына күчерү зур кыенлык тудырмый. Ләкин иске әлифтә басылган әсәрләрнең сузыклар бирелешендә кайбер читен очраклар булуы мөмкин. Еш кына ا – әлифнең диариктик билгеләре куелмый; димәк, ул чакта аны: **а, ә, о, ө, ы – е, и** дип тә укырга мөмкин. Шикле булганда, сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

§2. Тартыклар бирелешендәге аерым очраклар түбәндәгечә:

ۋ – و – **в, у** (азакта): اول – *авыл;* تاو – *тау;*

غ – ع – **г, гъ:** منع – *мәнегъ, мәнгъ;* سعت – *сәгать*

ظ<br>ز – **з:** ذاكر – *закир;* ضيع – *зайг;* ناز – *наз;* ظلم – *золым;*<br>ض<br>ذ

ق – **к – къ:** قلم – *каләм;* نه ق – *нәкъ;*<br>ك – **к** – كم – *кем;* قارى – *кари;*<br>قا – **ка (къа)** : قاف – *каф*

س<br>ص – с سبق – *сабак;* صبا – *саба;* ثابث – *сабит;*

§3. كا – **кя**, لا – **ля**, گا – **гя** кушылмалары шул рәвешчә бирелә: *инкяр* – انكار; *кятиб* – كاتب ; *агяһ* – اگاه; *лям әлиф* – لام الف ;

Кайбер инде урнашкан, тотрыклашкан *сәлам, Камал, хезмәткәр, ислах, голәма* һ.б шундый сүзләр гадәттәгечә языла.

§4. Гарәп сүзләрендә, бигрәк тә абстракт, китаби сүзләрдә **б** – ب языла. Мәсәлән: *баб, гаиб, галиб,җәнаб,җәнабе гали,җәнабләре, калеб, инкыйлаб, гари<u>б</u> ( гаҗәп, сәер, ят; гидай, сәяхәтче мәгънәсендә. Имгәнгән, зәгыйфь кеше мәгънәсендә исә гари<u>п</u> языла)*

**§5.** Шуңа охшаш: *өмид // өмет, иҗад // иҗат, гаед // гает, Мөхәммәд // Мөхәммәт, идеп // итеп, идәрәк // итәрәк* һ.б.

§6. XX йөз башы текстларында **б // в // у** параллель дә йөри: *бар // вар, барачак // варачак, бирмеш // вирмеш, була // ула, булдыкын // улдыкын* һ.б. Текстта ничек, шулай калырга тиеш.

§7. Шундый ук хәл – **в // гъ:** *авыз // агыз, авыр // агыр* һ.б. тексттагыча калдырыла.

§8. Шуңа охшаш: *сагъ // сау, тугъды // туды, тугъры // туры, угылы // угълы* һ.б. автордагыча кала.

§9. Әгәр хәзерге язуда да еш кына ике төрле йөри торган: *ефәк – җефәк, егет – җегет, елкы – җылкы, йон – җон, елан – җылан, елгыр – җылгыр, елтер – җелтер* кебек сүзләр очрый икән, алар тексттагыча калдырыла.

§10. *Җир, җил, җимеш, җитми* кебек сүзләр күп очракта *йил, йир, йимеш, йитми* һ.б. дип язылган була. Болар, кагыйдә буларак, хәзерге орфография буенча алына да, бит астына төшермәдә: *«Автордa йил // йир һ.б. дип язылган»* – дип күрсәтелә.

§11. Кайбер сүзләрнең орфографиясе элеккеге һәм хәзерге вариантта янәшә кулланыла. Мондый очраклар автор язганча кала, берләштерелми. Мәсәлән:

*анлар // алар, нә // ни*
*бунлар // болар, нәкадәр // никадәр*
*аст // ас, дуст // дус, чобар // чуар*
*өст // өс дөрест // дөрес, юкары // югары*
*монарга // моңарга* һ.б.

## II. Морфология

§12. Килеш кушымчалары хәзерге орфография буенча языла. Мәсәлән:

**Юнәлеш килеш: -га/-гә, -ка/-кә:** *тауга, бигә, атка, мәктәпкә.* (*атга, мәктәпгә* түгел).

**Төшем килеше: -ны/-не** ( -ыны/-ене турында карагыз §13)

**Урын-вакыт килеше: -да/- дә, -та/-тә**: *тауда, өйдә, атта, мәктәптә* ( *атда, мәктәпдә* түгел)

**Чыгыш килеше: -дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән**: *аттан, мәктәптән, урманнан, рәсемнән* (*атдан, мәктәпдән, урмандан, рәсемдән* түгел).

§13. Әгәр автор иске төрки (көньяк төрки, госманлы төрки) формаларын кулланган булса, алар хәзерге килеш кушымчалары белән алыштырылмый, авторның үзендәгечә кала. Мәсәлән:

**Иялек килеше: -ың/-ең**: *адәмең* ( *адәмнең* түгел).

**Юнәлеш килеш: -а/-ә**: *бушә, мәйданә* (*бушка, мәйданга* түгел),

**йа – йә**: *дөньяйә* (*дөньяга* түгел).

**Төшем килеш: -ыны/-ене**: *тыныны, мәдрәсәсене (тынын, мәдрәсәсен* түгел*).*

**Чыгыш килеш: -дыйн/-дин**: *тагдин* (*таудан* түгел).

§14. Күплек кушымчалары( -лар/-ләр, -нар/-нәр) §12 та күрсәтелгән, чыгыш килеше кебек хәл ителә. Мәсәлән:اورمانلر *урманнар (урманлар түгел).*

§15. Фигыльнең заман кушымчалары хәзерге орфография белән языла. Мәсәлән:

**Хәзерге заман: -а/-ә, -ый/-и**: *кала, көтә, карый, сөйли* һ.б.

**Үткән заман: -ды /-де, -ты/-те**: *кайтты* ( *кайтды* түгел).

**Киләчәк заман: -ар/-әр, -ыр/-ер /-р**: *кайтар // кайтыр,*-**ачак/-әчәк**: *кайтачак* һ.б.

Искәрмә: Фигыль заманнарындагы көньяк төрки формалары: *барыйур, кәлийур, бардыкта, көлдектә, бармыш, кәлмеш, бараҗак, кәләҗәк* һ.б. турында карагыз §18.

§16. Юклык кушымчалары автор сөйләмендә кагыйдә буларак – мый/-ми рәвешендә язылган. Мәсәлән: *бармый, килми* һ.б. (Персонаж телендәге бармай, килмәй формалары исә шул килеш кала).

Искәрмә: -*майынча/-мәенчә* формалары турында карагыз §18.

§17. Хәл фигыльнең **–ып/-еп** формасы хәзерге орфография буенча языла. Мәсәлән: *дип, барып, килеп, кайтып* (*диб, барыб, килеб* түгел).

§18. Текстларда очрый торган түбәндәге формалар, кагыйдә буларак, авторда язылганча сакланырга тиеш, ягъни хәзергеләштерергә – модернизацияләргә ярамый.

**-ан/-ән ( -ян/-йән)**: *акан су, атаң ук* (*аккан су, аткан ук* түгел).

**-арак/-әрәк**: *Һәммәсе җыеларак сөйләшә башладылар.* (*җыелып* дип төзәтелми).

**-ачак/-әчәк // -аҗак/-әҗәк**: *барачак // вараҗак; киләчәк // киләҗәк. **-га** башка: дигәнгә башка* (*дигәннән башка* түгел).

**-ган соң/-гән соң:** *алган соң, белгән соң (алганнан соң урынына).*

Искәрмә: Моның киресе буларак, *бераз соң* дип куллану да очрый (*бераздан* дип үзгәртелми).

**-дисә // ды исә**: *чыкдисә* (*чыкты исә* түгел).

**-лыгы/-леге ///-лыкы/-леке**: *улдыгыннан (булганга түгел); кем идекене* (*икәнен* түгел).

**-дыгыннан/-дегеннән** – *хилаф улдыгыннан.*

**-дыкыннан/-декеннән.**

**-да/-дә**: *кирәк кадәрдә // кадәреңдә // кадәр* һ.б.

**-ла/-лә/-илә***: аныңлә, синеңлә, таңла, васитасилә* һ.б.

**-лайын:** *язлаен (язлыен)* һ.б.

**-ланды:** *гаед якындыладı (якынлашты* түгел).

**-ланды:** *хыялы нықланды (ныгыды, ныгайды* түгел), *кызыкланып карап йөри* (*кызыксынып* түгел)*; ямансуланды* (*ямансулады* түгел).

**-лыкны/-лекне/-лыныны/-лекене/-лыгыны/-легене:** *юклыгыны, ганлыкыны, китергәнлегене* һ.б.

**-лык/-лыйг/-лик/-лек илә:***көчлек илә,ачигълык илә* һ.б.

**-мага/-мәгә:***сорашмага, такмага* (*тагарга* түгел).

**-маенча/-мәенчә:***чәен эчермәенчә* (*эчермичә* түгел).

**-маз/-мәз:** *ачылмазмы // ачылмасмы (икесе дә булырга* мөмкин).

**-макга/-мәкгә***: укымакга* (*укырга* түгел).

**-макда/-мәкдә:** *макта/-мәктә: укымакта, килмәктә* (*килә иде* түгел).

**-маклы/-мәкле**: *күрмәклә* (*күрү белән* түгел).

**-мак кирәк:** *уздырмак кирәк, кермәк кирәк.*

***-мыз/-мез/-быз/-без*****:** *мәгъшукымыз, мәкъсудемез;максадымыз // максатыбыз* һ.б.

***-мын/-мен/-м*****:** *бармыймын, белмимен; күрмим, алмыйм.*

**-мыш/-меш**: *кыенлык күрмеш.*

**--ңыз/-ңез**: *атаңыз // атагыз.*

**гыз/-гез:***малыгыз // малыңыз.*

**-рым/-рем/-рмын/-рмен:** *һәммәсен дә белерем; күререм // күрермен.*

**-сын/-сен /-сың/-сең:** *эшлисен // эшлисең, адәмсен // адәмсең* һ.б.

**-ча/-чә/-гамча/-гәмчә:** *тамак туйганча* (*туйганчы* түгел).

**-ын/-ен**: *мәдрәсәдә укышны* (*укуны* түгел).

**-ыюр/-ийүр:** *барыюр, кәлийүр, ачыйыр/ачыюр* һ.б.

## III. Синтаксис сүзтезмәләре

§19. جناب عالي – *җанабе гали,*حالتي روحيه– *халәте рухия,* قصه اوق – *кыйссаи Aукъ* һ.б. шуның кебек сүзтезмәләр, ягъни фарсы изафәсе, ике сүз арасындагы бәйләү (хәмзә) билгесе язылу-язылмауга карамастан, югарыдагы үрнәк буенча, **-е, -и** кушымчасы өстәп, изафәләп, бәйләнешле итеп бирелә.

| | | |
|---|---|---|
| **احوال روحيه** | *әхвале рухия* | *эчке кичерешләр, рухи халәт* |
| **اهل اسلام** | *әһле ислам* | *мөселманнар* |
| **اهل قلم** | *әһле каләм* | *каләм ияләре, язучылар* |
| **عبد ملت** | *габде милләт* | *милләт колы, патриот* |
| **علم اسلام** | *галәме ислам* | *ислам дөньясы* |
| **جناب عالي** | *җәнабе гали* | *өстенлек иясе, бик хөрмәтле* |
| **جمعيت خيريه** | *җәмгыяте хәйрия* | *хәйрия җәмгыяте* |
| **قصهء اوق** | *кыйссаи Аукъ* | *Аукъ кыйссасы* |
| **ملت تاتار** | *милләте татар* | *татар милләте* |
| **محب ملت** | *мөхибе милләт* | *милләтне сөюче* |
| **رسم خط** | *рәсме хат* | *язу, почерк* |
| **حريت وجدانيه** | *хөррияте вөҗдания* | *вөҗдан иреге* |
| **حريت كلاميه** | *хөррияте кәлямия* | *сүз иреге* |
| **حريت مطبوعات** | *хөррияте матбугат* | *матбугат иреге* |
| **حسن ظان** | *хөсне зан* | *яхшы уй, яхшы фикер* |
| **حسن خط** | *хөсне хат* | *матур язу* |
| **هيئت رئيس** | *һәйәте рәис* | *һәйәт ( комиссия) рәисе* |
| **هيئت مبعوثان** | *һәйәте мәбгусан* | *депутатлар палатасы* |

§20. Гарәби изафәләр, мәсәлән, ابالحيات *абелхәят*, татар телендә урнашканча языла, ягъни аның гарәпчә-фарсыча әйтелешенә һәм русча язылышына да иярелми.

§21. Гарәп сүзләре һәм сүз тезмәләрендә кояш һәм ай хәрефләре (хоруфе шәмсия вә камәрия) кагыйдәсе буенча эш ителә.

Мәсәлән*: вәссәлам –* والسلام (*вәл-сәлам* түгел).

*Габдеррәхим, Габдрәхим – ( Габде-л-Рәхим* түгел).

*Габдессәлам –* ( *Габде-л-сәлам, Әпсәләм, Гапсәләм* түгел).

§22**.** Казакъ, төрек, үзбәк һ.б. төрки телләрдән үзгәртелмичә алынган өземтәләр хәзерге татар язуынча, ләкин шул телләрнең лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләрен исәпкә алып язылалар.

## IV. Лексика: сүзлек хәзинәсе

§23. Хәзерге татар теленә (әдәби тел һәм гомумхалык сөйләм теленә) хас булган күпчелек сүзләр хәзерге орфография буенча языла. Мәсәлән: *кеше, йолдыз* (*йулдуз* түгел)*; кара* قارە (*карә* түгел); *авыл* اول (*аул* түгел) һ.б.

§24. Теге яки бу авторның үз язу теле һәм стиленә хас булган җирле, диалекталь, өлкә сүзләре хәзерге әдәби тәңгәлләре белән алмаштырылмый. Мәсәлән:

*азбар – абзар* дип алмаштырылмый. Бу сүз кайбер төбәкләрдә үзенә хас бер мәгънәдә йөри: *азбар* – йорт-өйдән кала бөтен ихата-куралар дигән сүз ул (шулар эчендә сыер абзары, ат абзары, сарык абзары аерым була);

*баку, багу, бакмак – карау, карамак* белән алмаштырылмый.

*тирмән – тегермәнгә үзгәртелми.*

*тугару – туару* түгел.

*ялбару – ялвару* түгел.

*җилбер – җилбер – җилфер–җилфергә* әйләнми.

*тупрак – туфрак* дип үзгәртелми.

*төя – дөя* дип үзгәртелми.

§25. Текстларда кайбер сүзләрнең вариантлары параллель кулланыла:

*былчырак // пычрак*

*маңлай // маңгай*

*бозай // бодай*

*тулкын // дулкын һ.б.*

Мондай сүзләр текстта ничек, шулай алына.

§26. Текстлардагы иске төрки сүзләр һәм архаизмнар нинди дә булса стилистик функция үтиләр. Шуңа күрә алар нәкъ шул стилистик функция таләп иткәнчә, ягъни үзгәртелмичә, хәзергеләштерелмичә сакланалар.

*анҗак // анчак – әмма, ләкин, шулай да.*

*барыйш – табыш, файда.*

*безем – безнең.*

*бирү – бирле (башланганнан бирү).*

*бинзәр – охшаш, охшый торган.*

*буңа дик, буңа дик – моңа чаклы.*

*бән – мин.*

*дагы // дәхи – тагы, тагын, янә.*

*кеби // кебек* – янәшә кулланылып йөриләр.

*кыйла // кыла* – янәшә кулланылып йөриләр.

*ягъмур – яңгыр, явым, явым – төшем.*

*ярлыйг – ярлык, указ, фәрман, әмер.*

*ясигъ // йәсигъ – йәстү намазы һәм вакыты.*

Әгәр алар хәзерге гадәти лексика белән алмаштырылса, модернизация килеп чыгар иде, ягъни хронологик колорит (заман рухы) бозылыр иде. Икенчедән, теге яки бу очракта автор күздә тоткан стилистик функция дә ( югары стиль, тантана, күтәренкелек, шигърият, сатира-юмор, персонаж сөйләме һ.б.) юкка чыгар иде.

§27. Рус-европа алынмалары шул чордагы әйтелеш буенча язылалар (аларны бүгенге норматив орфографиягә күчерү модернизация булыр иде). Мәсәлән: *булыс // вулус (волость* түгел)*;гәзит (ә)* (*газета* түгел)*; марҗҗа – рус хатыны* дип алыштыру ярамый (*марҗа – Мария* сүзенең татарча әйтелеше генә); *әфисәр – офицер* дип алмаштырылмый*; Русия / Рәсәй – Россия* дип үзгәртелми.

Әлбәттә, бу кыска гына бүлектә язма мирасыбызда күзәтелгән барлык үзенчәлекләрне искә алып бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә, биредә искә алынмаган очраклар һәм мисаллар югарыдагы кагыйдәләргә чагыштыру белән карала һәм аналогия буенча хәл ителә. Теге яки бу текстның тел-стиль үзенчәлекләрен мөмкин кадәр үзгәртмичә транскрипцияләү текстолог өчен төп кагыйдә булып тора.

*Биремнәр:*

1. XX йөз башы гарәби язулы татарча текстларны кириллица нигезендә транскрипцияләүнең кагыйдәләре хакында мәгълүмат бирегез.
2. Гарәби текстларда кеше исемнәренең бирелү үзенчәлеге.

Әдәбият:

1. *Әдәби мирас һәм текстология: Мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 164 б.*

2. *Курбатов Х.Р. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы / Х.Р. Курбатов. – Казан : Таткнигоиздат., 1960. – 130 б.*

5. *Лихачев Д.С. Текстология. На материале русской литературы X–XVII веков. – 2–е изд. / Д.С. Лихачев. – Л. : Наука, 1983. – 639 с.*

*6. Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века / З.З. Рамеев. – Казань : Алма–Лит, 2008. – 188 б.*

*7. Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты (авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре) / З. Рәмиев. – Казан : РИЦ «Школа», 2000. – 180 б.*

*8. Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (урта гасырлар – XX йөз башы). – Казан, 2006. – 192 б.*

*9. Хәкимҗанов Ф.С. Хәзерге татар теле: Пунктуация / Ф.С. Хәкимҗанов, М.М. Шәкүрова. – Казан: Gumanitarya, 2003. – 388 б.*

## Төшенчәләр сүзлеге

**Алфавит (әлифба) –** язуда кулланыла торган хәрефләрнең кабул ителгән тәртиптә тезелгән җыелмасы.

**Алынма сүз** – берәр телгә башка телдән кергән сүз. Мәсәлән, татар телендәге гарәп, фарсы, рус алынмалары.

**Архаизм** – хәзерге вакытта кулланылыштан төшеп калган һәм башка берәмлекләр белән алыштырылган тел элементлары (сүзләр, тәгъбирләр, аффикслар).

**Археография** – кулъязма, басма һ.б. документаль ядкәрләрне җыю, тасвирлау һәм нәшер итү белән шөгыльләнә торган тарих фәне тармагы.

**Гарәп теле** семит-хәмит төркемендәге телләрнең семит тармагына керә. Гыйракта, Сүриядә, Ливанда, Согуд Гарәбстанында, Алжирда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Мисырда, Ливиядә һ.б. кайбер дәүләтләрдә кулланылышта.

**Гарәп язуы** – Көнбатыш Азиядә һәм Төньяк Африкада таралган язу төре. Б.э.ның IV йөзенә кадәр Гарәбстанда арамей язуы нигезендә барлыкка килә. Гарәп алфавитында 28 хәреф.

**Графема** – авазның язудагы билгесе, язу берәмлеге. Язу стиленә, сүздәге урынына бәйле рәвештә төрле вариантларда булырга мөмкин. Мәсәлән, «а» графемасының баш (А), юл (а), курсив *(а)* вариантлары бар.

**Графика** – нинди дә булса телнең язу чаралары җыелмасы. Тел гыйлеменең авазлар белән хәрефләр арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнә торган бүлеге.

**Дивани** – гарәп язуының бер төре. «Диван», ягъни «фәрман, боерык» сүзеннән. Бу төр язуда хәрефләр бер-берсенә эленеп, беркетелгән рәвештә языла. Дивани язуы дәүләтнең рәсми эш кәгазьләрен язуда файдаланыла.

**Имля (язу)** – сүзләрне дөрес язу тәртибе, орфография.

**Иске имля** – Татар халкында XX йөз башына кадәр кулланылган гарәп алфавиты.

**Искергән сүзләр** – актив лексикадан төшеп калган сүзләр.

**Каллиграфия** (хөсне хат) – матур язу сәнгате.

**Кириллица** – XI гасырда барлыкка килгән иске славян язуы. Византия миссионеры Кирилл исеменнән алынган. Соңрак кириллицага нигезләнеп хәзерге рус, украин һ.б. язулар барлыкка килгән.

**Кульязма татар китабы** – традицияләре Идел буе Болгары, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләренә барып тоташа. Кульязма татар китабын күчереп язуның үзәкләре мәчет һәм мәдрәсәләрдә була. Гарәп хәрефләре белән иске татар телендә (Идел буе төркие), гадәттә, кәгазьдә каз каурыеннан ясалган каләм, бамбуктан яки сөяктән ясалган таякчыклар, тушь, кара, сирәк очракларда кызыл минераллардан ясалган буяу белән язылган.

**Куфи** – гарәп язуының иң борынгы төре. Куфи язуы орнамент белән бергә геометрия кагыйдәләренә буйсынып эшләнә.

**Нәстәгълик** – үзендә нәсх һәм тәгъликъ үзенчәлекләрен берләштергән язу төре. Нәстәгълик – Иранда барлыкка килгән язу. Аның үзенчәлеге булып язганда хәрефләрнең өстән аска таба күчә баруы тора, ягъни язу вертикаль рәвештә эшләнгән кебек тоела. Бу стиль Һиндстан, Иран, Әфганстан, Пакыстанда кулланыла.

**Нәсх** – классик алты язуның берсе. Катлаулы куфи стилен алыштырып килә. Бу стиль хәзерге заман басма гарәп шрифтының нигезендә ята. Нәсх III гасырда барлыкка килә. Язуның вертикаль озынлыгы белән горизонталь өлеше бертигез озынлыкта, хәрефләре «тулы», «борылмалары» тирән, сүзләр арасында интерваллар бертигез калдырыла.

**Өзек хәрефләр –** үзеннән соң хәреф кушмый торган хәрефләр.

**Палеография** – кульязма чыганакларның тарихи үсештәге үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән. Палеография язу материалларын, язу билгеләрен, язу коралларын, кульязмаларның бизәлешен һәм буяуларын, кәгазьләрдәге су билгеләрен, кәгазьнең форматын һәм кульязма китап тышлыкларын өйрәнә.

**Рәйхани** – классик алты язуның берсе. Язу төренең матурлыгын хуш исле гөлгә охшатып бирелгән исем. Хәрефләрнең бер-берсенә үрелеп китүе белән аерылып торган язу.

**Рокъгә** – классик алты язуның берсе. Хәрефләрнең язылышы нәсх стиленә охшаш, тик үзенең йөгерек язылуы белән аерылып тора. Рокъгә – сөлс һәм нәсх стильләре нигезендә ясалган «кысынкы» стиль. Ул җиңел почерклардан санала, шуңа күрә дә тиз язуда күбрәк әлеге стильне кулланалар.

**Сингармонизм** (грек. *sin* – бергә, *harmonia* – яңгыраш) – сүздәге сузык авазларның калынлык-нечкәлек яки иренләшү ягыннан үзара охшаш булу күренеше.

**Сөлс** – өчтән бер өлеш дип тәрҗемә ителә. Классик алты язуның иң әһәмиятлесе, иң катлаулы һәм камил стильләрнең берсе. «Сөлс» I–II гасырларда нигезләнә.

**Текстология** (лат. *textus* – тукыма (нигез) һәм *logia* логия) –язма һәм басма әдәбият, фольклор әсәрләре текстларын тәнкыйди тикшерү, аныклау, чыганакларын, тарихын өйрәнеп басмага әзерләү белән шөгыльләнә торган фән. Мәгълүм булганча, аныкланган ышанычлы текстларга нигезләнмичә әсәрне идея-художество һ.б. яклардан өйрәнү, әсәргә яисә язучы, галим, автор иҗатына идея-эстетик анализ ясап булмый.

**Тугра** ул – хәлифнең, солтанның, ханның, дәүләт җитәкчесенең шәхси билгесе. Ул гарәп хәрефләрен матур итеп «боргалап» сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән язу. Тугра, гадәттә, дәүләт эш кәгазьләренә куелган, ул бу документның авторының билгесе булып торган. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, «тугра» сүзе «мөһер», «ярлык» мәгънәсен аңлата.

**Транскрипция** – нинди дә булса берәр тел яки диалект авазларын бу телнең язу системасыннан үзгәрәк булган хәрефләр, шартлы билгеләр белән бирү.

**Транслитерация** – чит тел сүзләрен үз телендәге хәрефләр ярдәмендә язу.

**Тәгъликъ** – «эленеп торган» дип тәрҗемә ителә. Нәсх стиле белән чагыштырганда, хәрефнең вертикаль элементлары кыскарак һәм нечкәрәк, ә горизонталь өлешләре дулкынсыман сыгылмалырак. Шигъри җыентыкларда кулланыла.

**Хаттат** – каллиграф, матур язу остазы.

**Хәрәкә** – кыска сузыкларны белдерү өчен кулланыла торган ас-өс билгеләре.

**Хәреф** – бер телнең алфавит составындагы график тамга. Авазларны язуда белдерү өчен хезмәт итә.

**Һәмзә** – бугаздагы тавыш ярыларының шартлап ачылуы нәтиҗәсендә ясала торган бугаз тартыгы.

**Шәмаил** – гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «бәла-казалардан саклаучы язу» мәгънәсен аңлата, ә фарсы теленнән «портрет», «сурәт» рәвешендә тәрҗемә кылына.

**Шикәстә** – тәүкигъ һәм тәгъликъ стильләрен кушудан барлыкка килгән стиль. Йөгерек курсив стиль.

**Эпиграфика** – кабер өстенә куелган ташка, металлга, агачка төшерелгән язма истәлекләрне өйрәнә торган фән.

**Язу** – график тамгалар системасы ярдәмендә аралашу чарасы.

**Яңа имля** – 1920 елда ТАССР ХКС декреты белән кабул ителгән гарәп алфавиты.

**Яңалиф** – 1927 елда кабул ителгән латин алфавиты.

## Әдәбият исемлеге

Төп әдәбият:


1. *Абзалов Л.Ф. Ханские писцы. Из истории становления и развития канцелярской службы ханов Золотой Орды / Л.Ф. Абзалов. – Казань : Изд-во «Яз», 2011. – 252 с.*
2. *Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы / М. Әхмәтҗанов. – Казан, 2000. – 285 б.*
3. *Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения : Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / Сост.: Р.Ф. Исламов, С.Ф. Галимов. – Казань, 2011. – 268 с.*
4. *Госманов М. Иске татар язуы нигезләре: Методик кулланма / М.Госманов. – Казан : КДУ, 1983.– 24 б.*
5. *Зәйнуллин Җ.Г. Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба / Җ.Г. Зәйнуллин. – Казан, 1989. – 112 б.*
6. *Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана: татарча уку-язуга өйрәнү методикасы һәм татар әлифбалары тарихы / Ф. Ибраһимов. – Казан : Мәгариф, 1994. – 265 б.*
7. *Исхакова Ә.Р. Гарәп язуы палеографиясе һәм каллиграфиясе. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен уку-укыту методик кулланмасы / Ә.Р. Исхакова. – Казан, 2009. – 80 б.*
8. *Ишмөхәммәтов Г. Гарәп графикасы нигезендә татарча әлифба : Уку-язу күнекмәләре / Г. Ишмөхәммәтов. – Казан, 1961.*
9. *Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы /Х.Курбатов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1960. – 130 б.*
10. *Маматов И.О., Таҗиева Л.К. Гарәби матур язу үрнәкләре һәм күнекмәләре / И.А. Маматов, Л.К. Таҗиева. – Казан : Тарих, 2001. – 80 б.*
11. *Салахова Э.К. Старотатарская письменность. Программа /Э.К.Салахова. – Казань : Казанский университет им. В.И.Ульянова, 2006. – 12 с. (на татарском языке).*
12. *Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. /М.А.Усманов. – Казань : Изд-во Казан. ун-та, 1972. – 223 с.*
13. *Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. /М.А. Усманов – Казань : Изд-во Казан.ун-та, 1979. – 318 с.*

14. Хәмзин К. Гәрәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / Хәмзин К.З., Мәхмүтов М.И., Сәйфуллин Г.Ш. – Казан : Татар, кит. нәшр., 1965. – 853 б.

Өстәмә әдәбият:

1. Алишев С.Х. Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар / С.Х. Алишев; Мөх-р Р.Г. Әмирханов; ТФА, Тарих ин-ты. – Казан, 2002. – 71 б.
2. Арабская средневековая культура и литература. – М., 1975.
3. Әдәби мирас һәм текстология: Мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 164 б.
4. Бартольд. Культура мусульманства. – IV т. – 1918.
5. Бибикова О.П. Калам острее сабли /О.П.Бибикова // Восточная коллекция, 2005. – № 1 (20). С. – 66–83.
6. Валеев Д.К. Шамаили / Д.К. Валеев // Из истории татарского народного искусства. – Казань : ИЯЛИ, 1995. С – 45–49 с.
7. Веймарн Б.В. Искусство арабских народов (средневековый период) / Б.В. Веймарн. – М. : Искусство, 1960. – 199 с.
8. Веймарн Б.В. Классическое искусство стран ислама / Б.В. Веймарн. – М.: Искусство, 2002. – 495 с.
9. Веймарн Б.В. Искусство арабских стран и Ирана VII – XVII вв. / Б.В. Веймарн – М., 1974.- 187 с.
10. Всеобщая история искусств: в 6 томах / Б.В. Веймарн и др. – М. : Искусство, 1960–1961 гг.
11. Гете И. Об искусстве / И. Гете. – М., 1975.
12. Госманов М. Каурый каләм эзеннән : Археограф язмалары. – Тулыландырылган икенче басма /М. Госманов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1994. – 463 б.
13. Госманов М. Иске татар язуы нигезләре : Студентлар өчен методик кулланма-таблицалар. 1 кисәк / М. Госманов. – Казан : Казан ун–ты нәшр., 1983. – 34 б.
14. Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы / Г.М.Дәүләтшин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1999. – 512 б.
15. Дульский П.М. Искусство Казанских татар /П.М. Дульский. – М. : Центр изд-во народов СССР. – 1925. – 19 с.

*16. Дульский П.М. Казанский каллиграф Али Махмудов / П.М. Дульский. – Казань, 1930. – 8 с.*

*17. Дульский П.М. Оформление татарской книги за революционный период / П.М. Дульский. – 1930.*

*18. Зәкиев М.З. Некоторые вопросы развития татарского литературного языка / М.З.Зәкиев // Вопросы языкознания. – Казань : Изд-во КГУ, 1965. – С.5–37.*

*19. Земное искусство – небесная красота : Искусство ислама (каталог выставки) / Государственный Эрмитаж; Под ред. М.Б. Пиотровского; Авт.-сост. каталожных описаний – С.Б. Адаксина и др. – СПб: Славия, 2000. – 359 с.*

*20. Ислам в Поволжье: история и проблемы изучения: Материалы научной конференции. – Казань : Иман, 2000. – 184 с.*

*21. Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. – Казань : ИЯЛИ, 1983. – 161 с.*

*22. История татарского литературного языка (XIII–первая четверть XX вв.). – Казань , Фикер, 2003. – 656 с.*

*23. Казиев А.Ю. Художественно-технические материалы и терминология книжной живописи / А.Ю. Казиев. – Баку, 1966. – 133с.*

*24. Костыгова Г.И. Трактат о каллиграфии Султана Али Мешхеди «Серат ас-Сутур» /Г.И. Костыгова // Сборник трудов Государственной публичной библиотеки им. С.- Щедрина. – Вып. 2. – Ленинград, 1957. – С. 103-163.*

*25. Крачковская В.А. Эволюция куфического письма в Средней Азии /В.А. Крачковская // Эпиграфика Востока. Т.3. – Л., 1949. – С. 4–27.*

*26. Крачковский И.Ю. Над арабскими рукописями /И.Ю. Крачковский. – М.: Наука. – 1965. – 232 с.*

*27. Курбатов Х.Р. Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка / Х.Р.Курбатов // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. – Казань,1992. – С. 20-25.*

*28. Курбатов Х.Р. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы /Х.Р. Курбатов. – Казан : Татар, кит. нәшр., 1960. – 130 б.*

*29. Лазурский В.В. Прекрасная книга о прекрасном искусстве /В.В.Лазурский // Искусство книги. Вып. 4 – М., 1961..*

*30. Лихачев Д.С. Текстология. На материале русской литературы X–XVII веков /Д.С. Лихачев. – Изд. 2–е. – Л. : Наука, 1983. – 639 с.*

*31. Малов В.Н. Происхождение современного письма / В.Н. Малов. – М., 1975.*

*32. Михайлова С.М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России / С.М. Михайлова. – Казань : Изд-во КГУ, 1991. – 341 с.*

*33. Мурадов А. Из истории каллиграфии в Средней Азии / А. Мурадов.– Ташкент: Фан, 1967.*

*34. Нуриева Ф.Ш. Борынгы төрки тел. Орхон-Енисей язмалары теле / Ф.Ш. Нуриева. – Казан : Казан ун-ты нәшр, 2007. – 144 б.*

*35. Нуриева Ф.Ш. Общий взгляд на развитие письменного литературного старотатарского языка (XIII–XIV вв.) / Ф.Ш.Нуриева // Языковые уровни и их анализ. – Казань : Изд-во ТГГИ. – 2001. – С. 29-35.*

*36. Письменные памятники Востока. Историко-филологические исследования. – М. : Наука, 1970. – 312 с.*

*37. Программа спецкурса "Исламоведение" / Казан. гос. ун-т, Ин-т востоковедения при поддержке Ин-та "Открытое о-во" (Фонд Сороса). Россия / Сост. А. Б. Халидов].–Казань: [б. и.], 2001.– 10 с.*

*38. Программа спецкурса "Каллиграфия" / Казан. гос. ун-т, Ин-т востоковедения; [сост. Д.А. Шарафутдинов; науч. ред. А.Б. Халидов. – Казань: [б. и.], 2001.–11 с.*

*39. Проненко Л.И. Каллиграфия для всех / Л.И. Проненко. – М. : Книга, 1990. – 248 с.*

*40. Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века / З.З. Рамеев. – Казань : Алма–Лит, 2008. – 188 б.*

*41. Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты; авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре / З. Рәмиев. – Казан : РИЦ «Школа», 2000. – 180 б.*

*42. Рукописная книга в культуре народов Востока. – Кн. 1. – М. : Наука, 1981. – 557 с.; кн. 2. – 1988. – 547 б.*

*43. Сабиров А.Р. Арабская каллиграфия / А.Р. Сабиров. – Казань: Иман, 2006. – 32 с.*

*44. Сафиуллина Р. История арабского книгопечатания / Р.Сафиуллина; науч. рук. А.Б. Халидов. – Казань : Иман, 1999.– 40 с.*

*45. Соколов-Ремизов С.Н. Литература, каллиграфия, живопись / С.Н. Соколов-Ремизов. – М. : Наука, 1985. – 205 с.*

*46. Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (урта гасырлар – XX йөз башы). – Казан, 2006. – 192 б.*

*47. Татар грамматикасы: 3 томда. Т. 1. – М. : Инсан, К. : Фикер, 1998. – 45–49 б.*

*48. Хакимзянов Ф.С. Булгарский литературный язык или же Литературный язык булгарской эпохи / Ф.С. Хакимзянов // Тенишевские чтения : Сборник научных статей. – Казань : ТГГПУ, 2008. – 256 с.*

*49. Хакимзянов Ф.С. Варианты реализации поволжского литературного языка / Ф.С. Хакимзянов // Старотатарский литературный язык : Исследования и тексты. – Казань, 1991. – С. 28-36.*

*50. Хаков В.Х. Татар әдәби теленең үсү һәм нормалашу процессына караган кайбер мәсьәләләр / В.Х. Хаков // Вопросы тюркологии. – Казань, 1970. – 166–175 б.*

*51. Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше / В.Х. Хаков. – Казан : КДУ нәшрияты, 1972. – 224 б.*

*52. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе / В.Х. Хаков. – Казан : Тат. кит. нәшр., 2003. – 14 б.*

*53. Халидов А.Б. Арабские рукописи и арабская рукописная традиция / А.Б. Халидов; Акад. наук СССР. Отд. истории. Ин-т востоковедения.–М. : Наука, Гл. ред. вост. лит., 1985.–302 с.*

*54. Хәкимҗанов Ф.С. Хәзерге татар теле: Пунктуация /Ф.С. Хәкимҗанов, М.М. Шәкүрова. – Казан : Gumanitarya, 2003. – 388 б.*

*55. Хисамова Ф.М. Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – нач. XVIII вв.) / Ф.М. Хисамова. – Казань, 1999. – 407 с.*

*56. Червонная С.М. Искусство Татарии / С.М. Червонная. – М., 1987. – 352 с.*

*57. Шамсутов Р.И. Искусство татарского шамаиля (19 – нач. 20 вв.) / Р.И. Шамсутов – Казань, 2001. – 184 с.*

*58. Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле / Р.И. Шамсутов. – Казань, 2003. – 199 с.*

*59. Шимел А. Исламская каллиграфия /А. Шимел // Родина, 2001. – № 5. – С. 30.*

*60. Щепкин В.Н. Палеографическое значение водяных знаков /В.Н. Щепкин, М.В. Щепкина // Проблемы источниковедения. – Вып. 6. – М. : Изд-во АН СССР, 1958. – С. 325–346.*

*61. Юзиев Н. Әдәбият хәзинәләре /Н. Юзиев. – Казан, 1978. – 192 б.*

*62. Юзиев Н. Әдәбият чыганаклары белеме (әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре) / Н. Юзиев. – Казан : Фикер, 1998. – 175 б.*

**КУШЫМТА № 1**

Белемне тикшерү өчен тест:

1. Гарәп әлифбасы барлыкка килгән территорияне күрсәтегез:
   а) Согуд Гарәбстаны;
   б) Марокко;
   в) Алжир;
   г) Һиндстан.
2. Классик гарәп алфавитындагы хәрефләр саны:
   а) 23;
   б) 31;
   в) 29;
   г) 28.
3. Гарәп алфавитына фарсы теленнән өстәлгән хәрефләр:
   а) дәл, зәл;
   б) пи , чин, җим, гәф;
   в) әлиф;
   г) син, шин.
4. Өзек хәрефләрнең барысы да күрсәтелгән җавапны билгеләгез:
   а) әлиф, дәл, зәл, ра, зә, уау;
   б) дәл, зәл, ра, зә;
   в) әлиф;
   г) әлиф, уау.
5. Өзек хәрефләрнең алфавит тәртибендә бирелгән вариантын күрсәтегез: ژ ۋ و ذ د ا ز ر
   а) ژ ۋ و ذ د ا ز ر
   б) ر و ژ ۋ ذ د ا ز
   в) ۋ و ژ ز ر ذ د ا
   г) ا ذ د ژ ۋ و ز ر
6. «Әлиф» хәрефе:
   а) башка хәрефләр ясауда катнаша;
   б) башка хәрефләр ясауда катнашмый;
   в) дүрт шәкелдә языла;
   в) тартык авазларны белдерә ала.
7. ی хәрефенең исеме –
   а) мим;
   б) нүн;
   в) уау;

г) йа.

8) Хәрефләрнең исеме белән аларның язылышын тәңгәлләштерегез:

| | |
|---|---|
| س | фи; |
| ل | ләм; |
| ط | син; |
| ف | тый. |

9) Дөрес вариантларны билгеләгез:

| | |
|---|---|
| قارعا | саба; |
| شار | багана; |
| صابا | карга; |
| قالفاق | чабата; |
| باعانا | шар; |
| چاباتا | калфак. |

10. «Гүзәл» сүзенең дөрес язылыш вариантын күрсәтегез:

а) گـزل

б) گوزه ل

в) عوزل

г) عوضال

11. Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү.

а) 1342;

б) 908;

в) 922;

7) 1552.

12. Җүчи Олысында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгән ел.

а) 1226;

б) 1312;

в) 1342;

г) 1445.

13. Сул баганадагы хәрефне уң баганадагы шул ук хәрефнең исеме белән туры китерегез:

| | |
|---|---|
| ج | чим; |
| چ | җим; |
| غ | гъайн; |
| ع | гәйн. |

14. «һә»хәрефенең шәкелен туры китерегез:

| | |
|---|---|
| ﻫ | сүз уртасында; |

| | |
|---|---|
| هـ | сүз башында; |
| ه | аерым язылышы; |
| ـه | сүз азагында. |

15. Гарәп язуында тартык авазны икеләтеп әйтүне таләп итә торган билге:

а) сәкен;

б) тәшдид;

в) кәсрә;

г) һәмзә.

16) Гарәп язуында тартыкның йомыклыгын белдерә торган билге

а) маддә;

б) сәкен;

в) тәнвин;

г) фәтхә.

17) Классик алтылыкка кермәгән стильне билгеләгез:

а) нәсх;

б) мөхаккак;

в) күфи;

г) рокъгә.

18. хаттат ул… :

а) матур язу остасы;

б) классик алты язуның берсе;

в) кулъязма башында бизәкләп ясалган урын;

г) хәрефләрнең нечкә элементлары.

19. Казан университетында эшләгән атаклы каллиграф

а) Ш. Мәрҗани;

б) К. Насыйри;

в) М. Мәхмүдов;

г) Р. Фәхреддин.

20. Хәрәкәләр алар:

а) язу төрләре;

б) аст-өст билгеләре.

21. Көнчыгыш кулъязмаларын җыючы, университет китапханәсе белән дә җитәкчелек иткән, хәзерге вакытта ул җыйган кулъязмалар университет китапханәсендә аерым фонд тәшкил итәләр.

а) И. Хәлфин;

б) К. Фукс;

в) И. Готвальд;

г) К. Насыйри.

22. Совет чорында татар кулъязмаларын тикшерү һәм җыюны башкарган атаклы археограф:

а) С. Вахиди;

б) К. Насыйри;

в) Ш. Мәрҗани;

г) Г. Утыз Имәни.

23. Җүчи Олысы канцеляриясендә өстенлек иткән язу төрләре.

а) сөлс;

б) дивани;

в) куфи;

г) нәсх.

24. Архитектур биналарны бизәгәндә иң еш кулланыла торган язу төре:

а) рәйхани;

б) нәсх;

в) куфи;

г) мөхаккак.

**КУШЫМТА № 2**

## Гарәп хәрефләре белән язу өчен текстлар:

**Текст № 1**

Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

***

Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен булыр.

***

Сабырлы чыдый, сабырсыз елый.

***

Көзге бозның көзге калынлыгына да ышан, язгы бозның ястык калынлыгына да ышанма.

***

Ашлыкны арба өйгә кертә, чана базарга илтә.

***

Ат кешнәп, адәм сөйләшеп таныша.

***

Сүз утыз теш арасыннан чыкса, утыз кешегә җитә.

***

Сыйламага сыең булмаса да, сөйләмәгә телең булсын.

***

Кызлы йорт – фәрештәле йорт.

*(Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. – Казан : Таткнигоиздат, 1957. – 243 б.)*

**Текст № 2**

Казаннан килгән туп,
Авызы-борыны юк,

Тышы таш, эче боз,
Үзе кып-кызыл,
Күлмәге ямь-яшел.

***

Аттым таш,
Тоттым кош,
Атканым таш түгел,
Тотканым кош түгел,
Торган иле ил түгел,
Утырган җире җир түгел.

*(Татар табышмаклары. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1970. – 567 б.)*

**Текст № 3**

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була;
Биегән кеше өстәлендә
Ипи белән май була.

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була;
Бай булмаса да, тук була,
Кайгы-моңы юк була.

***

Яңгыр, яу, яу, яу!
Ашлык уңсын ызанда,
Ботка пешсен казанда;
Алтын кашык базарда,
Көмеш кашык болытта.
Нык яварга онытма!

*(Балалар фольклоры. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1984. – 485 б.)*

**Текст № 4**

**Кәкре каен терәткән**

*(Татар халык әкияте)*

Борын заманда бер алдакчы кеше булган, ди. Ул теләсә кемне алдый ала икән.

Үзен бик акыллыга санап йөргән бер бай кеше:

– Мин шул аАлдарга очрасам, һич тә алдатмас идем, – дип, күкрәк суга икән.

Бервакыт бу кеше юл буйлап барганда күрә: юл буенда әлеге Алдар бер кәкре каенны терәп тора, имеш.

Бай аның янына барган да:

– Йә, дус, сине алдарга бик оста дип әйтәләр, мине дә алдый алырсың микән, алдап кара әле, – дигән.

Алдар әйткән:

– Нигә сине алдый алмам икән? Бик тиз алдар идем дә, янымда алдар капчыгым юк бит, өйдә калды, – дигән.

Бай, аны-моны уйламыйча, Алдарга әйткән:

– Бар, алайса, капчыгыңны алып кил, мин монда көтеп торырмын, – дигән.

– Алдар аңа әйткән:

– Өйгә бик кайтыр идем дә, менә бу каен аварга тора, китәргә ярамый бит, – дигән.

Бу кеше, бик үрсәләнеп:

– Барсана, зинһар, капчыгыңны китерсәнә, син килгәнче, каенны үзем терәтеп торырмын, – дип, кәкре каенны терәтеп калган.

Алдар шул китүдән киткән, ди, ә теге бай әле дә булса кәкре каенны терәп тора, ди.

*(Алтын алма. – Казан : Мәгариф, 2006. – 244 б.)*

**Текст № 5**

Татарлар арасыннан башлап дини вә милли бөек хезмәтләр иткән Мәрҗани хәзрәтләренең нәсәбе: Шиһабетдин бине Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим бине Габдеттәүуаб бине Габделгани бине Габделкоддус бине Йәдәш бине Ядкәр бине Гомәр.

Бабаларыннан Габделкоддус, Мәрҗан авылының урынына беренче мәртәбә килеп утырып, шул авылны нигезләгәнлектән, нисбәтлә-

рендә «Мәрҗани» дип мәшһүр булганнар. Мәрҗан Казаннан 50 чакырым ераклыкта.

*(Мәрҗанинең тууына 100 ел тулу уңаеннан 1915 елда Казанда нәшер ителгән «Мәрҗани» мәҗмугасыннан өзек.)*

**Текст № 6**

Уфа шәһәрендә торганда, ошбу көнгә кадәр Оренбург шәһәренә – ике мәртәбә, асыл ватаным булган Кичүчат һәм Чубытлы авылларына – өч, Болгар шәһәре харәбәсенә бер мәртәбә барып килдем.

Җәй көнендә иң элек Түбән Шәлчеле авылына бардым. Монда исә бергә гомер сөргән иптәшләремне, ничә ел бергә укыган шәрикләремне күрергә, фикере илә җәннәткә чакырылган бер кеше кеби шатлык вә мәхәббәт белән килгән идем. Фәкать, килгәч, ни күрим, күңелемдә булган кешеләремнең һичбере юк. Алар урынына бөтенләй мин танымаган халыклар тулган. Шул дәрәҗәдә өметсез булдым ки, бәян итәргә көчем калмады. Дөньяның эше җыелганны тарату, таратылганны җыю икән.

*(Р. Фәхретдиннең 1905 елда үз кулы белән язылган «Тәрҗемәи хәл»еннән өзек.)*

**Текст № 7**

Рус шәркыять белгечләренең иң галимнәреннән вә шуның илә шәрык гыйлеменә дә вә, аерым алганда, татар-төрекләргә гаэдлар илә иң күп шөгыльләнүчеләрдән берсе, һич шөбһәсез, асаре гатикаларының рәисе булган профессор Катановтыр. Бу зат, 1884 елдан бирле теге җәмгыятьнең әгъзасы булып, 1894 елда җәмгыятьнең хокукый әгъзасы һәм сәркятибе ителеп сайланган вә 1898 елны исә җәмгыятькә рәис ителгән. Катанов җәнабләре асаре гатика җәмгыятендә әгъза булган шәрык галәменә гаять тә бик күп файдалы нәрсәләр язган рәис булганнан соң да аларга даир күп эшләр башкарды.

*(Һ. Атласиның «Шура» журналында басылган «Профессор Катанов илә мөсахәбә» исемле мәкаләсеннән өзек.)*

**Текст № 8**

Болгар шәһәренең урыннарында бик күп төрле нәрсәләр табыла. Зиярәт кылырга килүчеләр җирдән табылган нәрсәләрне, хосусан, акчаларны сатып алып китәләр, ул нәрсәләрне кара халык арасында төрле авырулардан файдалы дип, шәрәфәтле нәрсә кеби йөртәләр,

балаларының түбәтәенә яки янына тагалар. Анда табылган нәрсәләрне чит мәмләкәтләрдән килүчеләр сатып алып китәләр, Болгар нәрсәләре белән бөтен Русия музейлары тулган дип әйтерлек, хәтта чит мәмләкәтләрнең музейларында да бик күп җыелган, имеш.

*(Г. Әхмәревнең «Болгар тарихы» хезмәтеннән өзек.)*

**Текст № 9**

Сөенбикә мәшһүр нугай князе Йосыф мирза кызы булган. 1533 елда Казанның 17 яшьлек хөкемдары Җангали ханга хатынлыкка бирелгән. Ул вакытта Сөенбикә үзе дә бик яшь булган, имеш. Җангали, Казан ханлыгына Мәскәү князе Василийның ярдәме белән куелганлыктан, Сөенбикәне дә аның рөхсәте белән алган. Мәмләкәтне карамаенча, бозык вә фәна эшләр белән шөгыльләнгәнлектән, Русиядән китереп куелган Җангалине Казан халкы бер дә яратмаган, Мәскәүгә дошман булып Казаннан бер мәртәбә куылып киткән Сафагәрәйне яңадан хан итү нияте берлә 1535 елда Казанда Җангали ханны үтергәннәр. Аның зарарына тырышучылар, хосусан, князь Булат һәм Гәүһәршад бикә булган, имеш. Алар Кырымнан Сафагәрәйне бик тиз чакырып китергәннәр. Җангали хан берлә 2 генә ел торып тол калган Сөенбикә 1535 елда Сафагәрәйгә яшь хатынлыкка бирелгән.

*(Г. Әхмәревнең «Казан тарихы» хезмәтеннән өзек.)*

**Текст № 10**

Сәгыйдә остазбикәдә бер дә артыклык-кимлек юк иде. Ул гади генә авыл остазбикәсе иде. Аның кияүгә чыгуы да муллаларда булганча гади генә булды. Ул кыз булып үсеп килә башлагач та төрле җирдән муллалар, мөәзиннәргә, мулла сыманрак булырга тырышкан байларга сорарга тотындылар. Әтисе хәзрәт, мужик халкын яратмаганга, мөәзиннәрне Хуҗа Насретдин хәзрәтләренең мәгълүм ишәге тупрагыннан яратылган дип икътикад иткәнгә, һәммәсенә сүз кайтара килде.

Абыстай кайвакытларда Сәгыйдәнең буйга җитеп егермегә басуыннан курыккаласа да, хәзрәт, тәкъдире язганы булыр дип ышанганга, һаман да сүзендә торды.

Менә, еракта гына булса да, яңа указ алган бер муллага Сәгыйдәне сорарга килделәр. Остазбикә булачак авылы кара як булганга, сораган яшь мулланың атасы тирә-юньдә наданлык берлән шөһрәт тоткан Рәхим мулла булганга, кардәш-кабилә әүвәлдән үк чит күрделәр.

Ләкин хәзрәт үзе кияү булачак шәкертне әлләкайда гына – шәһәрдәме, Казан юлында пароходтамы – бер мәртәбә күреп ихлас баглаганга, «киңәш итешик» дигән җавапны бирдертте вә башкода булып килгән Фәхри мөәзин артыннан ук, абыстайның туган кардәшен, ат җиктереп, шул авылга югалган атны эзләргә җибәрделәр... Яшь мулланың бөтен хәл-әхвале, надан Рәхим мулланың хатыны, бала-чагасы, мәхәллә халкы, мәхәлләнең яшь муллага карашы, тирә-юнь муллаларның яшь мулладан өметләре хакында тулы мәгълүмат китерергә куштылар.

*(Г. Исхакыйның «Остазбикә» әсәреннән өзек.)*

**Текст № 11**

Китапчылык һәм нәшрият эшләре. 1905 революциясе елларында әдәбият үсешенә параллель рәвештә ул вакыттагы гарәп хәрефләре белән китап басу машиналары булган басмаханәләр дә арта, нәшрият эшләре дә шактый алга китә. 1914 елда Казан шәһәрендә гарәп язулы ун матбага була. Боларның бишесе төрки ширкәтләрнең яисә аерым кешеләрнең шәхси милке иде (бертуган Кәримиләр вә «Өмет», «Милләт» ширкәтләре; бертуган Шәрәфләр һәм элеккеге Харитонов матбагалары.)

Бары тик Казан шәһәрендә генә дә җиде милли сәүдә китап йорты бар иде (бертуган Кәримиләр, «Сабах», «Мәгариф», «Гасыр», «Юл» ширкәтләре, Һади Максуди, Хөсәеновлар сәүдәсе). Ул елларда китап кибетләре һәм басмаханәләр башка шәһәрләрдә дә (Оренбург, Уфа, Әстерхан, Троицк, Орск һәм хәтта Петербургта да) бар иде.

Идел буенда гарәп хәрефләре белән басылган әсәрләрнең исемлеге 1915 елда Петербургта оештырылган матбугат күргәзмәсенә куела. Бу исемлек игътибарны җәлеп итәрлек дәрәҗәдә зур була.

1905–1907 елларда Казан төркиләренең икътисади хәле шактый яхшыра. Авыл кешеләре игенчелектә төрле машиналар куллана башлыйлар, кооперативлар, кечкенә кредит банклары төзиләр. Шәһәр һәм бистәләрдә җитештерүнең төрле өлкәләренә караган төрки ширкәтләр һәм бай кешеләрнең җитештерү һәм сәүдә йортлары шактый арта.

Шул рәвешле Казан һәм Урал төркиләре мәдәни һәм икътисади өлкәләрдә үсү, алга китү дәверен кичергәндә, 1914 елның җәендә, Русия дә катнашкан Беренче бөтендөнья сугышы башлана, ә 1917

елның язында, әле сугыш та тәмамланмаганда, Икенче рус революциясе кабынып китә.

*(Г. Батталның «Казан төркиләре» хезмәтеннән өзек.)*

**Текст № 12**

**Бәллү**

Кыйгач кашым,
Асыл ташым,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү!
Хублар хубы,
Алма тубы,
Пешкән, тулгансың!
Бу чагында
Син тагын да
Чибәр булгансың!
Алмакаем,
Аппаккаем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү-бәү!

Җилбер-җилбер,
Син бик тилбер –
Күбрәк уйныйсың!
Ал гөлләрне, Сөмбелләрне
Өзми куймыйсың.
Кил, гөлкәем,
Сөмбелкәем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү!

Йокла шунда...
Син төшеңдә
Колын менәрсең;
Алмачобар,
Арбасы бар –
Менә күрерсең!
Колынкаем,
Кил, җанкаем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү!

Юл юлдашың
Һәм кулдашың
Сиңа бар эштә
Һәм саклаучы,
Һәм яклаучы
Булсын фәрештә.
Кил, бөдрәкәй,
Фәрештәкәй,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү!
*(Дәрдемәнд.)*

**Текст № 13**

**Дусларга бер сүз**

И кардәшләр, кул тотышып, алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк, –
Егыла-тора, алга таба атлыйк имди.

Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;
Диңгез якасында торып, без сусамыйк, –
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!
Мәзлүмнәргә якты, нурлы көннәр килде, –
Азатлыкның кояшы тугъды имди.
*(Г. Тукай)*

**Текст № 14**

**Туган җиремә**

Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссемне;
Тарта торгач, куймады, кайтарды ахыр җисмемне.

Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,
Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине, –

Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби;
Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби.

Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гаркъ итмәде;
Алды дүрт ягымны ялкын, якмады, харкъ итмәде.
*(Г. Тукай)*

**Текст № 15**

**Кайсыгызның кулы җылы**

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.

Күлмәк җиңен ертасымы? –
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:

– Кайт!.. – дип хатлар килделәр..
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
– Бусы – алкалары,
Бусы – кабере... – диделәр.

Әгәр тагын килсәләр:
– Сау! – дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы? –
Бәйлисе бар йөрәкне...
*(Х. Туфан)*

**Текст № 16**

**Кашларың карасына ла...**

Карасалар карасыннар
Кашларың карасына.
Тик ят укларны үткәрмә
Керфекләр арасына.

Кашларың карасына ла,
Гөл куйдым арасына.
Тик синең карашың дәва
Йөрәгем ярасына.
*(Р. Фәйзуллин)*

**Текст № 17**

**Туу**

Табигатьнең уртасында
Күзне текәп таңга,
Исем китеп басып торам,
Калып торам таңга.

Могҗиза көтүдәнмени?
Мин тик таңны көтәм.
Кеше кебек, шигырь кебек
Ул да туа икән.
*(М. Әгъләмов)*

**Текст № 18**

***

Сердәш булды авыл йолдызлары –
Шат чагыммы, авыр чагыммы –
Керфектәге күз яшендә хәтта
Йолдызлы күк тетрәп чагылды.

Нишлисең бит... Китәселәр бар шул –
Бу гомерне артык сузалмам;
Минем кадәр соклanучы булмас! –
Күк гөмбәзен шуңа кызганам.
*(Зөлфәт)*

**КУШЫМТА № 3**

## Язу үрнәкләре

**Уку өчен тәкъдим ителгән басма һәм кулъязма текстлар**

№ 1. Г.Тукай. Туган тел. М.Җәлил. Катильгә.

№ 2. Г.Тукай. Пар ат.

№ 3. Г. Тукай. Туган авыл.

№ 4. Г.Тукай. Милли моңнар.

№ 5. Г.Тукай. Фатыйма белән сандугач. Ак бабай. Кызыклы шәкерт.

№ 6. Ш.Мәрҗанинең вафатына 100 ел тулу уңаеннан чыгарылган хезмәттән өзек. (Мәрҗани. – Казан : Мәгариф, 1915.)

№ 7. Р.Фәхретдиннең кыз балаларга багышланган нәсихәтләреннән өзек. (Р.Фәхретдин. Нәсихәт. – Оренбург : Вакыт, 1916.)

№ 8. Менәргә иде Урал тауларына. Идел кызы. (Милли җырлар һәм шигырьләр. Өченче кисәк /җыючы Гайса Хәкимҗан. – 1966.)

№ 9. Безнең көннәр. Авылны сагыну. (Милли җырлар һәм шигырьләр. Өченче кисәк / җыючы Гайса Хәкимҗан. – 1966.)

№ 10.Урман сүзе. Күңелләрем сине эзли. (Милли җырлар һәм шигырьләр. Өченче кисәк / җыючы Гайса Хәкимҗан. – 1966.)

№ 11. Гармун тавышы. Җирән кашка. (Милли җырлар һәм шигырьләр. Өченче кисәк / җыючы Гайса Хәкимҗан. – 1966.)

№ 12. М.Гафури. Сөембикә манарасы.

№ 13. Г.Кариев. Тукай Мәкәрҗәдә // Аң. – 1914. – № 7. – 134–135 б.

№ 14. Хатт мөгаллиме. – Казан : Бертуган Кәримевләр, 1913. Китапның сүз башы.

№ 15. Казан шәһәренең әхвале // Календарь, сәнәи һиҗрия 1316, сәнәи миладия 1899 / Авт.-төз. Ф.Халиди. – Казан, 1898. – 49-54 б.

№ 16. Җәгърафия вә тарих фәннәре // Мәңгелек календарь / Авт.-төз. Ш.Хәмиди. – Казан, 1908. – 118 б.

№ 17. Казан тарихы // Мәңгелек календарь / Авт.-төз. Ш.Хәмиди. – Казан, 1908. – 127-132 б.

№ 18. Татар халык шагыйре Г.Тукайның Габдерахман Дәүләтшинга язган хаты. Казан, 1908, 9 июнь. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 345 т.).

№ 19. Гыйшык хаты үрнәге. XIX йөз азагы. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 1253 т.).

№ 20. Казан дигән калада... Бәет. XIX йөз азагы. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 2365 т.).

№ 21. Кызлар киндер агарта. Бәет. XIX йөз азагы. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 2365 т.).

№ 22. Яшь кызны картка биргән вакыттагы бәет. XIX йөз азагы. Казан (Идел буе федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 2365 т.).

№ 23. Метрика кенәгәсе. Туучылар сәхифәсе. 1903 ел. Татарстан Республикасы Милли архивы. 204 ф., 177 тасв., 13 эш, 532 а.

№ 24. Метрика кенәгәсе. Вафат булучылар сәхифәсе. 1902 ел. Татарстан Республикасы Милли архивы. 204 ф., 177 тасв., 13 эш, 60 б.

№ 25. Метрика кенәгәсе. Никахлашучылар сәхифәсе. 1903 ел. Татарстан Республикасы Милли архивы. 204 ф., 177 тасв., 13 эш, 522 а.

№ 26. Метрика кенәгәсе. Талак сәхифәсе. 1903 ел. Татарстан Республикасы Милли архивы. 204 ф., 177 тасв., 13 эш, 510 а.

№ 27. Метрика кенәгәсе. Талак сәхифәсе. 1906 ел. Татарстан Республикасы Милли архивы. 204 ф., 177 тасв., 13 эш, 233 б.

№ 28. Иртәнге азан. XIX йөз азагы. Казан (Идел буе федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 2365 т.).

№ 29. Г.Кандалый шигыреннән өзек. Бән сөйми дип әйтсәң... XIX йөз азагы. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 2450 т.).

№ 30. Сугыш бәете. XIX йөз азагы. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 8243 т.).

№ 31. Акча алу турында расписка. Казан губернасы Чар (Царевококшайск) өязе Күлле Киме волосте. 1908 ел, 3 июнь. Казан (Идел буе федераль университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 334 т.).

№ 32. Тарихчы һәм әдип Г.Гобәйдуллинның Хәсәнгата Габәшигә язган хаты. Казан, 1911 ел, 18 октябрь. Казан (Идел буе) федераль

университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 1036 т.).

№ 33. Хәсәнгата Габәшигә «Хәрби Шура» рәисе Ильяс Алкин хаты. Казан, 1917 ел, октябрь. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге.).

№ 34. Р.Фәхретдиннең «Асар» исемле хезмәтенең кульъязмасы. Казан (Идел буе) федераль университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 1496 т.).

№ 35. «Дәфтәри Чыңгызнамә». XVII йөз азагы тарихи ядкяренең 1732 елгы күчермәсеннән өзекләр. Казан (Идел) буе федераль университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. № 40 т.).

№ 36. Хәрби коллегиянең Габделкәрим Гаид углын есаул итеп билгеләү һәм аның вазифалары турында нәсихәтнамә. Россиянең Борынгы актлар дәүләт архивы. 6 ф., 416 эш, 2 өлеш, 184б.

№ 37. Полковник Бәхтияр Канкай углы, старшиналар Габдулла Мостай углы һәм Балтач Сәид углының Казан өязенең нугай һәм башка даругалары сотникларына башкүтәрүчеләр отрядларыннан качкан дезиртирларны һәм башка сотнялардагы кешеләрне өстәмә мобилизация турында приказы. 19 июль, 1774. Россиянең Борынгы актлар дәүләт архивы. 6 ф., 416 эш, 2 өлеш, 99 б.




Гайнетдин Әхмәревнең 1911 елда нәшер ителгән «Хөсне хат нәмүнәсе» исемле китабыннан матур язарга өйрәтү үрнәкләре




1913 елда бертуган Кәримевләр тарафыннан нәшер ителгән «Хатт мөгаллиме» исемле китаптан язу үрнәкләре

الخطّ يبقى زماناً بعد كاتبه

الخطّ يبقى زماناً بعد كاتبه    وكاتب الخطّ تحت الأرض مدفون

وكاتب الخطّ تحت الأرض مدفون

تَعَلَّمْ قِوَامَ الْخَطِّ يَا ذَا التَّأَدُّبِ

فَإِنْ كُنْتَ ذَا مَالٍ فَخَطُّكَ زِينَةٌ فَمَا الْخَطُّ إِلَّا زِينَةُ الْمُتَأَدِّبِ

وَإِنْ كُنْتَ مُحْتَاجًا فَأَفْضَلُ مَكْسَبِ

ا ب ج د ر د ر س س ش ص ط ع ف — ق ک ک ل م ن و ه لا ی ے با

با بت بج بد بر بس بش بص بط بع بف — بق بک بل بم بن بو به بلا بی بے

جا جب جج جد جر جر جپ جس جش — جص جط جع جف جق جک جل جم جب

جن جو جه جلا جی جے سا پست — سج سد سپ سر سس سش سص سط سع سف

سق سک سل سم سپم سن سو سپه سه — سلا سی سے صا صب صج صد صد



فق فك فل فم فه فن فو فه فلا في كا كب كج كد كر كس كش

كص كط كع كف كو كك كل كم كن كو كه كلا كى كى ما مت مح مد مر

مس مش مص مط مع مف مق مك مل مم من مو مه ملا مى يى مى ها هب

هج هد هر هس هش هص هط هع هف هق هك هل هم هم

من هو هه هه ها هى تمت المفردات

КАЗАНЬ.
Лито-Типографія Т-го Д-ма „Бр. Каримовы“

# 53. Саннар язылышы



## Укыгыз һәм күчереп языгыз

### Язу үрнәкләре

آ ا ـا بـ ـبـ ـب ب پـ ـپـ ـپ پ تـ ـتـ ـت ت

ثـ ـثـ ـث ث جـ ـجـ ـج ج چـ ـچـ ـچ چ حـ ـحـ ـح

ح خـ ـخـ ـخ خ د ـد ذ ـذ ر ـر ز ـز ژ ـژ سـ ـسـ

ـس س شـ ـشـ ـش ش صـ ـصـ ـص ص ضـ ـضـ ـض ض

ط ـط ظ ـظ عـ ـعـ ـع ع غـ ـغـ ـغ غ فـ ـفـ ـف ف قـ ـقـ

ـق ق کـ ـکـ ـک ک ـك ك گـ ـگـ ـگ گ ـنک نک ـڭ ڭ لـ ـلـ ـل

ل مـ ـمـ ـم م نـ ـنـ ـن ن هـ ـهـ ـه ه ـۀ ۀ ـه ه و

ۋ ـو و یـ ـیـ ـی ی ـلا لا

### Укыгыз һәм күчереп языгыз

آز آق آل آر آس آش آغا آزا آلا آنا

آتا آپا آچا آرپا آراتا آلما آرقان بابا باز باغانا

بارماق باتقاق تابا تاتار تازارا تالاق تارماق جاناش

جای چاباتا چاتان چاتناغان چارلاق دار دان داستان

ساپ ساز ساق ساران ساباقتاش سایلانا سالماق

شامان شاه صاف فاش فال قاداق قازاق قاناغان

قاراساق قابارتما قازان قالفاق کادر کازارما لاف لایلا

لاقان لاشمان لاباسا لامپا لاپاس مارس ماقتانا مای

مالای ناز نارات واق واز یاز یاق یالغان یالاغای

اَبْ ، اَتْ ، اَثْ ، اَجّْ ، اَچْ، اَحْ ، اَدْ ، اَرْ ، اَزْ، اَسْ، اَشْ،
بَنْ ، بَرْ، بَدْ، تَنْ، اِبْ ، اِتْ ، اِثْ، اِجْ، اِچْ، اِدْ، اِرْ، اِزْ، اِسْ،
بِنْ، تِنْ ، بِرْ، تِرْ ، اُبْ، اُتْ، اُثْ، اُجْ ، اُچْ ، اُدْ ، بُنْ ، تُنْ، بُرْ،
تَارْ، بَارْ ، سَازْ ، شَازْ، جَامْ ، دَارْ، رَامْ، سَالْ، طَالْ، طَاوْ، طَایْ،
وَاقْ ، وَایْ، یَاتْ ، یَارْ، یَازْ، یَاقْ ، یَالْ، یَانْ، اوزُمْ ، اوغُمْ، اولُمْ،
بولُمْ، توشَكْ ، تومَرْ، سوزُمْ ، قولُمْ ، كوزُمْ ، یوزُمْ، یولُمْ، آزْدی،
آلْدی، آوْدی، تالْدی، تامْدی، تایْدی، جانْلی، جانْدی، جاوْدی،
چالْدی، سالْدی، صاوْدی، قارْلی، قاشْلی، قالْدی، قویْدی،
قونْدی، كورْدی، كومْدی، كولْدی، مانْدی، واتْتی، یوْتْتی، یازْدی،
اَبْجَدْ، اَعْضَا ، اَعْظَمْ ، اَعْلَمْ، اَدِیبْ، اَدَبْ، اَژْدَها ، اَكْبَرْ، اَلِفْ،
بِیعَیْبَه ، بَلُّور، بِنَا، بَدْبَخْتْ ، بُلغَارْ، بَدَوِی ، بَدَوامْ ، بَیْتْ، بَنْدَه،
تَبْرِیكْ، تَوَكُّلْ ، تَعْبِیرْ، تَذْكِیرَه ، تَكَبُّرْ، جُنْسِی، جِدِّی، جِنَایَتْ،
جُمْعَه ، جَبْرْ، جَدِیدْ، جَمْعِیَتْ، جَنْجَالْ، جَرَاحَتْ، جَوْهَرْ،
حِكْمَتْ، حِرْصْ، خِیَانَتْ، خُدَا ، حُضورْ، دِقَّتْ، دِلْبَرْ، دَلِیلْ،
دَرْوِیشْ، دَرْدْمَنْدْ ، دَرْسْ، رِضَا ، رِزْقْ ، رَوْشْ، رَسَّامْ، رَسْمِیْ
زِینَّتْ، ظُلْمْ، زَهَرْ، سِحْرْ، صُلْحْ ، صِفَتْ، سَبَبْ، سَیَّار، صَنْعَتْ،
شِعْرِیَتْ، شِرْبَتْ، شَكْلْ، شَرِیعَتْ، شَرِیفْ، شَرْقْ، شَفْقَتْ،
عَدْلْ، عَزِیزْ، غَیْرَتْ ، عَمَلْ، عَرِیضَه ، عَرَفَه ، عَوْرَتْ، عِشْقْ،
فِعْلْ ، فِكْرْ، فِرْعَوْنْ ، فَلْسَفَه ، قَبَاحَتْ، قَبِیلَه، قَدْرْ، قُدْرَتْ،
مُعْتَبَرْ، مَعْنَوِی، مِلَّتْ، نِسْبَتْ، وَقْتْ، وَطَنْ، وَسْوَسَه، یادْكارْ

## توغان تل

ای توغان تل، ای ماتور تل، ئەتكەم-ئەنكەمنڭ تلی!
دُنيادا كور، نەرسە بلدم سين توغان تل آرقلی.
ايكِ الك بو تل بلەن ئەنكەم بيشكتە كويلەگەن،
آنناری تونلەر بويی ئەبكەم حِكايت سويلەگەن.
ای توغان تل! هر وَقتتا يارده ملڭ برلەن سينڭ
كچكەدەن آڭلاشلغان شادلغم، قايغم مينم.
ای توغان تل! سيىده بولغان ايكِ الك قلغان دُعام:
يارلقاغل، ديب، لوزم هَم ئەتكەم ئەنكەمنی، خُدام!

ع. توقای

## قاتيلگە

مين تز چوكەم، قاتيل، سينڭ آلدا،
قول ايتسەڭ دە، توتقن ايتسەڭ دە،
كيدەن ايكەن، اولەم آياغورە،
بالتا بلەن باشم كيسسەڭ دە.
مڭن نوگل، بارن يوزن گنە
يوق ايتەلدم سينڭ سگارنڭ.
هەم حالقمنان، قايتقاچ، شونڭ اوُچن
مين تزلەنب عافو سورارمن.

م. جەليل

# پار آط.

(لیرمونتوفنڭ „Тройка“ شعرن اوقو تأثیرندن.

جیکدرب پار آط، قزانغه طوب طوری کیتدم قاراب،
چابدرا آطلرنی کوچر، صوقغالاب ده طارتقالاب.

کیچ ایدی، شادلق بله‌ن نورلار چه‌چب آی یالتری.
ایسکان ئه‌کرن ییل بله‌ن یافراق آغاچلر قالتری.

هر طرف طن. اوی میڭا تیك، ئه‌لله‌نی جرلی، اوقی،
نرسه‌دندر، کوز ئلنگان هم تمام باصقان یوقی؛

برزمان آچسه‌م کوزم، بر نورلی یاب‌یات قر کوره‌م،
آه بو نیندی آیرلو؟ عمرمده بر طابقر کوره‌م.

صاو بول ایندی! خوش بخیل بول، ای مینم طورغان ییرم!
مین بولای، شولای ایته‌م، دیب تورلی اوی قورغان ییرم!

خوش عمر ایتکان شهر! ایندی یراقده قالدڭز،
آه! طانش یورطلر تمام کوزدن‌ده سز یوغالدڭز!

اچ پوشا، یانا یوره‌ك، حسرت اچنده اویده مین،
ایچماسام ایبده‌ش‌ده یوق ایچ، تیك ایکه‌وبز: اوی ده‌مین.

آه گناهم شوملغی، بو کوچری بیك طن طاغن:
جرلامیدر بر ماتورنڭ بالداغن یا قالفاغن.

ـەلله نرسەم یوق کبی، بر نرسه یوق؛ بر نرسه کیم؛
ـارده بار، تیك یوق طوغانلر، مین یتیم، مونده یتیم.

مونده بارده یات میڭا: بو میـڭعلی، بیکموللا کم؟
ـیکمحمد، بیکتیمر بر سنده بلمیم، ئەلله کم!

ـزدن آیرلوب طوغانلر! جایسز، اوڭغایسز طورو.
ـو طورو ئەیتورگه ممکندر: قویاش، آیسز طورو.

ـوندی اویلر برله طاشدای قاتدی کیتدی باشلرم،
چبشمه توسلی اختیارسز، آقدی کیتدی یـاشلرم.

ـر طاوش کیلدی قولاقغه یاڭغرادی بر زمـان:
ـطور، شەکرت! بیتدك قزانغه، آلدمزده بیت قزان!"

بوطاوش بیك آچدی کوڭلم؛ شادلغمدن جان جانا،
ـئەیده چاب، کوچر! قزانغه، آطلرڭ قو: نا! نانا!"

ئەیته ایرتەنـگی نمازغه بیك ماتور موڭلی أذان.
ای قزان! دردلی قزان! موڭلی قزان! نورلی قزان!

مونده‌در بزنڭ بابایلر، تورلری پوچماقـلری،
مونده‌در دردلی کوڭلنڭ حورلری، اوجماخلری،

مونده حکمت، معرفت هم مونده عرفان، مونده نور،
مونده مینم نچکه بیلم، جنتم هم مونـده حور.

۱۹۰۷ سنه.

## طوغان آول.

طاو باشینه صالنغاندر بزنڭ آول،
بر چیشمه بار، یاقن بزنڭ آولغه اول،
آولمزنڭ یه‌من، صووی ته‌من بله‌م
شوکارکوره سویه‌م جانم، ته‌نم بلەن.

خدای شونده جان بیرگان، مین شونده طوغان
شونده اوّل قرآن آیتن اوقوغان،
شونده بلدم رسولمز محمدنی:
نیچك محنت، جفا کورگان، نیچك طورغان.

ایسدن چقمی بونده مینم کورگانلرم،
شادلق بلەن اویناب عمر سورگانلرم،
آبی بلەن برگه‌لەشوب قارا جیرنی
صوقا بلەن یرطوب، یرطوب یورگانلرم

بودنیاده بلکه کوب، کوب اشلر کورم:
بیلگیسزدر قایا طاشلار بوتقدیرم،
قایابارسام، قایده طورسام، نیشله‌سه‌مده
خاطرمده مەنگی قالور طوغان جیرم.

# ملی موڭلر.

ایشتدم مین کیچه بره‌و جرلی،
چن بزنڭچه ماتور ملی کوی.
باشقه کیله اویلر تورلی، تورلی،
ئه‌لله نیندی زارلی، موڭلی کوی.
اوزلوب، اوزلوب‌کنه ئه‌یتوب بیره
تاتار کوڭلی نیلر سیزگانن،
مسکین بولوب طورغان اوچیوز یلده
تقدیر بزنی نیچك ایزگانن.
کوبمی محنت کورگان بزنڭ خلق،
کوبمی کوز یه‌شلری توگلگان،
ملی حسلر برله‌ن یالقنلانوب
صزلوب، صزلوب چغا کوڭلندن.

جیران بولوب جرنی طڭلاب طوردم،
طاشلاب توبه‌ن دنیا اویلرن،
کوز آلدمده کورگان توسلی بولدم
«بلغار» هم آق ایدل بویلرن.
توزه‌لمادم؛ باردم جرلاوچیغه
دیدم: „قرده‌ش بو کوی، نیندی کوی؟“
جوابنده ملتده‌شم میگا:
„بو کوی بولا، دیدی، ئه‌للوکی!“

۱۹۰۹ سنه.

## فاطمه بلەن صاندوغاچ.

فــاطمه: نی اوچون سین صایرامیسڭ صاندوغاچ؟
شاد بولا کوڭلم مینم سین صایراغاچ.
چیتلـگڭ ئەیبەت، یانـگدە بار آشڭ،
نیك کوڭلسز سبن بولای بوکدڭ باشڭ؟

صاندوغاچ: آه مینم صایرار ییرم اورمان ایدی،
آنده هر تورلی قزق طولغان ایدی،
مین بو ییرده نیگه شادلق کورسەتیم؟
آنده اوچ باش قوشچغم قالدی یتیم!

هم مینی آنده طاغن دوستم کوته،
صاغنا اول، صارغایا اول، اوت یوتا.

بلمیسکمی سین چیتن محبوسلك اول،
بولسەده آلتون، هاماندە چیتلك اول.

فاطمه: جه آلایسه مین ایشك آچدم سیڭا،
بار آزاد بول، قیل میڭا ایزگی دعا،

بار، جانم ایندی یەشل اورمانغه اوچ
تیز یتیم قوشچقلرڭ برلەن قاوش.

## آق بابای.

بتون دنیا آپپاق بولوب قار یاوغانده،
ایشك آلدی، اورام، توبه آغارغانده،

أپپاق بولوب قايتوب كيلە بزنڭ باباى،
بزگە تورلى، تورلى اوينچق آلغاندە.

شادلانشوب بز ئەيتەمز: «رحمت باباى
سيڭا، طاغن كوب يل عمر بيرسون خداى».

باباى مسكين قار، ياڭغرغە قاراميچە
بزنى شادلاندرمق اوچون يورى شولاى.

---

## قزقلى شەكرت.

ئەيدەلى آقباى، اوبرەن سين آرت آياغڭ برلە طور!
آوما، آوما، طوب‌طورى‌طور، توزاوطور، ياخشى‌اوطور!

– نيك عذابليسڭ بولاى سين، مين ئەلى بيك كچكنە،
مين طوغانغە تيك ايكى آيلاب بولور يا اوچ كنە.

يوق كيرەكمى، مين اويرەنميم، مينم اوينيسم كيلە:
شول بولونلردە ياتاسم، شوندە آونيسم كيلە.

– آخ جولەر مائماى! طرش يەشلەى، زورايغاچ جايسزاول،
قارتايوب قاتقاچ بوونلر، اش بلو اوڭايسز اول!

# لوندن نشر شركتی.

## LONDON Puslishing Company

**نسبكه دائر اثرلرنی نشر ایتوگه خصوصی اهمیت بیریله.**

خزینه‌دار: یوجین گه‌ده‌مس　　　　　　كاتب: ویلیام‌ستون

**مارت ۲۰　۱۸۷٤سنه.**

**افنـدم!**

علمی اثرلرنی نشر ایتو اشینه نظـر دقت ایتووگزنی اوتنه‌بز. حیات‌گز وتورغان اورنـگز حقنده اجمالی معلومات بیروب، امتال اوستینه قازوب یاصالوراق روشده ابنوب توشورولـگان فوتوغرافـگزنی یبه‌رسه‌گز ایـكان.

پارتریتلرنی قازوب یاصاو، وفوتوغرافلرنی یاگادن توشورو اشلری ایك اوستا آدملر طرفندن اشله‌نه‌در.

اوزگز وتورغان شهرگز حقنده‌غی اجمالی معلومات ۱۵۰۰سوزدن عبارت یاكه آرتغراق بولورغه یاری. سزنك طرفدن یباریله‌چك اجمالی معلومات‌نی وه‌پوارث دیسون، فرو آسالا، والهیات دوقتوری جوزف اوغس وباشقه مشهور محررلر قاراب ترتیب ایتوب بیره‌چكلردر.

بو اش بر عائله ایه‌سینك عائله‌سینه قالدرا تورغان بر اثری ویادكاری بولدیغندن زور بر اهمیتنی حائز بولسه كیره‌ك. بوندی نرسه‌لرنی نشر ایتونك بعضا بره‌وگه اقتصادی، صناعی، وسـیاسی جهتلردنده فائده‌لی بولوی بیك ممكندر.

اوزگرنك وتورغان شهرگزنك فوتوغرافلری كابینیت اولچه‌وننه (عادی ۋیزیتنی كارتچكه اولچه‌وندن زورراق) بولورغه تیوشدر.

بزگه تاغیده زنهار اوزگزنك تورغان شهرگزنی تفصیلا توصیف ایتوب آرخیتكتوراسی، بیرلری، وتاریخی جهتدن اهمیتلی نرسه‌لری حقنده تفصیلا یازساگز ایـكان.

حاضرلنگان معلوماتنی اوبوشدررغه وقت بیك ینکاتلکلن
لطفا بو اشکه تیزرهك اهمیت بیرساڭز ایدی.

احترام بلهن
لوندن نشر شرکتی
پرافیسور یوجین ئەدەمس.

## شهاب حضرتنك جوابی.

افندم!

مارت ۲۰ تاریخلی مکتوبڭزنی آلدق. اوز طرفڭزدن توصیف اینولگانچه اوزمنك فوتوغرافمنی وحیاتم حقنداغی اجمالی معلوماتنی سزگه یبارامن. اما تورغان شهرمنك فوتوغرافینی یبارو ممکن بولمادی. حیاتم حقندهغی اجمالی معلومات عربچه یازیلمشدر. بیرگان قرارڭزنی لطفا بڭا بلدرساڭز ایدی.

احترام بلهن
ملا شهاب‌الدین.

# آتا و آنا ادبلری

۱) حرمتلو قزلر! آناگزغه حرمت ایتگز. آلدنده و آرتنده کامل خشنودلق ایله ادبلرینی رعایت قیلگز. آتا و آناگزنی اخلاص ایله سویگز هم وصیتلرینی یرینه کیتورگز. مرادلرینه قارشو کیلمه‌گز. قاتیغ کوگللی بولماگز. آلارنی حسرتلندرمه‌گز. بار اجتهادگز ایله آلارنی رضا قیلگز. آتا آناسینه اطاعتلی بولغان، علم ایله زینتله‌نگان قزلرنگ عادتلری کوندن کون گوزلله‌نور. دوست و بلشلری آراسنده اسملری حرمت ایله سویله‌نور. اما آتا و آنالرینی حرمتسز ایتکان و آلارنگ سوزلرینه قولاق صالماغان قزلر محبتسز بولورلر، آتا و آنالری ده اوزلرینی سویمازلر، چیت کیمسه‌لر کوزلرنده‌ده خور کورلورلر. دنیاده گوزل ترکلک هم ایته آلمازلر.

۲) آتاگز یاننده اوطورسه‌گز ادبلی بولگز، کوب کولمه‌گز، کیوملرگز ایله اویناماگز، آنگ تاوشندن آرتق تاوش ایله سویله‌مه‌گز.

۳) آتاگزدن باشقه کیمسه‌دن، کیره‌ک ایگ یاقین کیمسه‌گزده بولسون، هیچ نرسه صوراماگز. چونکه طوغری کیلگان برکشیدن نرسه صورامق قزلرنگ کوگللری بوزولوغه سبب بولور. آتاگزدن صوراغانده‌ده چیت کیمسه‌لر یوق وقتلرده‌غنه ادب ایله صوراگز

وبیرماسدلر قات قات صوراب بوده‌تمه‌گز.

٤) آتاگزچیت یرده ویاکه وفات ایتکان بولسه آنك یرینه قالغان طوغانلرگزنی آتاگز حکمنده طوتگز.

٥) آقچه و باشقه قدرلی نرسه‌لرگزنی آتاگزده صاقلاگز. آناگز رخصتندن باشقه آشامق و ایچه‌ك نرسه‌لرینه قول صوزماگز. کوچگز یتدیکنده یورت واوی خدمتلری طوغروسنده آنالرگزغه یاردمچی بولگز. آلارنك قول آرالرینه کرگز. اوی خدمتلرینی باشقاررغه اوگره‌نگز. نیك طورماگز. عذر بولماغانده یاتوب طورماگز، اوست و باشگزنی پچراق یورتمه‌گز.

## طوغانلر ادبی

٦) طوغانلرگزنی حرمتلی طوتگز. آلار ایله ادبلی بولگز؛ چونکه آتا و آنالرگزدن صوك ایك یاقین کیمسه‌لرگز طوغانلرگزدر.

٧) اوزگزدن الوغ بولغان طوغانلرگزنی آتا و آناگز یرنده حساب ایتگز. آلارغه تاوش کوتارمه‌گز؛ آلار ایله نزاعلاشماگز. آلارنك سوزلرینه خلافلق ایتمه‌گز. آلارنی سویگز.

٨) کچکنه طوغانلرگزغه شفقتلی بولگز، رنجتمه‌گز. آلار قولنده بولغان نرسه‌لرنی قچقرتوب آلماگز. چونکه بو اشلر آلارنك کوگللری بیوغوغه، آتا هم آنالرگزنك آچولانولرینه سبب و قزلرنك ادبسز بولولرینه علامت بولور.

٩) قولگزده بولغان نرسه‌لر ایله طوغانلرگزنی قزقدروب قاراتوب طورماگز یاکه آلارغه هم الوش چقارگز. هر نه ایسه آلارغه بیك شفقتلی بولگز.

١٠) طوغانلرگزدن ناگاه ادبسز اشلر کورلسه یومشاقلق ایله‌گنه:

«بو اش عیبدر؛ اشله‌مه‌گز!» دیب خاطرلرینه توشرگز. حق یولنی کورسه‌تگز.

۱۱) طوغانلرگزنی آتا و آنالرگزغه یمانلاب سویله‌مه‌گز. تللرگزنی آدم یمانلاوغه عادتله‌ندرمه‌گز.

## قارنداشلر ادبی

۱۲) آتالرگز و آنالرگز ایله بو طوغانلرنی و آلارنڭ بالالرینی، باشقه قارنداشلرگزنی‌ده حرمت ایتگز. آلارنی یاقین کورگز. غیبتلرینی سویله‌مه‌گز. آلارنڭ حرمتلی کیمسه‌لر ایدکلرینی هیچ اونوتماگز.

۱۳) آتا و آنالرگز رخصت ایتکان وقتلرده قارنداشلرگزنی زیارت ایتگز. خسته‌له‌نسه‌لر حاللرینی صوری بارگز، چیتده بولغانلرینی بلشوب طورگز. آلارنڭ شادلقلرینه شادلانگز و قایغولری بولسه قایغولرینی اورتاقلاگز. آلارنڭ خدمتلرینی باشقارگز.

۱٤) قارنداشلرنڭ الوغلرینه، آتالرغه بولغان حرمت مثالنده حرمت ایتگز؛ کچوکلرینه طوغانلرغه بولغان شفقت مثالنده شفقت کورسه‌تگز.

## کورشیلر ادبی

۱۵) یاقین کورشیلرنڭ حقلرینی رعایت ایتگز. مونلرنی قارنداشلرگز کبی کورگز. آلارنڭ حاللرندن غافل طورماگز. حاجتلرینی اوته‌گز، خسته‌لرینڭ حاللرینی صوراگز. قایغو و شادلقلرینی اورتاقلاشگز. چیتگه کیتدکلرنده حاللرینی بلشوب و صوراب طورگز. حاجت وقتلرنده یاردم ایتگز، آلارغه ایزگولك ایسته‌گز یه سمکن قدر احسان ایله‌گز.

بزننك كونله ر

يانلا رينڭا اوچوب بار ر ايد م
مينم قوللار قانات توگلله ر
شول ياقلا رغا قوشلا ر كيتكه نه ساين
نيلك تالپنا مينم كوكلله ر
نيچه نچى قات ايندى يازلا ر كيلدى
چه چه كله ر گه بيرنى كومد يله ر
تاغيد ا شولا ئه بر كوررگه زارغب
اوته ر ميكه ن بزننك عومر له ر

يــازغى جر

جه يگى ياگڭر ياوغان چاقدا تامچى بولاسم كيله
تامچن بولوب كر فيكيگه تامب قوناسم كيله
يازغى سيرين چه چه ك آتقاچ سيرين اوزه سم كيله
سيرين چه چه كله رن اوزوب سيگا بيره سم كيله
يازغى جيلله ر ايسكه ن چاقدا مين سين بولاسم كيله
جيل بولوب سيننك چه چكنى سيفاف اوره سم كيله

ایدل قزی

وطنم نڭ عادی بر قزی مین
تووب اوسدم ایدل بویندا
چه چه لك جیدم حه تفه بولونلاردان
جراویره ندم سابان تویندا
حه یران قالدم جه یگی اورمانلاردا
تگلاب که کـکوکله ر نلڭ تاوشن
اوتوب آلب یوره گیمه سالدم
چیشمه له رنڭ چلتراب آغشن
دولقن دولقن بولسن آرش تییره نگه نده
کوکره ب اوستی مینم قرلارم
ئش سویوچی یاقداشلارم جرلاب
نچکه رنددیله ر کوکلم قللارن
جر توزوچی اوگفان یه ش قزلارنڭ
شه ب توزوون تگلاب تاڭ قالدم
تووب اوسکه ن شوشی گوزه ل ییرده ن
جرلاریما ده رتلی موڭ آلدم

منه رگه ایدی اورال تاولارینا
منه رگه ایدی اورال تاولارینا
باسارغا ایدی قویاش قارشینا
شول اویاد ان قوشلار جرلارلار ایدی
اورال بورکوتله ری تاوشینا
یورسه لڭ ایدی اورال کوکره گنده
سالاوات یولای یورگه اول چاقدا
بلمیم نیکد ر یارسب ساغنا بله م
آشقنا یوره گم شول یاققا
بلزگه ایدی اورال تاولارندا
بورکوتله ر نڭ قانات قاققانن
قارشیلارغا ایدی توغان ایلمنی
نورغا کومب تاکڭلا ر آتقانن

آولنی ساغنو

ئه ی آول سین نیندی کیك کوگللی

نیندی ایرکن سیننك قولا رك

نیندی ماتور سینك تاو اوسله رك

نیندی زیفا یلغا بویلا رك

ئاول اورامندا ئاز یورسه گده

کوب اوتکه نله ر ایسگه توشه له ر

قالدیلا بیت اویناب اوسکه ن جیرله ر

قالدی بیك کوب بلگه ن کشیله ر

ایرکن قرلار قالدی قالووندا

موندادا بیت اورن تار توگل

آندا مینم تووب اوسکه ن ییرم

تیك تارتلا شوگا بو کوگل

تورلی تاووش بله ن سوزب سوزب

یاکغراتب آول اورامن

جرلی ایدك شوندا اوزوب اوزوب

یه ش واقتنك ده رتلی جرلا رن

## اورمان سری

مین ایشته من شوندا یافراق لارنك
شپردا غان تاوش سوزله رن
تیك بر گته کون اورمان اوغلی بولسام
سویله ر ایدم اورمان سرله ر ن
سالقن تاشقا باسب اوسکه مندم
سوزلب یاتقان یه شل تاولارغا
قوللا رمنی قویب ماڭلا ییما
اویلیم اورمان تاوشن تڭلا رغا
اورلتی چه چه دم ایندی اورمان اوسسن
اورمان اوسسن ایندی دالادا
مین دن یادگار بولسون هه ر بر تاڭدا
هه ر بر تاڭدا توغان بالاغا

کوکلله رم سینی ئزلی

تونگی یاقلا رغا قاریم دا

یوره کم دولقنلا نا

سویگه نمنی تون بویی نا

قاراب ساغنرغا قالا

سوبویلارینا توشدم ده اوزوب آلدم بر غیاق

ئیرکه م مینم یراقلا ردا شوکا کوکلوم بویوئ

کیلر قاوشو کونله ر آچلر تونگی یاقلار

آلا ردا ماتور جلمایب بزنلڭ قاوشونی قوتلار

آقلی کولمه ك

آقلی کولمه کله ر تکتردم جه ی کونی کیه رمن دیبب

کوڭلمنی سیکا سالدم اوزولب سویه رمن دیبب

ساندوغاچلار قولغا توشمی توشمه سه ده باغا لمای

کوڭلله رم سینی ئزلی ئزله سه ده تابالمای

آغاچلا ر یافراغن قویا کوزگی جیلله ر ایسکه نده

ئوزگه له نه یوره ککه یم سین ایسیمه توشکه نده

## غارمون تاوشی

آی بوغارمون تاوشی نیندی ماتور
نیندی ماتورایکه ن تگلا رغا
تاگمی غارمون کبلک ته ملی جرلار
تگلا نرلار کیلر تاگلاردان
تیزده ن کیلر جرلار موزیکاسی
قایغی موگن سزب یلا ماس
کشیله رگه سویگه ن یارن جویب
یه ش بالادای یامان سلاماس
آی مین کوره م یه شلک باقچالاردا
بره ؤ جلو بالان توبنده
کرفك آراسندان قاینار یه شی
چقلار بولب جیرگه توگلگه ن
اول هاماندا شونده ا هه رکون ساین
چغب جلو ایکه ن ایرته سن
قاینار یه شی چقلار یاسی ایکه ن
ساغنغانغا سویگه ن ایرکه سن

## جیره ن قاشقا

جه یله وله رگه بارد ق بیه له ر ساود ق
باش کونه که یله رنی قولغا آلب
جیره ن قاشقا آتقا یم باشن چه یکی مالقایم
آللارندا سولوسی بتسه سزلا یوره ك مایقایم
ایسه ن ده گه یوروب ساو قایتغز
کیته سز بیت ایلله رده ن قوزغالب
جیره ن قاشقا آتقایم جیلله ر تاری جالقاین
ایه رله گه ن جگتله رنی تاشلا ب قایتا مالقایم
جه یله وله رنی تاشلا ب قورال آلب
بز کیته بز منب له ی آتلا رغا
جیره ن قاشقا آتقایم آلدان بارا مالقایم
ایه رله نگه ن جگت بارسا بوئوغا بلمه سر مالقایم
ایسه ن تورغز ایندی بر قایتر بز
بیش یازغز جه واب خاتلا رغا
جیره ن قاشقا آتقایم جیللر تاری یالقاین
ایسه ن یوروب مین ساو قایتسام اوقالارمن یالقاین

# سویمبیکه مانارِاسی

هه‌ر بنادان بیك اولوب کوکلارگا چقمئش باشك
مین بلام بلدرماساك ده اغادر کوزده‌ن یاشئك
بوحالگنان شکایت قیلدی سینك هر بر طاشـــك
قالبئمی مئك پاره قیلدی شول گوزه‌ل حان مسجدی.

بر زاماندا سینده نامار اوقئغانلار حان ایدی،
قومی تاتار هه‌م تورکنك مسکنی قازان ایدی،
اول واقتنی تصویر ایتساك نی گوزه‌ل زامان ایدی
قالبئمی مئك پاره قیلدی شول گوزه‌ل حان مسجدی.

هه‌ب کلیسه اورتاسندا یالغئزئك قالدنك نیچون؟
التفاتك بر تاتاردان سین بینا الدك نیچون ؟

اهلی اسلام قالبئنه سین خسرەتی سالدک نیچون ؟

قالبئمی مئک پارە قیلدی شول گوزەل حان مسجدی.

بر واقتدا سینده طوردی اهلی اسلام عسکری ،

شوکتک بتتی بو کونده ، قالمادی منکدان بئری ،

باشقالارنک جیری بولدی اوشبوکون اسلام جیری .

قالبئمی مئک پارە قیلدی شول گوزەل حان مسجدی.

سین اومید اوزماسانک دە بئردین - بز اومیدنی اوزمادک

ظاهران توزساک دە بزلار - قالبئمزدەن توزمادیک

جاهیل اولغان بر زاماندا قیمه تکنی بلمادیک

قالبئمی مئک پارە قیلدی شول گوزەل حان مسجدی

مجید غافوری

## توقای مکارجه‌ده

۱۹۰۸ نچی یلنی شاعرمز عبدالله افندی توقای علی اصغر افندی کمال برله برگه ایکاو مکارجه‌گه کیلگانلر ایدی. آلار مکارجه‌ده تیمر شاه افندی صالاۋیوف نڭ گاستینسه‌سینه توشکانلر ایکان. بزنڭ اول وقتلرده اسپیکتاکل‌لر سیره‌ك قویلغانغه بوش وقتلرمز کوب بولا ایدی. بز آرتیستلر گاستینسه‌غه باررب توقای، علی اصغر افندی و باشقه فکرده‌ش دوستلر برله برگه جیلوب گه‌بله‌شوب، چای اچه‌در ایدك. شولای یوری طورغاچ بر کوننی، تیمرشاه افندی صالاۋیوف بزدن، کچکنه‌گنه پیانینو قویار اوچون یاصاغان، صحنه‌سینه چغوب تورلی ملی شعرلر اوقوومزنی اوتندی. بز یه‌ش کوڭللر صحنه‌گه منوب «بحیلله‌شو» شعرینی و باشقه شوندی کوڭل اویغاتا طورغان شعرلرنی جرلاب توشدك. په‌ره‌مه‌چ آشاوچی آغای انیلر بزنڭ جرلاوومزنی بیك

یاراتوب قایسی: آفرین! یه‌شه‌گز! دیگان طاوش و آلقشلر برله بزنی قارشی آلدیلر...

تیمرشاه افندی بزنك جرلاغانمزنی بلسونلر اوچون پارادنی ته‌ره‌زه‌سینه: ملی شعرلر اوقولا، خلق جرلاری جرلانا، دیب بر کچکنه گنه پلاکات ده ئلوب قویدی. بزنك اشلر شه‌به‌یدی. ایکنچی کونی ایندی، اول بارمز اوچون ده آلطی دانه قزل، بر دانه زنگه‌ر فه‌سلر آلدرغان ایدی. عبدالله افندی توقای جرلاغان وقتده بزنك آلده خلقغه آرطی بزگه آلدی برله کاپلمیستر شیکللی قوللری برله بولغاب طورادر ایدی؛ مونه اول زنگه‌ر فه‌س توقای اوچون ایکان.

... شولای اشلر یاخشی‌غنه بارغانده، ئلله قایدن بر گارمونچی کیلوب چقدی؛ اول صحنه‌گه منوب گارمونی ئه‌یتدره، ئلله نیندی اورام جرلری جرلی با-شلادی. بو گارمونچی بزگه قاراغانده اون ئلوشله‌ب آرتق موفقیت قازاندی. طانش‌لر بزنك یانغه کیلوب بزنی ئورته‌گان صمان، شادلقلرن بلگرتوب: «یوزی قارا، شه‌ب جرلی بیت ئه؟» دیب کیته‌لر ایدی.

شوندن صوك بز اوز اوزمزگه اونوتلدق. کونذزلرنی توقای برله صاماکاتقه یورورگه چغا ایدك، اول آنده ایکی تیین بیروب، بالالر شیکللی کروسیل آطلرینه آطلانوب ئه‌یله‌نه طورغان ایدی. توقاینك، کروسیل آطلرینه آطلانوب ئه‌یله‌نووی اورالسکی‌ده ده یش، یش کنه بولا ابدی.

... توقای‌نك مکارجه‌ده بولووی برنچی هم آقتغی بولدی.

ع. کارییف.

# سوز باشی

سویکلی بالالر !

سز کچکنه بولساڭزده یازونی طانیسز، ماتور بولما-
سه ده بیك درست ایتوب یازاده بله سز.

ایندی شول یازونی ماتور ایتوب یازو بار، آنارغه «حسن خط» دیوب ئه یتوله در. «حسن خط» مکتبده چاغنده اویره نورگه تییشلی و بیك کیره کلی هنرلرنڭ برنچیسیدر. منه شول هنرنی آلورغه سزنی قزقدرو اوچون، بیك ماتور ایتوب یازو توغریسنده برنی قدر سوزلر یازوب کتاب شکلنه قویام. سزده آنی اوقوب، کوزڭز ماتور یازوغه اویره نورهم اوزڭز-ده شونڭ توسلی ماتور ایتوب یازا باشلارسز.

مکتبده حسن خط اویره ته تورغان معلمڭز-نڭ بیرگان وظیفه لرینی بیك چن کوڭلکز ایله ماتور

چغار رغه طرشو سز. درستنده بالالر یازوولك ماتور
چقسه اوزڭاده کوڭللی، اوقتوچیغه ده کوڭللی بولادر.
ماتور یازولرنك تورلی اسملیلری بار، اما سزگه
بو کتابده کورسه تلگان یازولر «خط ثلث»، «خط
نسخ»، «خط تعلیق» دیوب آتالادر.
سز طرشساڭز اول یازولرنك بارلغنده اوێره-
نورسزده «خطاط» (ماتوریازوچی) اسمن آلورسز.
اگرده سز یازولردن برنیچه تورلیسنی اویره نوب
ماتورماتوریازولریازسه ڭز سزنك اول یازولر-
ڭزغه هرکم «آخ شونك کبك یازا بلسه ایدم» دیه
قزغوب کوزلرن آلماسدی بولوب قاراب تور-
ورلر. کوره سز بیت ماتوریازلغان یازولرنی
قدرله ب، رامقه لاب استینالرغه کوز آلدینه
طاغوب قویالر.

# قزان شهری ننك احوالی

میلادیه ١٢٩٥ نچی یلده ایسکی قزان شهری قورلغان قزان صوی بوینده ایشی آولی یاننده ایسکی قزان اورنی حاضرکی قزان شهرینه ٤٧ چاقرم

١٤٣٧ نچی یلده ایسکی قزاننی اورنی اونکغایسز دیوب بو اورنغه کازانکی صویده هم ؤولغه ایدلیده قبان کولیده بار دیوب ایسکی قزانغه کلوب اوردا خانی ننك اوغلی محمود مصلحت ایدوب شهرنی بو حاضرکی اورنغه کوچردی هم شول یل مسکاو ایله اورش قیلدیلار بو شهرکا اسم بیردیلر غزان دیوب

١ل٢١ نچی یلده قزانده شیر علی خانغه خلقی باش کوتاروب شیر علی خاننی توشوروب اورننه سید گرای نی خان ایتوب شول یلنی عسکر جیوب مسکاو جیرینه یوردیلر

١ل٢٤ نچی یلده سید گرای خاننی قزاندان اورس قوغان هم کناز ؤاسیلی ایؤانغه اورس کوپیسلرنی منع قیلغان قزان یارمنکاسینه بارورغه هم سوده قیلورغه اورون تعین قیلغان ایدل ننك صول یاغنده مکار اسکی ژیلتاوتسکی ماناستیر دیکان اورنده ـ شول یارمنکانی حاضرده نیژنی ناؤغورودده مکار اسکی یارمنکا دیورلر بیك ضور سوده قیلا تورغان یارمنکا بولادر

١ل٣٠ نچی یلده مسکاو عسکری قزانغه صوغشقه کیلکان هم شول وقت قزان خلقی ینالی خاننی تحتکا اوتورتقانلار

١ل٣٦ نچی یلده برنچی صوغشی مسکاو اسکی ؤیلیکی کناز ایؤان رابع ننك قزان خلقی ایله

١ل٤١ نچی یلده قزانغه صفا گرای خان بولغان

١ل٤ل نچی یلده ایکنچی سفری صوغشقه ؤیلیکی کناز ایؤان رابع ننك قزانغه

١لل٥ نچی یلده قزانغه اوچنچی سفری ؤیلیکی کناز ایؤان رابع ننك زویه قالاسی صالورغه اورون ازلرکا کیلوی

١لل١ نچی یلده قزانغه دورتنچی سفری ؤیلیکی کناز ایؤان رابع ننك هم زویه قالاسنی صالوب قالدردی

١لل٢ نچی یلده ایبول ننك ٣ نده مسکاو عسکری ایله کناز ایؤان رابع اوزی سفر قیلدی صو ایله هم قورودان کوب عسکر ایله هم سنتابرننك ل نده قزانغه چوقرلار قازوب داری ایله کوتارته باشلادیلار هم سنتابرننك ٦ نده آرچه نی آلدیلار آرچه قزان ننك سبر یاغنداغی کرپیچی ایردی سنتابرننك ٥٣ نده آرچه جولندان کلوب آرچه قرندان داری ایله کوتارته باشلاغانلار اوکتابرننك ٢ نده هر جانبدن قزان شهرینه کروب کوب قان توکوب شهرنی آلغان هم خلقنی اوزینه تابع قیلغان

١٧٠٨ نچی یلده اوّل باشلانوی قزان‌ننك گوبیرنا بولوب ایمپیراطور پیطر پیرۋی‌ننك اوكازی بوینچه یعنی امری بوینچه ١٨ نچی دیكابرده روسیه‌نی بولدی سكز گوبیرناغه اماقزان گوبیرناسینه ١٧ اویاز بولدی

١٧١٤ نچی یلده ایمپیراطور پیطر پیرۋی رخصت قیلدی قزان‌غه پوصتاو فابریكی آچارغه

١٧٢٢ نچی یلده مای‌ننك ٢٧ نچه ایمپیراطور پیطر ۋیلیكی قزان‌غه كیلدی

١٧٥٨ نچی یلده ایبون‌ننك ٢٥ نچه قزانده ایكی گیمنازیه آچلدی برسی دۋوران بالالاری اوچون ایكنچی گیمنازیه غیری توره بالالاری اوچون

١٧٥٩ نچی یلده آپریل‌ننك ٢٧ نچه تیآتور اویونی باشلاندی گیمنازیه‌ده

١٧٦٧ نچی یلده مای‌ننك ٢٦ نچه قزان‌غه كیلدی ایمپیراطوریتسه یكاترینه افتوروی

١٧٧٤ نچی یلده ایبول‌ننك ١٢ نچه قزاننی خراب ایتوب یاندردی پوگاچوف

١٧٨١ نچی یلده قزان گوبیرناسینه یانكا نظام ایله حكم بیورلدی

١٧٨٦ نچی یلده ١٥ نچی سنتابرده پورحاۋای زاۋود آچلورغه امر بولدی

١٧٩٨ نچی یلده ٢٤ نچی مای‌ده قزان‌غه كیلدی ایمپیراطور پاۋیل پیرۋی ۋیلیكی كنازلر ایله یعنی الیكساندر پاۋلوۋیچ هم قنسطنطین پاۋلوۋیچ‌لر ایلان

١٨٠٠ نچی یلده ایمپیراطوریتسه یكاترینا ثانی امر ایتدی قزان‌ده گیمنازیه‌ده مسلمانلارغه كتاب باصارغه

١٨٠١ نچی یلده قزانده چاستنی تیاتور آچلدی یسیپواده

١٨٠١ نچی یلده صویرلار محله‌سی دیكان طاش مسجدنی اورناش باشی آولی‌ننك موسی بای سلیم اوغلی صالدرغان

١٨٠١ نچی یلده یانكا بیسته‌ده اورطا محله‌ده طاش مسجدنی اورناش باشی آولی‌ننك رقی بای صالدرغان

١٨٠٢ نچی یلده یانكا بیسته‌ده ١ نچی ضور طاش مسجدنی مچكره‌ننك عبد الله عبد السلام اوغلی اوتمیشوف صالدرغان

١٨٠٤ نچی یلده ٥ نچی نویابرده قزان اونیویر یستیتی‌ننك اوصنافنی اوتۋیر دیت ایتلكان

١٨٠٤ نچی یلده آپانایوف‌لار مسجدی دیكان مسجدنی یعقوب سلطانایوف اوز آقچه‌سی بتكاچ جماعتدن آقچه جیوب صالدرغان

هم بو یلنی قزان مسلمانلارندان آقچه جیوب محمد شریف ملا ایله بكر ملا برنچی طاش مسجدنی بنا قیلا باشلاغانلار افندی مسجدی دیو مشهوردر

١٨١١ نچی یلده یانكا بیسته‌ده كچكنه طاش مسجدنی موسی آپانایوف صالدرغان

١٨١٥ نچی یلده ایسكی بیسته‌ده میشچان اورامنده طاش مسجدنی قزان كوپیصی ایصای

احمدقزی‌ننك وصیتی بوینچه صالغانلار زنكار مسجد دیو مشهوردر

١٨١٦ نچی یلده قزان‌غه كیلدی ؤیلیكی كناز میخایل پاؤلوؤیچ یانكادان قارارغه اونیویریستیت اوصنافنی

١٨٢٣ نچی یلده آغوست‌ننك ٣٠ نده آچلدی كازانكه بوینده پامتنیك قزان آلغانده اولكانلر اوچون

١٨٢٩ نچی یلده اوّل بیرلدی ملالارغه میتریچسكی دفتر مسلمانلارننك توغاننی اولكاننی نكاحنی طلاقنی یازارغه

١٨٣٠ نچی یلده قزان‌ده ضور وبانك اوّل بولوی

١٨٣٥ نچی یلده ایكنچی ایرلر گیمنازیه‌سی آچلدی

١٨٣٦ نچی یلده ٢٠ نچی آغوست‌ده قزان‌غه كیلدی ایمپیراطور اعظم نیكولای پاؤلوؤیچ نیژنیدن اچترخان‌كوپیصی یارالوف‌ننك پراحوتی ایله دقت ایدوب قارادی اونیویریستیت‌نی هم مانیبر یصادی هم دؤوران‌لر مجلس قیلوب حرمت ایندیلر

١٨٣٧ نچی یلده ایپول‌ننك ٢٢ — ١٢ نده قزان‌ده‌بولدی ناسلیدنیك سیصاروؤیچ الیكساندرنیكولایؤیچ سبردن یوروب قایتونده

١٨٤٢ نچی یلده سنتابرننك ١٢ نده قزان‌ده دوخوؤنی آكادیمیه آچلدی

١٨٤٤ نچی یلده ١١ نچی عنوارده آچلدی نیكولایؤاسكی بالالار تربیه قیلا تورغان پریبوت

١٨٤٤ نچی یلده ٥ نچی دیكابرده آچلدی یونوسف اسكی مسلمان‌بالالارنی تربیه قیلا تورغان پریبوت

١٨٤٥ نچی یلده فبرال‌ننك ٦ نده الیكساندروف اسكی بالالار تربیه قیلا تورغان پریبوت آچلدی

١٨٤٥ نچی یلده پچان بازارنده طاش مسجدنی صالدردیلار عبید الله یونوسف‌ننك اوغل‌لاری ابراهیم هم اسحاق حاجی

١٨٤٩ نچی یلده قزان ایله بش‌بالطا آراسنده دامبی‌یصالدی هم بویل ایكنچی وبا بولوی قازان‌ده

١٨٥١ نچی یلده طاشدان یانكا تیاتور آچلدی اوّل اوینالغان اویونی ایتالیان اسكی اوپیر

١٨٥٣ نچی یلده اوچنچی مرتبه قزانده وبا بولغان

١٨٥٩ نچی یلده ١٧ نچی مای‌ده قزان‌ده ضوریوژار بولغان بوندای ضوریوژارننك بولوی قزانده اوننچی مرتبه سیدر

١٨٦٥ نچی یلده سنتابرننك برنچی آچلدی قزانسکی سیلسکی حوزایستۆیننی ۋیصتوفکه

١٨٦١ نچی یلده آغوست‌ننك ١٦ نچی بولدی قزانده ناسلیدنیك سیصاروۋیچ نیکولای الیکساندروۋیچ

١٨٦٣ نچی یلده ایپول‌ننك ٩ نچی بولدی قزانده ناسلیدنیك سیصاروۋیچ نیکولای الیکساندروۋیچ آغوست‌ننك ١٨ نچی نیکزصالدیلار سینترالنی اومالیشننی دوم یعنی عقلی خسته بولغانلار اوچون جورت

١٨٦٤ نچی یلده آچلدی اوبشیستۆیننی بیبلوتیکه ینه بویل آچلدی اوّل زیمسکی صوبرانیه ینه بویل آچلدی قزانده یونکیر اسکی پیخوتنی اوچیلشچه ینه بویل آچلدی زیمله‌دیلیچسکی اوچیلشچه یعنی زراعت مکتبی فیرمیده

١٨٦٨ نچی یلده قزان‌ننك ضور بابی جهانشاه عثمانوف تیخۆین اسکی اورامده طاش مسجد صالدردی

١٨٦٩ نچی یلده صودیبنی میراویح اوچریژدینیه آچلدی قزانده

١٨٧٥ نچی یلده آچلدی قزانده اوکروژنوی صود هم صودیبنی پولاط

١٨٧١ نچی یلده ایرلر اوقورغه پروگیمنازیه آچلدی

١٨٧٢ نچی یلده میشچانسکی اورام باشنداغی طاش مسجدنی قزان‌کوپیسی آصلی بره‌سکه‌لك محمدصادق قربان‌علی اوغلی بورنایوف صالدردی

١٨٧٢ نچی یلده نیگزی قورلدی کول‌بویینداغی اوچیتل اسکی سیمیناری‌ننك

١٨٧ل نچی یلده ایسکی زیارة یاننده ایسکی بیسته‌ده طاش مسجد صالدردی قزان بابی محمدجان نذیر اوغلی کازاکوف بوبای آصلی طاو یاغی‌ننك

١٨٧٤ نچی یلده اوکتابرننك ٤٢ نده آچلدی قزانده ۋوده پروۋود یعنی فانطال هم بویل غاز یانا باشلادی اورام فانارلارنده قزانده

١٨٧ل نچی یلده آچلدی رویالنی اوچیلشچه هم اوکتابرننك ٢ نده کوننی ژیلیزنی دوروگی یعنی آط ایله باگون جولی آچلدی هم بویل آچلدی گراداسکوی ناچالنوی مسلمان اسکی اوچیلشچه

١٨٧٦ نچی یلده آچلدی خاتونلار پروگیمنازیه‌سی

١٨٧٧ نچی یلده آچلدی گراداسکوی ناچالنوی اوچیلشچه ایکنچسی مسلمان بالالاری اوچون

١٨٨٥ نچی یلده ١ نچی ایپولده آچلدی بش بالطاده سیلسکی خوجا یستۆیننی ۋیستوفکه

١٨٨٣ نچی یلده قزانده پاسصاژ آچلدی

١٨٨٦ نچی یلده آچلدی تلسزلر اوچون اوچیلشچه

١٨٨٦ نچی یلده آچلدی آتدیلینیه کریستیان اسکی پوزیمیلنی بانکه قزانده

١٨٨٦ نچی یلده آغوستننك ١٧ نده آچلدی قزانده ریمسلیننی هم سیلسکی
خوجایستۋیننی ۋیستوفکه

١٨٨٧ نچی یلده آچلدی قزانده زیمسکی فیلدشیر اسکی اشکولی

١٨٨٨ نچی یلده نویابر ل ١ نده باشلاندی تیلیفون قزانده

١٨٨٩ نچی یلده آچلدی قزانده ګراداسکوی لانبارد

١٨٩٥ نچی یلده مای ل ١ نده آچلدی قزانده نااوچنی پرومیشلیننی ۋیستوفکه
شول یلنی ل ١ نچی سنتابرده یابلدی

١٨٩٥ نچی یلده ١٦ نچی اوکتابرده قزانده مسلمانلارغه بوګادیلنی آچار اوچون
اون منك تنکه آلیکساندروف سنکلسی اولګه عنیس اهلیه سی بیردی

١٨٩١ نچی یلده ایيون ٤ نده قزانده بولاقده طاشاياق يارمنكاسی تمامجاندی

١٨٩١ نچی یلده آغوست ٢٥ نده چرك كولنی تمام كوموب صونی بتروركا باشلادیلار

١٨٩٢ نچی یلده مارت ٢٢ نده آچلدی حیوان صویا تورغان قصاب اورنی
ایيون ٣ نده برکا قوشلدی مسلمان اسکی هم روس اسکی سیرود اسکی صود
ایيون ٩ نده باشلاندی کیژیچسکی دامبه نی اشلرکا
ایيون ٢٧ نده بش بالطاغه وبا اوچون بولنیس صالندی هم وبا بو یل بولا
باشلاندی •
ایيول ٣٥ نده آچلدی قزانده اوبشیستۋو تریزۋستی یعنی آیقلار جماعسی
سنتابر ٦ نده صالونا باشلاندی قزانده اونیۋیریستیت بیبلوتیکه سی
سنتابر ١٧ نده آرچه قرنده حیوانلار اوچون بولنیس آچلدی

١٨٩٣ نچی یلده ٧ نچی آپریلده برنچی صوبرانیه بولدی قزاننك بلی سابد
اوبشیستۋاسی ننك
سنتابر ٢١ نده آچلدی سیلسکی خوجایستۋیننی ۋیستوفکه پانایوف باقچه سنده
دیکابر ٢٢ نده ګراد اسکوی دوم زالنده دعاء بیرلدی ژیلیزنی دوروګی
آچارغه قزاندان زویه بوینه

١٨٩٣ نچی یلده داملا عالمجان بن حاجی محمدجان علیوف بو یل بالالارنی اصولی
جدید اوزرینه تعلیم بیره باشلادی

١٨٩٧ نچی یلده آرچه قرنده کلیننیك بنا قیلنه باشلاندی بیك ضور عمارتلار

١٨٩٧ نچی یلده قزان مسلمانلاری مسلمان اسکی بلاګوآتۋوریتلنی اوبشیستۋا
آچدیلار بایلار هرقایولاری آقچه صالوب چلین بولدیلار پریدسیداتیل
ایتوب صایلادیلار ګنیرال شامل حضرتلرینی آقچه کازناچیی قزان کوپیسی

اسماعیل اسحاق اوغلی آیتوغانوف بو مسلمان اسکی اوبشیستـڤوا جیولغان آقچه‌دان حاضرده شهر قزانده فوت بولغان فقیرلرگا کومارگا هم کفن‌گا قبر قازغان‌غه دیوب اوچ صوم تنکه بیره‌لر اما قزانده ل نچی چاسده پوپیریچنی زاخار اسکی اورامده ابراهیم یونوسف وقف قیلغان جورتنی توزاتدوره‌لر قزانده بولغان یتیم بالالارنی تربیه قیلور اوچون مثلا بعضی مسافر قزانده توروب اولوب بعده بالالاری قالا بعضسی‌ننك دولتی بولمی هم بو بالالارنی تربیه قیلور کشی ده بولمیدر ینه بعضی آدملر گناهی سببلی قزانده حکم ایدلوب سبرگا یبارورگا ریشیت قیلغاچ بو آدم‌ننك خاتونی هم بالالاری آتالارندان قالمای بارامز دیوب کاعذ بیروب بونلرده آتالاری یانینه حبس‌گا کیلوب آتالاری سبرگا چغوب کیتکانچه قزان‌ده تورغان‌ده عمرننك فنالغی سببلی آتالاری هم آنالارینه اجل یتشوب اولـکاچ بو بالالارنی سبرگا یوللامی‌لار چونکه بونلار گناهسز آتالارینه ایاروب‌کنه بارالار ایدی ایمدی بونلارنی آوٴل‌لارینه یبارسه‌لر آول‌لارندان بونلار چقغان شول سببدن بوندای عاجز یتیملرنی تربیه ایدارگا بیك تیوش بولغاچ قزان مسلمان‌لاری بویله آقچه جیلوشوب پریپوط آچالار ینه آقچه‌لاری کوبایکاچ شهرده برقرداشی بولماغان عاجز توفیقلی قارتلار بولا شونلارغه بوگادیلنی آچماق بولالار بو قارت‌لار پادشاهمز نیکولای ثانی آلیکساندروڤیچ حضرتلرینه خیر دعاقیلوب تورورغه ایمدی عزتلو اوقوچیلار بو یتیملر اوچون هم ضعیف قارت‌لار اوچون تصدق قیلماق مراد ایتسانکز قزان‌غه مسلمان اسکی بلاگو آتـڤوریتلنی اوبشیستڤاننك کازناچیی قزان کوپیسی اسماعیل آیتوغانوف‌غه یباراسـز آیتوغانوف آقچه آلغانلقـدان جنابنکزگا کڤیتانسه یبارور

١٨٩٨ نچی یلده بش‌بالطاده ایکنچی مسجد صالونا باشلاندی

١٨٩٨ نچی یلده بش‌بالطاده آلطنچی‌چاس‌ده ضوراورامده آغاچ‌دان جامع صالدی قزان کوپیسی سلیمان محمدجان اوغلی آیتوف اما بو مسجد جیرنی صاتوب آلغان ایردی قزان کوپیسی علیم صوبایوف اوغلی باقی‌بای بو باقی صوبایوف بو جیرنی مسجدگا وقف قیلدی بارك‌الله بو ایکی یاش بایلار قندای مروّت کوستاردیلر ❁

# جغرافیه وتاریخ فنلری.

جغرافیه. یر علمی. یرنڭ اوستنده‌گی صولار، طاغلر اورمانلر وبولارغه باشقه شیلرنی تعریف ایتگان فننی جغرافیه (Географія) دیلر.

بو جغرافیه علمی بزم اسلام شریعتنچه بلوی واجب بولغان علملردن بر یدر. حتی آرتق درجه‌ده لازمدر. چونکه قرآن شریفده «ومن آیاته خلق السموات والارض وما بث فیهما من دابة وهو علی جمعهم اذا یشاء قدیر» دیمش. یعنی الله تعالی‌نڭ کمال قدرتینه الوغ علامتلر جمله‌سندندر، یر کوکلرنی یاراتمقی همده بو ایکسنده جان ایه‌لرندن طاراتقان ذاتلری. یعنی یرده وکوکده جان ایه‌لری باردر. الله تعالی تلاگان چاغنده بونلرنی برگه جیارغه قادردر. بو آیتدن بلنه‌در یرده جان ایه‌لری بولغانی کبی کوکده ده خلق بارلغی. بو آیت حکیملرنڭ یولدوزلارده طورغوچیلر بار دیدکلرینه بیک موافقدر...

یر کوک علمن تمام بلوده الله تعالی‌نڭ قدرتن بلو، بو علمنی بلمگانلرگه قاراغانده میلیون درجه آرتق بولوتده شبهه یوقدر. دیماککه جغرافیه بلو الله تعالی‌نی کامل معرفت‌نی بیره‌در. معرفت الله واجب ایدی. بس جغرافیه‌ده واجب بولادر. کوک علملرن کواکب حاللرن آی قویاش حاللرن بلو مسلمانلر ایچون صورتدن حقیقتی بلنودن منزه بولغان ربلرن بلوده برنچی قورالدر... بز جغرافیه بلسه‌ك یولدوزلارنی تکر دیوچیلرنی رد قیلوده قادر بولامز...علم تاریخده مسلمانلر ایچون لازم بر علمدر. بتون یر یوزنده بولغان خلقلرنی توسلرن وصورتلرن توشنب بلو، آنلرنڭ صانلرن بلو بارسیده قرآن شریفده بیورولمشدر. چونکه توسلرگزنڭ وتللرگزنڭ تورلیلگی الله الله تعالی‌نڭ قدرتینه الوغ علامتلردر دیولمش. ینه‌ده قرآن شریفده دیولمش:

«قل سیروا فی الارض فینظروا» ایت سین ای محمد، اوزڭنڭ قومڭه: یر یوزنده سیر ایتوڭز، اگرده سیر ایتسه‌ڭز اعتبار کوزلری ایله قاراب اشنڭ حقیقتنه توشنرسز! بو آیت شریفه‌ده‌ده یر یوزنده یورو جغرافیه وتاریخ علملرن بلوگه بیورو بار...

شول سببدنده جغرافیه علمی کبی تاریخده واجبدر...

بزم شریعت مسئله‌لرمزده‌ده جغرافیه ضروردر. مثلا چیت مملکتده بولغان بر کمسه بزم روسیه مملکتنده بولغان زیدنڭ طوغانی ایکان. شولار ایکسی بر کونده وفات بولسالار، شول وقتده بولارنڭ قایوسی الك اولگاننی بلو ایچون جغرافیه بلو لازمدر. ینه‌ده اسلام شریعتنچه جهاد فرض‌در. آنی اجراء ایچون جغرافیه لازمدر...

# قزان تاریخی.

قزان شهری ۱۵۵۲ نچی یلنڭ اوکتابر ۲ سینه قدر، مسلمان خانلغنده (تاتارلار قولونده) بولمش. دیمککه موندان ۳۵۶ یل الك بو قزان شهری بزنڭ بابالارمز قولونده بولمشدر. مذکور یلده بابالارمزنڭ قوللارندان روس عسکری قولینه کرمشدر...

ایوان غروزنی دیگان روس خانی‌نڭ قزاننی مسلمانلر قولوندان آلوی.

(Царь Іоннъ IV Грозный.)

مسقوا خانلغی، اوزن صاقلامق واوزن یاشاتمك ایچون قزان خانلغی ایله بر طوطاشدان صوغش آچماق بولدی. مسقوا خانی غروزنی ۱۵۵۲ نچی سنه ۱۶ نچی ایونده یوز ایللی مڭ عسکر (غازی) جیوب، باشده اوزی طوروب تحت ریاستنده عسکرن آلوب آوغوست ۱۳ نده مسقوادن قزان طرفینه سفر ایتدی. قزاندان یکرمی بیش چاقرم چاماسنده اولان زویه شهرینه یتوب، بولونغه شهر آستونه کیلوب طوقطادی. خان چاطرینده صوغش حقنده جمعیت تورلدی. شول جمعیتده قرار بیردیلر: قزان خانینه «اوز ایرکی ایله ایوانن گروزنیغه بیریلورگه» دیوب یازو یبه‌رگه.

آوغوست ۲۰ نده ایوانن اوزینڭ عسکری ایله ؤولغه آرقلی همده کازانکا آرقلی اوتب قزان شهری آستونه کیلوب توشدی.

— شونده چاقلارنده قزان خانی «یادگار» دن، قباحت سوزلر ایله یازلغان جوابنی آلدی. جواب‌نامه شویله تمام ایتولمش ایدی: «هر نرسه حاضر، سزنی کیفی صفا قوررغه کوته‌مز!».

— آوغوست ۲۳ نده ایرته‌گسن روس عسکری قزان‌نی قاماب آلدیلار. لکن باشده بو اشلری فائده‌سز بولدی. هم قزان خلقنده شادلق بولدی، بو آش آلارنڭ غیرتلرن آرطدردی. آلار ایتکانلر: بز بر کشمز قالماغانغه چه آقطق قاشق قانلارمز غاچه شونده‌اده طورشامز روس عسکرینه قلعه‌نی ایرکلی قولدان بیرمیمز. سیننده بر اوطورنده ایککی طرف قارا قارشو صوغشه باشلادیلار: لکن روس عسکرینڭ آرطده اپاص عسکرلی حاضر بولمادقدان بو صوغش، آنلار ایچون فائده‌سز چقدی. زاپاص عسکر یراق ایدی. اگرده شول وقتده زاپاص عسکر حاضر بولسه ایدی، قزان شول کونده اوك آلنغان بولور ایدی؟ بو وقعه‌دن صوڭ قزان خلقی بیك تیزگنه وقتلی قالقان قوردیلار. دشمان عسکرندن قاچنوب، صاقلانوب صوغشو ایچون اورن حاضرله‌دیلر.

برنچی اوکته‌برده شنبه کون روس خانی عسکرینه اعلان ایتدی: «ایرته‌گه یکشنبه کون ۲ نچی اوکته‌برده عمومی قان اچولر یعنی آقطق کوچکه قدر، قزاننی آلوده صوغش

قیلونور. ایکنچی اوکنه برگه قارشو شنبه کون کیچ روسنلڭ هر بر عسکری اوزا اورنلارنده اورناشوب قلعه نی چلغاب آلورغه حاضرلك قیلوب فرمان کوتوب طوردیلار.

روس خانی حضورنده یکرمی مڭ صایلانغان عسکر قالدی. بوصوغشقه خان اوزی برده قاطشمادی. هم عسکری باشی ده بیلگوله‌مدی. عسکرنڭ هر برسیده برنیتده براش خصوصنده اش قیلغاننی بلدکدن، آلار ایچون باشلاب کامانده‌وۋات ایتوچیده ضرور توگل ایدی. صوغش باشلانور آلدوندان، بیك طنچ ایدی هیچ برطاوش بولمادی. باری عسکر اوزاطو ایچون دعـا قیلنه طورغان پتخانه‌ده، دعا طاوشلاریغنه ایشتوله ایـدی. روس خانی ده شونده ایدی.

قویاش چغه باشلادی. اوزاق اوتمه‌دی کینه‌تدن بیك قاطی طاوش ایله یاشن آطقان کبی کوك گلدره‌گان ره‌وشده یر آستونه قازوب قویولغان، کوته‌رتو اوچون توزلگان داری شارطلادی. شول طاوشقه روس خانی پتخانه‌دن یوقارو چقدی: نی کورسون، قورقنوچلی کوته‌رتو، یرنڭ قوبارلوب طاشلانغان کیسه‌کلری، مناره‌لرنڭ قوبوب توشولری، اوی دیوارلری ایشولووی، کشیلر، طاشلار هم طوزانلار طاشلانوی. هواغه کوته‌رلگان توتونلر یوغـاری‌دان کیری شهر اوستونـه توشولری، عجیب بر قورقنوچ حـالت! بو ییر آستونـه قازوب قویولغـان روسلرنـڭ کوته‌رتو ایچون حاضرلب کوملـه‌ش برنچی کوته‌رتولری ایدی. بوحالنی کوروب بترگاچ روس خانی دعانی تمام ایتو ایچون عبادتخانه‌لرینه یاڭادن کردی.

اوزاق وقتده اوتمه‌دی، ایکنچی بایاغیدانده کوچلیره‌ك یاڭا طاوش ایشتولدی، بو ایکنچی کوته‌رتو. شوندان صوڭ روس عسکری «الله بزنڭ برله! «Съ нами богъ! دیوب، قلعه طرفینه یاقنایه باشلادیلر.

اول وقتده قزان خلقی مسلمان(تاتار)لار بیك غیرت همده چداماغان حالده روس عسکرن کتب طورالار ایدی. اوقلار همده ملطق‌لر ایله‌ده آطمیلر ایدی.

کینه‌تدن موڭلی‌غنه «الله اکـبر، الله اکبر!» دیگان طاوشلار ایشتوله باشلاب شول سوزلر ایله برلکده یه‌دره همده اوقلار، طاشلار روس عسکری اوستونه یاواده باشلادیلار....

تاتار (قرنداش‌لرمز) روس عسکرن استلرینه طاغدن بوره‌نه‌لر توشروب باصطره‌لار، قایناب طورا طورغان صومالالر سیبه‌لر. اوزلریده هلاك بولدیلر، لکن دشمانلری روس عسکرنده کوب هلاك ایتدیلر. شول ره‌وشده بولاما هلاك ایتوشو باشلاندی. قزان مسلمانلری (تاتار قرنده‌شلرمز) بیك غیرتلی وییگت طبیعتده، اوزلرن چلغاب آلغان

دشمان عسکرندن برده قورقمی طورغان وقورقنولاده آلماغان ، غیرت ملیهٔ اسلامیه ایله صوغش ایتوده مداومت ایتدیلر.

